күп сыйырлар асрап, сөт сатып йәшәйләр. Сыйыр асраған кешеләр эремсектер, ҡатыҡ та йасайлар, саталар, алабыз, Аллаға шөкөр. Үзебез сырлар йасайдыр идек, майлар. Чәк-чәкләр пешерәбез, тайикмәкләр, бәлеш. Хәзер барсын да бешерәләр бит, балам. Йарма бәлеше, ҡабаҡ белән бик тәмле килеп чыға. Вареньелар йасайсың. Быйыл алма бик күп булды. Баҡчала бөтөнөсө лә үсә. Ҡартайғач та чәчкә үстерергә йарата башладыҡ. Чәчкәләребез дә үсә. Донйалар бик матур, матур итеп көтәләр барсы ла.

Ауылыбызда клуб, китапхана эшләп тора. Медпункыт бар, бик әйбәт. Мәктәп кенә йуҡ инде. Мәктәп Ҡатайға күсте хәзер. Күрше ауылға автобус белән йөрөй бала-чаға.

Ҡамҡа – фатима (Фатима, фатима, кейәүең килә, ҡапҡа ач та ҡач, тийер идек бәләкәй чаҡта), турғай – чыпчыҡ, һандуғас – сандуғач.

**Муллағәлиева Вәзимә Абунәғим ҡыҙы:** Ауыл матур инде. Тау башына менеп ҡарасаң, Чейәле тауы бар, безнең ауылны ҡарасаң, безнең ауыл бик матур булып күренеп тора инде. Безнең үзебезгә матур инде. Мына урманнарда салҡын шишмә булған инде элек, без бәләкәй чаҡта ана шул салҡын урманға барадыр идек эткәйләр белән. Чабадыр идек бит элек песәнде. Шунда салҡын шишмәнән бездең эткәй шул салҡын шишмә суын алып килеп, безгә чәй ҡайнатар иде. Үземдең дә барып, бәләкәй чағымда күргәнем бар. Суу ныҡ салҡын иде. Бу йаҡка таба ағар иде ул, өстән түбәнгә ҡәдәр төшәр иде. Аның суу ла тәмле иде, салҡын иде. Шуларны беләбез инде без.

Ҡалка тауынын чоҡоронда су булған, анда ҡамышлар булған, шуға Ҡамышлытау дигәннәр, дип сүйләйләр иде.

Клубта инде без вечер суғадыр идек. Анда без читәнледәр уйнай идек, бейейдер идек. Гармонислар күп иде вит ауылда. Хәзер гармонислар йуҡ. Бийип, жырлап, читәнлеләр уйнап, рәхәтләнеп ҡайтып китәр идек. Төрлө дәртле бийүләр бийеп. Син ҡал, мин ҡач, дип бер-беребез менән уйнар идек. Кем ҡала, шул жырлаймы, бийийме. Шундай ҙа уйындар уйнай идек.

Элекке донйа бөтөп бара. Хәзер йәштәр заманса йортлар салалар. Ауыл халҡы тырыша. Ҡай берсе мал менән, ҡай берсе үзенә күрә эш табып, йәшәргә тырыша инде. Кемдең ҡулында нәрсә бар, эшләргә, йәшәргә тырышалар. Ҡорот ҡай берзәр эшләй. Бәлеш пешергәндә саласын. Без аны эремсек салмасында, йасап бөтөрмәйбез аны. Бөтөнләй сезден йаҡтағыса эшләмәйләр аны. Сезден йаҡта икенсе төрлө. Үзеңнен өйөндә булған бөтә нәрсәне лә пешерәсен. Баҡсала безнекендә бөтә нәмә лә үсә. Ҡарағат та, балан да, ҡурай жиләге лә, алма да, чейә лә. Слива да, ҡара слива да бар. Бөтөнөсөн дә жыйып чыҡсан, варенье ҡайнатырға була. Ҡызыл ҡарағат та, аҡ ҡарағат та бар.

Элек безнең ауылыбызда ике мәсет булған, хәзер инде мәчетебез йуҡ. Мулларыбыз да йуҡ. Уҡый торған әбейләребез бар ауылда.

Ачыторма, кесеторма. Шуның эченә бал салып, сууҡ тейгәндә ашасаң, ныҡ файзалы. Бөтөн йүтәлгә, салҡын тейгәнгә лә файзасы бар.Без тарелка, ҡашыҡ, ҡалаҡ тибез. Половник – чүмеч, аш чүмече. Чашка – йоморо. Бәлүдә инде блюдцены. Чәй чайнигы тибез.

Безнең мына хәзер бер нейне сөйләйем әле. Бәләкәй чаҡта инде без абыйым белән Ҡамышлы тауына барзыҡ, жиләк жыйырға, хәзер шунда пошой килеп чыҡты. Мин бәләкәйерәк булғанмын инде, абыйым зурыраҡ булды. Без шул пошойзан ҡурҡып, абый мине ағас башына мендереп ултыртты инде. Пошой безнең ниткән йердәрде айаҡлары белән тырмады. Шуңа пошойзоң беззен йаҡта бар икәнен беләм.

Бездә инде гөмбәне жыйалар. Унда теге гөрөздә, нарат гөмбәсе, коричневый төстә бер гөмбә.

Бездә инде хәзер атлар бик асырамайзар. Бер, ике, өч кешелә генә ат. Ҡазылыҡ эшләйбез без, сыйырныҡынан да эшләп була түшенән. Рысь бар. Урман песәйе тигәндәр дә бар.

Божья коровка тигәнде жәмилә тибез. Мин балаларға ла, оноҡларға ла жәмилә тимен.

Буала балыҡ бар. Уларға май салырға кирәкми, үзенен майында жарить итәсен. Карп, щукә, ҡызылғанат, этней бар. Этней – бәләкәй балыҡ, уны төрлө ауылда төрлөчә әйтәләр.

баҡырса – чүмеч, аш чүмече, сынаяҡ – йоморо, сынаяҡ аҫты – бәлүдә, сәйгүн – чәй чайнигы, әсәй – әни, атай – эти, кесе туған – ҡайынһеңле, янағый, сысҡан – тычҡан, крыса – ҡомаҡ.

(Ҡотлоәхмәтова Эльнара Рафиҡ ҡыҙы яҙып алды).

## ҠАМАЙ АУЫЛЫ

**Ғимазетдинов Мөнәүир Мәғнәүи улы, 1957 йылғы** (фотола – һулда)
**Гәрәев Ғүмәр Нәзих улы, 1958 йылғы** (фотола – уңда)

Безнең Ҡамай ауылы Ҡорос сельсоветына керә. Күп кенә йеллар ауылдан ситтә йәшәргә тура килде. Сигезенче кластан соң Бәләбәй педучилищесына уҡырға кердем. Педучилище бөтөрөп, ҡайтып бер йыл Ҡамайҙа укытучы булып эшләнем. Армийанан суң күрше Туҡтағол дигән ауылдағы икенче мәктәпкә күчергә туры килде (уҡытущылар етмәү щәбәпле). Анда бер ничә йыл эшләгәндән соң, директор итеп ҡуйдылар. Ун йеллап шушы вазифала эшләнем. Бөгөн дә шушы вазифала эшләйем.

Ҡамай ауылында, ҡызғаныщҡа ҡаршы, озаҡ йәшәргә туры килмәне, күберәге күрше Туҡтағол ауылында йәшәргә туры килде.

Ике меңенще йылның башларында туҡсанынышы йылның азаҡларында, Мортаза Ғөбәйдуллович Рәхимов президент булган ваҡытта, щыкты "Шәжәрә" дигән әйбер. Минең күңелгә ныҡ йатты, бәләкәй щаҡтан, моғайын, булғандыр. Минең шуның менән щын күңелдән заниматься итәсе киләдер ине. Ул уаҡытта директор

идем, кешеләрне туплап, шул ауылның тарихы, шәжәрәләре белән, архив материаллары жыйып (Уфалағы исторический архивтан, минем ҡыз институтта уҡығанда филфакта, ул миңә помогать итте) Туҡтағол һәм Ҡамай ауыллары хаҡында мәғлүмәт тупладым. Ҡызыҡлысы нәрсәдә: шул материалларны өйрәнә торғащ, минем элекке быуынлар Туҡтағолда йәшәгән булып щыкты. Мин аны ныҡлап белмәйдер инем дә, кешенән ишеткән бар, әлбәттә. Улар ун сигезенще ғасырның икенче йартысында Ҡамайға күщеп килеп ултырған. Безнең быуындың өщ йегете күщеп ултырған да Ҡамайға, беззең быуын шунан дауам итеп киткән. Анда уже эткәй-энкәйләр исән түгел, ә аларның быуынлары бар әле, эткәйнең двоюродныйлары.

Туҡтағол тарихы, бында безнең Мөдәрис Рәхимович дигән уҡытущы бар, шуның менән без бөтөн архивлардан, минеңщә инде, шаҡтый ғына материаллар туплап йазылды. Ә бына Ҡамай тарихына килгәндә инде, мин үземдең ойатыма ҡаршы дисәк тә була инде, аның менән күп шөғөлләнеп булманы, ҡызғаныщҡа ҡаршы. Попутно инде килеп сыҡҡанда, ҡызыҡсына инем. Ауыл халҡы барыбер тик торманы. Бөгөн, әлбәттә, Ҡамайда соңғы йылларда директор булып эшләгән Нуретдинов Науфар Анварович, ул аның менән заниматься итте. Анан соң ауыл йәштәре бер аз материал жыйдылар. Баҡалы районының китабында ла шушылар йазылған.

Әйтеп бөтмәгән нәмәм шул: һәр бер әйберзең башлағанда нигезе була. Бына Туҡтағол ауылының тарихын башлағанда, миңә, случайно, бер ни килеп эләкте. Минең бер элекке уҡущы ҡайтҡанда мынауындай ниләр алып килгән:

– Мөнәүир абый, сезгә мынау кирәкмийме? – ди.

– Ҡайдан алдың? – димен.

– Минем күршелә генә дачала Хажғали Яппаров йәши, – ди.

Случайно уға шулай эләккән. Хажғәли Яппаров – дөмәй шәжәрәсен йазған кеше, йазущы бит инде, “Безнең шәжәрә” дигән китап язып щыҡҡан кеше. Ҡарасам, бында “Челобитная качейка Туктагулово Петру Первому” йазылған. Шуның нийе Российский архивҡа эләккән. Унда шул ваҡытлардағы ваҡиғалар йазылған анда. Нигез ташы Туҡтағолдоҡо шул.

Ҡамайдыҡы инде: Асмондийаровтың “Западные башкиры” дигән китабы бар. Шунда Ҡамай ауылы тарихы турында бер аз материал йазылған. Западные башкиры – ул Баҡалы, Илеш, Шаран районлары. Шунда аларның сөйләшләре йазылған. Татарстан тәьсирендә үзгәреп татарлашҡан. Без таза башҡортща ғына сөйләшмәйбез. Без йарым татарща сөйләшәбез.

Үзем Туҡтағолда директор булып эшләгәндә Уфадан профессорлар килде. Безнең мәктәпкә килделәр, башҡорт ауылы булып щутлана Туҡтағол. Мин шулай тип сөйләнем дә:

– Туҡтағол – бөтөнләй башҡорт ауылы. Без шушы ауылда йәшәйбез. Үзебезне башҡорт милләте итеп тойабыз, тик без щий башҡортлар кебек түгел, аларның ғөрөф-ғәҙәтләрен икенсе төрлө саҡлағанбыҙ уже. Бына шулай йәшәп йатабыз, – тинем.

Шунан теге профессор:

– Бына синең шул “йәшәп йатабыз” дигәнең ул башҡорт инде, – ди. Тором-торомға шундай сүзләр килеп щыға.

Минең энкәй йағынан туғанлар дөмәй башҡортлары. Минең военный билетҡа ла “башҡорт” (башкирин) дип йазылған.

Хәзерге ваҡытта мине нәрсә ҡыуандыра: дин күтәрелде, мәщетләр барлыҡҡа килә, әлеге йәштәр аңа тартылалар. Мин үзем дә – дини кеше, көнөнә биш тапҡыр намаз уҡыйым. Шунысы ҡыуаныщлы: Ҡамайда мәщет салынып бөтеп бара, был безнең ауылдың бөтмәүен күрсәтә, соңғы ваҡытта йаңа өйләр дә барлыҡҡа килә.

Гел сабантуйлар үтә. Анада милли уйынлар уйнатыла: ат щабышы, әлбәттә, атсыз булмай инде бындай байрамлар, ҡапсыҡ суғыщы, көрәш.

СССР-ның соңғы йылларында Сабан йарышлары үткәрелә иде. Анда алдынғы механизаторлар ҡатнаша. Анан сун, безнең электән килгән йолаларзың бересе – ҡаз өмәләре үтә ине (инде бөтеп бара). Ауыл халҡы йыйылышып үткәрәләр: йә бер ощ йыйыла.

Ауылның структурасын әйтмәгәнмен: безнең төп Ҡамай ауылы урман йағынан Ҡорощ йағына барғащ, килеп кергән өлөшө генә Ҡамай ауылы. Анан ауылның зыйаратҡа хәтлемге өлөшө – йаңы Ҡамай. Анда ҡасандыр Ульяновск өлкәсенән мишәр татарлары күщеп килгәнләр. Уларның причинасы, моғайын, Иван Грозный ваҡытында эзәрлекләү булған бит инде. Улар бер урам булып ултырғанлар.

Ҡамай ауылы үзе басҡыщ формасында урынлашҡан: беренсеще – Иске Ҡамай, икенсещеләре – күщеп ултырған халыҡ. Бынан дүрт йөз йыллар элек Ҡорощ ауылы булмаған, элек Баҡалы да булмаған. Булған Ҡамай башҡорт ауылы, Дөмәй башҡорт ауылы, Туҡтағол башҡорт ауылы. Асмондияровтың “Западные башкиры” китабында мишәрләр турында бына нимә дип йазылған: “служилые татары” диелгән. Ҡамайның основной өлөшө – башҡортлар, Татарстандан килгән мищәрләрне улар хезмәткә алғанлар (армийа сафларына). Ҡайсы бересе йегерме биш йыл служить иткән.

Шушынан килеп щыҡҡан да инде “служилые татары”. Шундай ниләре булғащ, уже крещение килмәгән, щөнки государствоға служить иткәнләр и быларға уже тимәгәнләр. Моғайын, шуға ла улар мында күщеп ултырғанлардыр, шушында туҡтағанлардыр, дип уйлайым. Уларның затлары әле дә бар. Минең хатын да шуларның затынан. Әле лә Ҡамайның шул өлөшө – мишәр ощы дип йөрөтөлә. Шул мишәр ощо бөткәщ, Түбән ощ башлана. Улар – Туҡтағолдан күщеп килеп ултырған типтәрләр.

Типтәрләрнең татарлары ла булған, төрлө халыҡтан булғанлар. Типтәр – ул ерен йуғалтҡан ниндәйзер сәбәпләр арҡасында жире бөткән, или былай эшләп йөрөгән, или ҡайда ер бар, шул йерне арендаға алып торған

халыҡ. Был сүзнең ике мәғәнәсе бар, дип аңлата Асмондияров: “дәфтәр” дигәндән килеп щыҡҡан, йә “тибелгән” тигән сүздән. Йерең булмаса, уже йәшәп булмаған. Шул ощ – типтәрләр ощо тип йөрөтөлә. Ни өщен күскәнләр? Туҡтағолда халыҡ күбәйгән, жер үзләренә кәрәк була башлаған. Минең дә потомокларның өщ жигете шулай Ҡамайға беренсе күщеп килеп ултырған кешеләр.

Типтәрләр турында мәғлүмәт бөтен архивтарларда ла бар. Мең туғыз йөз туҡсан бишенще йылда төзелә беренще архив Башҡортостанда. Шуннан башлап, бөтен ниләр дә бар: Ҡамайның башҡортмо, татармы икәнлеге. Анан соң ауыл хужалыгы переписынан да эзләп табырға туры килде.

Безнең халыҡтың электән жирләре күп булған, десятина тип йөрөтелгән, йегермешәр, утызар гектарлы ерле кешеләр дә булған, ат тотҡанлар. Йарлылар да булған. Колхозлашыу уаҡытында бында колхоз барлыҡҡа килгән: башта ике колхоз, анан соң инде зур колхоз итеп берләштергәнләр. Ул уаҡытында районда беренще урынға щыҡҡан. Жирләр бында уңдырышлы – ҡара ерләр. Безнең колхозникларны ВДНХ-ға йебәргән булғанлар Москваға, мидалле, орденлы кешеләр күп булған.

Суғыш уаҡыты йылларында, ауыл халҡы, башҡа ауылдағы кебек, доброволец булып, суғышҡа киткәнләр. Минең ҡартатайны ғына мисал итеп алсаҡ, уны инде принудительно Чиләбегә эшкә йебәргәнләр, трактор заводында эшләгән. Шул уаҡытта суғыш башланған. Бу ҡайтҡан да, суғышҡа китәм дип, шулайтып суғышҡа киткән. 1944 йылдың февралендә үлеп ҡалған (без вестей пропал). Суғыштан исән ҡайтҡанлар тоже билгеле, шуларны барлап, уларға обелиск минең авторствода йасап ҡуйдыҡ мәктәп ихатасында. Директор школы шундый кеше инде ул: нәрсә әйтәсең шуны эшләй торған передовой кеше. Быйыл йаңыдан обелиск эшләдек мрамордан, барсы да үлеп бөтте бит инде. Мин анда килеп доғалар уҡыдым ащҡанда. Матур итеп үткәрдек, райондан кешеләр килде, телевидение.

Мәщет тә асылыу стадийасында тора, йомаларды башлап ебәрдек. Халыҡны йәлеп итәргә иде. Ауылда намаз уҡыщылар да күп: ололар да, йәшләр дә бар. Теләк теләр кәрәк, ни теләсәк – шуны алдыңа килтереп ҡуя да ҡуя. Диндең булыуы ул халыҡны ла берләштерә. Диндең көсө шул хәтлем зур, дип уйлайым үземщә.

Без башҡортща “бармайым”, “ҡайтмайым” дибез. Аның турында бер ҡызыҡлы уаҡиға да бар. Беззең Туктағол ауылынан бер ғаилә Татарстанға кущеп киттеләр, Нижнекамскиға. Балалары шундағы мәктәпкә уҡырға ингән. Татарстандағы уҡытущылар өйрәтә икән:“бармим”, “кайтмим”, “килмим”, “китмим”. Ҡайта да икән бу бала Әлфирә апаға:

– Нәнәй, синең белән үзебезщә сөйәләшәйек әле, – ди икән.

Татарстанға барғащ, кире “бармим”, “кайтмим” дип сөйләшер кәрәк. Анан теге бала:

– Ҡащан Туктағолға ҡайтабыз инде, рәхәтләнеп, “бармайым”, “ҡайтмайым” тип сөйләшер инек, – дип илый икән теге начальный класс баласы.

Ҡайһы бер кешеләр “ҙ” менән һөйләшә, андай халыҡлар бар иде, тик алар бөтеп бара. Хәзерге йәшләр алар татарща ла нащар белә. Тик безнең поколение түгел инде. Безнең поколение “ҙ” тип әйтмәй ине, щөнки безне мәктәпләрдә бөтен Татарстанда щыҡҡан татар китаплары белән уҡыттылар. Татарстан – минең туған илем, дип уҡыйдыр инек. Уҡытущылар ҡасандыр әйтеп йебәрә иде: безнең баш ҡала – Уфа, дип.

Безнең Башҡортостанда ныҡ әйбәт китап нәшриәте бар, үзе щығара бөтен китапларны. Анда библиотекаға ҡай саҡта керәм, фотолары, бөтен нәрсәләре качественный. Бер шунда ултырабыз, бер башҡорт теле уҡытущысы да бар. Мин башҡорт телен уҡытманым, но мин башҡорт телен йараттым, щөнки шәжәрәләр белән күп булыштым, башҡортлар белән дә йәшәнем. Уның белән сөйләшеп киттек тә, мин әйтәм:

– Башҡортса сөйләшкәнде тыңла да, татарща сөйләшкәнде тыңла. Шул хәтлем йағымлы бит ул башҡортноң теле, – дигәйнем, башҡорт теле уҡытущысының китте йөзләре асылып. Бәй, ул кемнең арасында йәшисең – шуның теле йаҡын була. Без бит татарлар арасында йәшәмәдек. Шуға күрә үзебезнең диалект яҡын миңа: бармайым, ҡайтмайым, килмәйем, китмәйем дибез, ә “бармим”, “кайтмим”, “килмим”, “китмим”түгел. Тағы да “йәшәп йатабыз” (“йәшибез” түгел), сөйләшәм (“сүләшәм” түгел), төшмәй (“төшми” түгел). Шулай йарым башҡортща, йарым татарща сөйләшәбез.

Миңа башҡорт халҡының иң оҡшаған нәмәсе – уның бөтөн әйбере открыто. Ҡамай халҡында башҡортноң элекке ҡаны булғащ, ҡапҡаларны, ишекләрне бикләмәй идек. Соңғы уаҡытларда ғына бикләй башладыҡ. Асҡыщны бикләсәк тә шунда ҡапҡа ҡырына элеп ҡуябыз, ә элек вообще бикләп тә тормайлар иде. Хәзер кеше үзенә бикләнә бара, бына шундай ниде юғалтмасҡа иде, дим. Күңел киңлеге – ул бит ныҡ әйбәт әйбер.

Элек суғымны суйалар да, туғанлар жыйылып, аннан кищ көнө ауылда ниндәй туғанлары бар – барысы да йыйылалар шунда. Анда табынға ҡуйалар итне дә, эщ-ҡарынларды алалар, уны да ҡуйалар. Шунда жыйылып, йырлашып ултырыу – ғөрөф-ғәдәт ана шул бит инде ул.

Бездә ошондай сүзләрде ҡулланалар:энәлек – ҡамырлыҡ, муйыл – шоморт, гөлйемеш – гөлжимеш, тәлмәрйен – баҡа, ҡурай еләге – ҡурай еләге, жиләк,ер еләге – ер еләге (*жир жиләге* тип тә әйтәләр), баҡса еләге – баҡща еләге, гөбөргәйел – ташбаҡа, ҡамҡа – тәтәй ҡашыҡ, мөйөш – пощмаҡ, тоҡ – ҡапщыҡ, икмәк – ипи, эпи, (“икмәк” тә бар – ул бер ҡапщыҡ зерно була: “икмәк ҡайта башлады”, “икмәк алырға барам” дибез), күнәк – щиләк, биҙрә, турғай – щыпщыҡ, олатай – ҡартатай.

Өләсәй – аны “ҡартый” диләр бездә, “ҡартаный” диләр тағын. Ана соңғы ваҡытта баллар уже бүтән йерзән дә ишетеп ҡайта микән, “нәнәй” ҙә диләр, безнекеләр бына “ҡартый” диләр. Минең Уфадағы внучка (почти татарща сөйләшмәй инде) ҡартыйын ҡартый ди, ҡартатай озонораҡ бит инде, этәннәде этәннәделә (интекте), шунан соң, “деда” дине лә ҡуйды.

Әсәй – әнкәй. Мин үҙем әнкәй-эткәй тимен, ҡайбер кеше әни-эти зә диләр. Бына безне үзебезне әни-эти диләр, без үзебез әнкәй-эткәй дибез, инәкәй тигәннәр бар.Кесе ҡыз туғанны сеңел, сеңлем дә диләр, сеңлем тип

әйтәләр. Ә былай теге, аның турала сүз барса "шуның сеңлесе", ә үзенә "сеңлем" тип әйтәбез.Ҡусты – энем.Атанан оло кеше – абзый, абый, ағай да диләр. Күп кеше ауылда йартысы "ағай" диләр.Әсәйҙән өлкән кеше – апа, түтәй (керәшендәрҙән килеп кергән сүз "түтәй"), түткәй дә диләр. "Ханым"ны әйтмәйдәр бездә, Татарстанда әйтәләр. Безнең халыҡҡа алай дип әйтсәң, синә аптырап ҡарап тора.

Бүрек – бүрек, эшләпә, кипке (кепка), башлыҡ, теүәтәй.

Боҙҙоң өҫтөндә һыу ҡалҡып сығыу – шәр сығыу.

Бездә урамдарға исем бик үк бирелмәй ул. Әле бирелде ул. Йуғары ощ, Түбән ощ бар инде. Мищәр ощо бар. Йылғаға ҡарап та исем бирелә. Йуғары ощ – ул йылғаның теге ощонда, йуғарыда булғанға, ә тегесе йылғаның аҫҡы ощонда.

Ул йәш сағында ныҡлы иде: малайлардың йуғары ощлар белән түбәнге ощлар сыгышы бар иде. Нәмәкәй бүлешә әлмәгәнбеззер. Мишәр ощо күщеп ултырғандар мишәрләрдән килеп щыҡҡанлар.

Ә бына Ҡорощта Шүпшә ощо бар, унда Ҡамай ощо ла бар, Башҡорт урамы бар, Алмантай урамы. Мында бит төрлө халыклар бар.

Мәсетле рйонында ике йыл эшләдем, Һөләймән ауылында башҡорт теле уҡыттым, шуннан сиксән икенсе йылда менә Ҡатай мәктәбендә башҡорт теле уҡыттым.

Мында кейәүгә сыҡҡас, Ҡатай мәктәбендә башҡорт теле уҡыта башланым. Сөнки һикһән икенсе йылдарҙа әнидә бит инде, етмеш һигеҙенсе йылдарҙа башланылар башҡорт теле. Менә Әбйәлилдән килгән иде Нурия дигән, педучилище бөтөп, ул башлап ебәргәйне, шуннан ул дүрт йыл, ул уаҡытта өс йыл иде бит инде, дүртенсе йылды  башҡорт телен мин алып уҡыта башланым инде. Ошолай итеп утыз дүрт йыл, менә Ҡатайҙа ғына утыз ике йыл башҡорт теле уҡытып, ун дүртенще йылда хаҡлы йалға сыҡтым.

Заманында уҡыта башлағас та, мөнәжәтләр, таҡмаҡлар йыйырға ул уаҡытта бик ҡушалар иде бит инде, бик йөрөп ҡараныҡ инде, ул уаҡытта более-менее әби-бабайлар бар иде әле, хәзер алар үлеп беттө инде. Бер генә апа бар инде безнең, Әлфиә тигән апа, ул более-менее белә, ул библиотекада эшләде. Менә шул апа безне ойоштороп, үзе сценарийҙар йазып, тула өмәсе, ҡаз өмәсе...

Тула өмәсе – кийем басыу. Хәзер башлап йебәрделәр бит Белорет йаҡларында, менә шуны башлап йебәрҙек без, беренщеләр булып. Әлфиә апа үзе библиотекала эшләй иде, үзе сценарийҙар йаззы, безгә үзе элекке йырларны өйрәтеп, суғыш уаҡытындағы таҡмаҡны өйрәтеп, "үзем баба, үзем мужик" диеп, шулай итеп сәхнәлә йырлап, иң беренсе йолаларны башлап ебәрдек, щөнки онотола башлағайны бит инде. Шунан суң, сәхнәлә генә инде, әлбәттә. Менә ҡаз өмәселәрен ошолай итеп инде, спектаклләр ҡуйа инек менә, шулай итеп башлап йебәрдек инде. Шунан Үәрис абый тигән безнең уҡытыущы, физкультура уҡытыущысы, бар ине, Әлфиә апаларҙан, менә, мин өйҙән-өйгә йөрөп, халыҡның уйыннарын өйрәндем. Менә Әлфиә апа бигерәк тә.

(Абдуллина Лилиә Байыҡ ҡыҙы яҙып алды).

## МИРЗӘИТ АУЫЛЫ

### Хәзиев Садирлиман Иҙрис улы, 1932 йылғы

Төрле эштә эшләдем инде. Бәләкәй чакта, бөтөнләй өчөнчө класта укыганда, алып баралар иде чуп утарга бодай басуына. Укытыучы алып бара иде. Шуннан башланды инде эш. Шуннан соң, үсә төшкәч инде, нийгә, нәрсә дип әйтим, көлтә ташырга, печән укытында, печән ташырга эскерт янына китерергә. Малайлар инде, бәләкәй малайлар. Шулай эшләнек. Шуннан көлтәне үгезләр белән ташыдык. Ул укытта аттар чәчүдә инде. Арыш чәчәләр иде. Но ауыр иде инде бала-чагага, жиңел түгел иде. Ауыр булды.

Шуннаң соң, үсә төшкәч инде, көндөз үгезләр белән көлтә ташыйдыр идек. Төннә атлар белән көлтә ташып, көлтәләндертеп, аны кайтартып, эскерткә кысадыр идек. Кышлыкка инде, кыш көнө сугарга икмәкне. Шуннаң соң, балчыкка күмер әзерләр өчөн, урманны йулга чыгара идек, кисеп. Усак, кайын, в основном, кайын агачы әйбәт инде.

Үгезләр белән чыгарадыр идек. Шул малай килеш, ун ике-ун өч йәшлек, ун дүрт йәш булгандыр инде, булса. Шуннаң соң инде үгезләр белән сабан сөрдөк. Ике малай сөрәдер идек жәй көнө. “Черный пар” дип аталадыр иде ансы. Шуны сөрәдер идек. Беребез үгезләрне куып йөрөй, икенчебез сабан итеп йөрөйдер иде. Утызар сотый җир сөрәдер идек. Шуннан шуны, шул җирне ат белән тырмыйдыр идек. Шуннаң соң сука белән аксакаллар чәчәләр иде. Шуннан ат белән йаңыдан тырмайдыр идек теге икмәкне күмәргә. Арыш басуны инде. Шундай тырма тимердән, тимер тырма белән. Шуннан, кыш көнө опять-таки шул нитәдер идек инде. Кызлар да безнең белән көлтә  ташыйлар иде, үгез белән тоже. Хатын-кызлар да безнең белән ташыйлар иде, үгез белән.

Шуннан, кызлар белән ташыганда инде, кызлар белән төйәйдер идек тә, үгезләргә йулга чыгарып куйадыр идек тә, алдан китә бит инде берәр малай үгез белән, уның артынан калган үгезләр. Ә без, кызлар янына үтеп, төйәлеп, йәш укытта, үзегез беләсез, шайарадыр идек инде. Шуннан, кайтып киткәндә, теге кызларның йөгө бәләкәй генә кала бит инде, тегендә малайлар күп булгач. Шунан бушатыр идек тә йаңыдан китәдер идек инде. Ә төннә эскерттә йөрөйдер идек ат менән.

Эскерт әнә шундый формада инде, буйы бер йегерме-утыз метр булгандыр. Бейеклеге бер, ике метр йарым-өч метр булгандыр, дүрт метрлы, может. Шундай көлтәне ыргытадыр идек, көлтәне йалгыш бирсәң, теге өстә торган кеше көлтә белән җибәрәдер иде дальше, суғыштан кайткан кешеләр инде былар. Ачуы килде исә, фурмандан җыгылып төшәсең инде, нишлисең инде. Йаңынан тағы ыргыта башлайсың. Әнә шулай.

Шуннан безнең ауылда начальный школа гына иде, Мирзәиттә. Дүртенче класка ҡәдәр генә. Шуннан, дүрт класс тутыргач, без Мустафага йөрөй башладыҡ. Туғыз километр уҡырға.

Мирзәит дип атала безнең ауыл, нәрсә итеп әйтим? Тәбиғәтнең иң матур пощмагына урыннашкан ул, Мирзәит. Урманға терәлеп тора, уның кай берләре урман кырында гел. Әй, шундай матур ауыл ул. Нийләре дә бар иде, бер-ике чишмәсе дә бар иде, әле дә бар.

Шуннан, Мустафа инде зур ауыл, бездән тугыз километр тора, читтә. Мустафаны белмим, ә Мирзәит кеше исеме белән бәйле. Мең тугыз йөз бишенче йылны Мирзәит дигән кеше үзенең семьясы белән килеп утырган шул Мирзәиткә. Шуннан аның булган иде балалары, семьясы булган. Шуннан бу Фархәбану исемле Мирзәитнең иптәше булган. Бер кызлары булган, Мәрзиә исемле. Шуннаң соң теге Фәрхәбану әбей үлгән бит инде, шуннан икенче кызга өйләнгән, Мәлфә исемне. Шуннан, ул Мәлфәдән бер кызы, өч малайы булган инде мынын. Мәлфә дигән кешенең шул Мирзәит бабайнын кызы Учсынга кейәүгә чыккан. Ә теге малайлары берсе Мөдәрис исемне иде, аңсы Тимадыга эшкә китте инде аның, икенчесе әзерәк колакка каты иде. Ул үз гүмере көтәү көттө инде ауылда. Шул фермада сыйыр көтөүе көттө. Нурислам дигәне бар иде, аңсы армийадан чирләп кайтты, теге припадки иде. Шунда ауылда караулчы булып, борчак карап-мазар, шундай эшкә кушалар иде инде. Төннәрдә куркалар иде инде, теге припадкасы да булгач, жыгыла иде дә, авызынан күбек килеп, шунда йатадыр иде.

Анда теге бүленеш дип төрлө ауылдан жыйылган халык инде. Нийдән, мына, Учсыннаң бер зур семья килгән, дүрт малайы булган аның. Муллағәли дигән исемле кеше. Шуның малайлары килгән, аннаң соң Нуратлыдан килгән ике семья. Әһәлтдин белән Ибрагим дигән. Шуннаң соң Ташыдан килгәннәр. Шуннан Җирекледән Хәйруллиннәр килгән, Басыровлар, тагын Шәнгәрәевлар килгән. Күп кеше килгән. Шуннан Чәкәннән, татар Чәкәннән килгән, Күгәрченнәң килгәннәр күп кенә семья. Күгәрсен, Шаран районынан. Шуннан нийдән килгән мына, Балыклыдан, тимәк, Балкысындан бер семья килгән, Чалпыдан килгән мулла. Мулла булып калды инде ул безнең ауылда. Мине диде, шушы ауыл халкы алып калды. Мине алып китәләр иде, дип тә сүләде инде ул. Грамотный мулла, теге, уҡыған мулла инде ул.

Ике чишмә бар иде, аларның исемнәре йук. Җылга, шул жылгараклар бар иде ауылның ике башында да. Менә хәзер алар буылганнар, берсендә даже балык та бар. Ә күлләр, бер күл бар иде, ул хәзер кипте инде. Элек шунда, нәрсә дип әйтим инде, киндер салып, киндер йөн төшөрөп, шуны талкып, бау ишәләдер иде шунардан.

Как бер семья, бер отказ итеүче да булмады, дүрт йөз гектар җирнең агачын төпләп, шуны чыгын чыгын тигер иткәннәр Мирзәит халкы. Бер ни дә булмаган, отказ-мазар. Шундай дружно эшләгәннәр. Малларын бит инде колхозга биргәннәр, бер караучы да булмаган. Ну, теге йаңа жирдә бит инде оло кешеләр беләләр: икмәк уңа, икмәк бик уңган иде мин бәләкәй уакытта.

Шундай мин бәләкәй уакытларны да сүләрмен. Ул икмәкнең утыз җиделәр-кырыгар центнер булган җирләре да булган басу буйлап. Шуннан халыкка инде, теге колхознын амбарлары халыктан жыелган булған бит инде. Шул амбарлары тулгач, халыкка, нийләр белән, бричка белән, атлар белән өй хаталарына кертеп, аудара торган булганнар утыз сигезенче йылларны.

Кемнәр бара анда, ат шуның исеме белән йөрөйләр иде. Мәсәлән, Каһир биәсе дип, Хужиәхмәт биәсе дип. Шуннан, тагы ниндәйләр аңда... Ак атлары да бар иде. Каралары да бар иде, тура атлар да бар иде. Бездән суғышка да бик күп киткән атлар. Бездә атлар шундай нийләр иде, айырылып тора торган атлар. Шундай нийләр, боевой атлар инде. Шуннаң, бер ун-ун ике ат, нийгә, суғышҡа китте, олар кире ҡайтмады инде. Пәрим биәсе дигән бар иде, менә шуның тайлары бик шәп иде. Комок биә диләр иде, аның да тайлары бик шәп иде. Менә шулар киттеләр инде суғышҡа. Шулар кире ҡайтмадылар инде.

Менә шуннан, нәрсә әйтим инде, колхоз “Чаган түбә” иде исеме колхозның. Шунда бер, урманның бер өлөшөн ҡалдырганнар, специально ҡура жиләге булган болононда. Шунда саклап, кеше кертмәгәннәр. Шуннан ҡура жиләге җитешкәч кенә, кешене кертә торган булганнар. Менә шулай.

Ну хәзер йуҡ инде, алар беттеләр. Йәшелчә бар иде бездә, бик шәп иде. Ана шул мулла шул йәшелчәнең бригадиры иде. Карлыган, кура җиләге, алма, чийә агачлары үсәдер иде. Шуннан кыйар, карбыз, кауын, суған, шалҡан, төрлө чөгөндөр, аш чөгөндөре үстерәләр иде. Ну бик уңадыр иде инде, теге йаңа жир булгач. Бик уңадыр иде. Шуны халыҡка өләшәләр иде, базарга да итеп саталар, халыкка да өләшәләр иде. Шуннан соң, умарталык та бар иде. Умарталыкта, теге, Шәйхрази дигән бер карт бар иде. Шул карт Муллакайдан оло ул, Учсыннан килгән. Бик аҡыллы ҡарт иде шундай. Бер уаҡытта да бер әшәке сүз ишетмәссең аның ауызынан. Шундай, без бәләкәй бит инде, барадыр идек айырткан көнне умарталык йанына. Ул безгә бирәдер иде, кружкага салып, бал. Бала-чага җыйыладыр иде шунда, ул бит интересно инде. Ололар да килеп шунда, рабочийлар да шунда. Ну бал күп буладыр иде, халыкка да саталар иде балны. Бик күп буладыр иде, йөз дә йегермеләп умарта, шуннан шул ҡарт үрчетте, икенче умарталык ачтылар. Ансы гел урман буйында иде, бер километр йарым жыраклыкта.

Умарталык тоткан кешеләр бар, бер биш кеше генә хәзер. Аны, ана шул теге опрыскивать итеп, шул күп бөтөрдө инде, буғай, умарталарны. Шуннан теге Средний Азиядан ҡайткан, китергән умарталарда, умарталарын талыйлар, дип сүләйләр инде. Алар да талый, видимо. Теге, аларга взятка беткәч, менә шул умарталарны тегеләр талый башлай. Кеше айыртып бетерә дә үзенең краннарын, менә шуңардан шулар тегеләрне талыйлар. Алар үзләре кара төстә, но усаллар инде.

Ну хәзер дә осыраучылар бар. Йегерме умарталы бар, но безнең үзебезнең бишәү генә, утыз өчкә җиткән иде... Үзебез карадык иптәш белән, ну иптәш үлгәнгә хәзер инде ун йыл тулып килә. Аҡыллы, сабыр, ул сабырлыҡ бөтөн хатында да булса, хатын-кызда да булса, халыҡ рәхәт йәшәр иде, дим инде. Шул хәтле

сабырлы иде, тыныч, укытыучы иде. Кырык ике йыл математика укыткан иде. Үзем дә укыттым инде. Биологияны.

Безнең йаҡта шушындай сүздәрҙе әйтәләр: һайыҫҡан – саескан, муйыл – шоморт, баҡса еләге – жиләк, ҡайын еләге – жир жиләге

Мәтрүшкә, сары мәтрүшкә, ни, обыкновенный мәтрүшкә бар бит инде. Шуннан соң... Бар үлән – дару үләне инде ул, но без куллана гына белмибез. Былар мына, шомортлар да, ҡура жиләкләр дә, карлығаннар да – барысы да дарулар бит инде алар.

Күп кеше ологайа бардылар. Урманай, Камай, Мирзәит йаңы, ни, Чарлы, Сөйөндөк. Аннаң соң, урыс ауылдары да бар иде. Сумароково, Максимовка, Рождественка, тагын, ний, Заря дигән ауыл бар иде – урыс ауылдар алар. Әзерәк кенә алдан, урыслар чувствовать итеп, видимо, киттеләр бу колхозлар кушылып атлагач.

Әле мына җитәрлек силос салып ҡуйдылар, җитәрлек сенаж салдылар, җитәрлек печән әзерләделәр. Кышка җитәрлек инде шул малга. Мына шуның өчөн минең әйтәсе килә, Мирзәит, менә шул Мирзәит кебек ауылдарга, ну кешесе әз генә, эшче кешеләре әз, шундай ауылдарга бер ун-ун ике йорт салырга кирәк. Шәхәрдәге кебек, йәшләр кайтырлар иде. Аларга бирергә кирәк утыз-утыз биш мең зарплата, менә шул уакытта кайтырлар иде алар. Ә ул йортларны шәхәрдәге кебек салырга, типовой итеп, бөтөн условиясы белән. Шуннан шуларга шул акчаны бирсәң, йортно салсаң, йәшләр кайта ул. Кайтмыйча калмай, ул акчанны бирсәң. Шуннан бер биш елдан соң гына түләй башларга кирәк инде, теге, йортлар өчен. Тегеләр ныгысын өчен.

## ТУҠТАҒОЛ АУЫЛЫ

### Ғәбиәтуллина Рима Нәбиулла ҡыҙы, 1958 йылғы

Әтий, әнийем – Яҡупов Нәбиулла белән Яҡупова Әнисә. Эшсе ғаиләсендә тудым. Хәзерге уаҡытта тормош иптәшемнең фамилиясы белән йәшәйем. Хәзерге уаҡытта лайыҡлы йалдамын. Мәктәптә уҡытучы булып эшләдем, анан инде бер ничә йыл директордың уҡытыу эшләре буйынча йардамчысы булып эшләргә тура килде. Коллектив әйбәт булды. Бик матур, рәхәт, хезмәт сөйә торған коллектив булды, шуға күрә күңелле булды. Хәзерге уаҡытта сағынып искә алам.

Матур шишмәләр бар. Ҡазыған ҡойо дип тә аталған чишмә бар. Бер ничә йыллар элек, йул буйында элеккеге ауыл советы депутаты, председателе булып эшләде Мансуров Айнур Шайнур улы, бик матур урында чишмә ҡазытты, матур итеп ҡоймалатты, йәшләр шунда барып, матур итеп бәйрәмнәр үткәреп, суңыдан жыйыштырып китеп, уйындар уйнап йөрөдөләр. Үзебезнең бик аҡыллы, бик белемле хәзрәтебез бар – Шайхлисламов Флюз хәзрәт. Ул үз инициативасы белән чишмә йасады, ана йардәмләштеләр инде, матур итеп чишмәбездә астыҡ, табыннар әзерләдек.

Ауыл халҡына ғына хас айырым ғына бәйрәмнәр йуҡтыр, тимен. Сөнки бөтә йердә лә шундай дини, милли бәйрәмнәрде үткәрергә тырышалар бит ул, бөтөн ауылда ла. Шул чишмә асылғанда, Чишмә бәйрәме итеп үткәрдек, оло табын әзерләп, оло кешеләр килде, хәйерләр тараттыҡ, матур итеп азаннар әйтте хәзрәт. Бик матур булды.

Анан йәшләр, йәш парлар су йулын башлағанда шунда киләләр ийе. Әлегесе уаҡытта безнең эшҡуарыбыз бар, Гареев Альберт, бик яҡшы итеп эшен алып бара, ауылға күп йардәм итә. Анын йардәме белән ул чишмә төзөкләндерелеп тора, бүтән йаҡка ла йардәме күп инде анын. Йылға арҡылы чит районға, Илеш районына, күперләрне лә башлап салыусы ул. Уға, әлбәттә, йардәмләшәләр. Ауыл халҡын матур итеп ойоштора белгән чағында кеше берсе дә ҡаршы тормай. Безнең бит әле Гильмутдинов Альберт та бар, бик күп маллар асырай, басуларда икмәкләр чәчә, ул икмәкләрне кешеләргә тарата. Сыйыр маллары, мөгөзлө эре терлектәр асырай, ҡош-ҡорт асурачылыҡ белән шөғөлләнә. Аларны суйалар, саталар. Ҡазлар, үрдәкләр, бройлерлар.

Ҡаз өмәләре үткәрелә. Без үзебез дә ишле ҡазлар асырадыҡ, әле мына быйыл ғына әзерәк чирләп, сырхаулап киткәч, ҡазлар ала алмадыҡ. Йөзәр бройлер алабыз үзебез, ҡаз йөзәрне алып, ул ҡазларның тәпиләрен, эчке әйберләрен, бүтәкәсен, йөрәген, бауырын матур ғына аҡ одноразовый тарелкаларға упаковать итеп, полиэтилен белән урап, теләгән кешеләргә хәйердән дә биргәләштердек, кучтәнәчкә лә биргәләштердек, бик йараттылар шул өләшләрне. Анан инде мин бройлерлар тәпиләренән дә, ҡаз тәпиләренән дә холодец йасайым.

Бездә тайикмәк һәм туҡмачлы аш бар. Төш тип тә атайбыз, чәк-чәк тип тә атайбыз. Өчпочмаҡ, бәлеш пешерәбез, бәрәңгеле, итле бәлешләр, жимеш-жиләктән дә пешерәбез. Ҡөрьән ашларына пешерәбез. Ҡара жимеш тә ҡушҡылаштырабыз ҡайсы бер чағында.

Муйылды шоморт тип әйтеп йөрөйбөз инде. Шоморттоң ҡызыл шоморто ла, ҡара шоморт та бар бездә, ҡызыл төстә чийәдән әз генә биләкәй. Ҡайын жиләге бар яланда, урман жиләге уаҡ ҡына. Икесен дә жыябыз, икесенән дә вареньелар ҡайнатабыз, пирогларға тәмле була, киптерәбез, ҡаҡларын йасайбыз.

Опята жыйдыҡ, ис китмәле урынға барып чыҡтыҡ. Шунан гөрөздә, этәч гөмбәсе жыйдыҡ. Шунан волнушка бар, нарат арасында рыжиклар. Иң йаратҡаным минең – опята, икрасын да йасайбыз, мариновать итеп тә ҡуйабыз. Шул ҡәдәр тәмле була.

Ул чигеүләр, челтәр бәйләүләр әле дә бар ул. Мына мин үзем чигеүләр чигәм, чәчкәләр йасайым, төрлө жипләр сатыла бит. Ул чәчкәләрне фольклорный праздниклар булған чағында алып барабыз, күргәзмәгә ҡуйабыз. Килендәшем Рәмнә лә шулай, бик күп әйберләрен алып барды. Ойоҡбашлар, бийәләйләр. Андый әйберләр, әле ҡул эшләре бездең бөтмәде, бар, чигеп кейәбез барыбер да. Чигеүле алйапҡычлар бар.

Бездә шулай әйтәләр. Ҡоҙача, ҡоҙағый, ҡартәтәй, ҡартинәй, нәнәй, оноҡ. Бәбәкәчәйем тибез инде без күберәк.

Без инде йазылғанбыз башҡортлар, рәсми рәүештә башҡортлар исәпләнәбез, шулай булса да безде̦ң жирле сөйләм – татарға йаҡын сөйләм. Ҡушымчалар (*бармай, килмәй)*, бер нисә сүзләр башҡортҡа йаҡын. Жирле диалект булса да, барыбер шул буталыбыраҡ. Бармайлар, килмәйләр. Без уҡыған чағында жирле сөйләм сөйләү телендә булса да, уҡыған дәрес татар теле уҡыдыҡ. Татар телендә бармим, килмим тип сөйләшергә тырыштыҡ дәресләрдә, өйдә икенче төрлө. Өйдә йәшәйештәге сүзләр ҡулланыла. Дәрестә ҡағиҙәгә тайаныбыраҡ сөйләшәсе̦ң. Былай татар телендә сөйләшәбез. Башҡорт телене̦ң сөйләм теленә йаҡыныраҡ, но башҡорт теле түгел инде тел. Бүленешкә килгәндә, Гильметдиндар нәселе тигән әйтеш бар инде ул.

Безне̦ң ауыл Керәшен ауылына йаҡын утырған. Шунда чаҡлы килгәннәр дә крестить итеп, безгә житеп йетә алмағандар бит инде, но жирле сөйләм ҡалған инде.

(Вәлиева Гөлназ Даурат ҡыҙы яҙып алды).

## УРМАНАЙ АУЫЛЫ

### Ваһапова Мөжәһиҙә Фәүхетдин ҡыҙы, 1945 йылғы

Бодайды башта инде аны и̦ң беренче тегермәнгә алып барып тартырға кирәк, он итәргә кирәк. Анна̦ң со̦ң инде икмәктән дә бик күп әйберләр пешерергә була. Оннан инде, тартып кайткач. Чәк-чәк пешерәбез безне̦ң ауылда. Үзем дә мин чәк-чәк пешерәм. Кийаүгә китүче ҡызларға, никахларга чәк-чәкләрне гел мин пешереп бирәдер идем, күмәч пешерәдер идем. Шул оннан инде күп әйберләр пешереп була. Пәрәмәчләр, бәлешләр, тағын нәрсә, гүбәдийәләр – бөтөнөсө шул оннан эшләнә инде. Хворост – ул кош теле дип атала инде бездә. Аны инде шул теге йоморҡаға су белән, йоморҡа белән басасы̦ң да, җәйәсе̦ң дә инде, туҡмач ҡамыры кебек иттереп. Теге үзене̦ң кискече бар, шуны кисәләр дә ҡайнап торған майға салып пешерәсе̦ң. Күпереп пешә инде, шул ҡош теле тип атала бездә.

### Вәлиева Сәлимә Усман ҡыҙы, 1940 йылғы

Жиденче класны бетергәч, Владимир обласына башта торф чығарырға киттем, ике йыл торф чығаруда эшләдем. Унан, торф чыгарудан ҡайтҡач, ний, Урманай ауылына килен булып төштөм, алтмыш беренче йелны. Мирзәиттән. Алтмыш беренче йелны̦ң жигерменче декабрендә килен булып төштөм, алтмыш икене̦ң ун дүртенче ноябрендә фермаға эшкә мендем.

Туҡсан бишенче йылны пенсийаға чыҡтым, сиксән беренче йылдан алып мин Башҡортостанны̦ң заслуженный животноводы. Пенсийаға чыҡҡач, әле сорағанча жардам иттем. Ике йел мин иптәш хатын белән повар булып та эшләп алдыҡ. Кеше йуҡлыҡтан безне файзаландылар. Әйбәт кенә эшләдек инде, ғүмеремдә, нийгә-түр фермаға менеп, пенсийаға киткәнче бер генә йазу: дойарка булдым мин. Дойарка булып эшләдем. “Заслуженный работник” грамоталарым бик күп. Дипломнар ҙа бар.

Сыйырларны̦ң барысыны̦ң да исемнәре бар иде. Менә инде хәзер пенсийаға чыҡҡанға егерме биш йыл, исемнәре берсе генә дә онотолмаған. Матур ҡызыл сыйыр – Невидимка. Менә анда Чәчкә дә Гүзәл, Җиләк, Шоморт. Шундый исемнәре, үзебез теләгәнчә исемнәрне ҡушабыз инде.

Сыйырны̦ң ҡайсысы чуар була, ҡайсысы ҡара точкалы, ҡайсысы ҡызыл була, ҡайсысы бик ты̦ңнаусыз да, әнә шул Невидимкасы. Эйе, шул төсләрне ҡарабырак та ҡушадыр идек инде. Чуар, ҡызгылт, ҡара чуарлар да бар иде, бар иде, төрлөсө бар иде. Әйе, тимгелде, тим, ҡара чуар тимгелде инде.

Бозаузарын без тыугачтын атап тормайдыр идек. Өч көн эчерәдер идек тә, бозау ҡараучыға бирәдер идек. Бозау ҡараучылар алып, алар ҡарайдыр иде бозауларны. Буаз сыйырларны “родительный” йаҡҡа кертеп ҡуйадыр идек. Шунда бозаулай да, шунда өч көн имезәбез дә, нийгә, бозау ҡараучыларға бирәдер идек. Бозау ҡараучылар ҡарайдыр иде.

Мөгөз, гәүдә, бүксә, койрок, айаклар, күзләр, тагы инде. Күзләре барысыны̦ң да бер төслөрәк инде. Бер төслө. Хайван – хайван инде.

Сөтне бит без шунда холодильник артына чыгарып тултырабыз да, маслозаводка йебәрәләр. Без сөт белән заниматься итмәйбез. Өйдә уны̦ң эремчеген дә йасайсы̦ң, катыгын да, сметанасын да йасайсы̦ң, сырын да. Өйдә эшләтергә бик эше күп аны̦ң. Буткаға кушасы̦ң, тәтле ҡамыр рыйзыкларына да ҡушасы̦ң, тәикмәккә, коймакка да кушасы̦ң. Эремчектән бик әйбәтләп кенә пирог пешерәсе̦ң.

Пилмән инде – пилмән просто, уак кына итеп эшлисе̦ң дә, шулпада пешереп алып, майда кыздырып та аласы̦ң.

Сауганда җырлай идек инде, хәзер җырлап онотолгандыр да инде, пожалуй. Андагылары онотолган инде. Туҡта, тамағым йуҡ бит әле! Хәзер инде бит сиксәндә, туғаным...

Үзем алмагачлар булсам,  
Ал чәчәк атар идем.  
Атлап түгел, йәшлегемә  
Йөгереп кайтыр идем.  
Атлап түгел, йәшлегемә  
Йөгереп кайтыр идем.

Менә кызыкмы ул, кызганышмы, бер вакига булды. Йал көнө безнең... Без җәйаү йөрөйбез фермага. Нийдә йылға безнең, айак очонда йылга. Йаз көннө йылга туңған. Кыш көнө бәке тишелгән, хәзер су ага, караңгыда, безнеңчә, башкортча, биштә фермага китәргә кирәк. Бакчага менә төштөм дә мин, фермага китәйем дип, йылга аркылы чыкканда, теге бәкегә төштөм дә киттем йазгы суга. Менә сиңә кызык. Бер дә мин, суга баттым дип, эшне ташламадым, кабат кайтып кейендем дә фермага киттем. Менә. Шул истә калган менә, үткәне. Үзәккә үткәне, бигерәк тә.

Тош пешерәбез. Майны без йазабыз, май итәбез, аннан сары май итәбез, эретеп. Бүтән төрлөләрен эшләмәйбез без, ул уакытта бүтән төрлөләргә бүлергә безнең уакыт та булмады, эш күп булды. Эретеп теге сары майга чийә йә йөзөмнәр кушып, тутырып куйасың, нитеп, боталып. Аннан тәмне була, кышкылыкка. Кар базына куйасың. Элек бит суыткычлар да бик йук иде.

## УТАР АУЫЛЫ

### Полякова Елизавета Николаевна, 1948 йылғы

Иптәшем менән был ауылда йәшибез. Дүрт ир бала үстердек, барсы да армийа сафтарында йөреп кайтты. Ошо ауылда тыуып үстем. Мең туғыз йөз туксан беренче йылда "Дуслык" фольклор ансамбленың ойоштороусыһы булдым. Хәзер бу эшне Васильцова Юлия Григорьевна давам итә, ансамблде йетәкләй. Ансамблгә бу костюмнарны безнең спонсор Чернов Альберт Павлович тектерде, зур рәхмәтлебез аңа. Жырлап йөрөйбез шушы костюмнар белән, бөтән мероприятиеларда катнашып.

Утар ауылы Утар су буйынан килгән. Ауыл халкы Сөн, Мәләде жылғалары буйын сайлап, шушында урынлашкан. Элек ауыл тау башында щокор буйында булған. Мең туғыз йөз бишенче-мең туғыз йөз сигезенче йылларда Иске ауылдан шунында күскәннәр, жылға буйына урынлашканнар. Табиғатебез бик матур, урманнар бай. "Утрау сымак урынлашкан" тип әйткәндәре очен, ауылыбыз Утар дигән исем алған.

Йолаларга килгәндә "Пасха" үткәрәбез, беззен ауыл православный ауыл. Бәйрәмнәрде зурлап үткәрәбез. Йыл башында Рождество, Пасха, Троица, Язғы Миколы, Көзгө Микулы үткәрәбез. Шулау ук өч төрлө Спас: Медовый, Яблочный, Ореховый спас кеүек оло бәйрәмдәр зурлап үткәрәбез.

Көз көнө бөтөн эшләр бөткәщ, Рәт ашы булған – берсеннән берсенә йөрөп кунӑк булғаннар, ашка алыш.

Рождествонан соң бездә Нардуған бәйрәме бар. Январның жидесенән башлап ун дүртенә кадәр. Ун дүрте көннө көндөз матур итеп, төрлөщә кейенеп, өйдән-өйгә бер-беребезгә көндөз йөрөшәбез, матур теләкләр теләп, ашлыклар сибеп. Йаңы йылдағы сымак төрлөщә кийенәләр, хайуан булып та кийенәләр, танытмаска тырышалар, Кыш бабай белән Кар кызы ла була. Ололар да, балалар да йөрөп, тик хәзер сирәкләнә бара. Элеккещә үк түгел.

Сөн жылғасы аға безнең йакка, Мәләде жылгасы килә. Утар шишмәсе бар. Наратлык шишмәсе аға. Йәш сакта көйәнтә менән шунда йөрий торгайнык. Кызлар тауы бар ауыл каршысында. Элек-электән йәшләр – кызлар, йегетләр шунда менеп уйнай торған, күңел аса торган булғаннар. Әле булса да анда жиләк шәп үсә. Болон тауы бар, бала-щаға уйнарға йарата, кыш сана шыуалар.

Исемнәр бездә кушамат менән йөрей: Степан – Чтапан, Григорий – Гөргөрөй, Грешкә, Ульяна – Үкелей, Евдокия – Жаудый, Ольга – Үлге, Анастасия – Нащта, Наталья – Натый, Николай – Кәрдәй Миколай, Мығый Миколай.

Куштабак – ущтауыщ, жулпыш – он салып иләй торган сауыт, гөбә – мал яза торган сауыт, нарат – шыршы, щиләк – күнәк, күке – кәкүк, инәй – әсәй, этий – атай, өләсәй (атай яғынан) – әбий, нәнәй, олатай (атай яғынан) – бабай, өләсәй (әсәй яғынан) – жырак әбей, олатай (әсәй яғынан) – жырак бабай.

(Абдуллина Лилиә Байык кызы яҙып алды).

## ҮШТЕМ АУЫЛЫ

### Исламова Нәзирә Нурлығаян кыҙы, 1947 йылғы

Муллалар күп булған. Сит ауылға барып йөрөгәннәр. Нуркаев Талип бар инде. Советтар Союзы Геройы.

Нөркәй урамы, Центральный (Үзәк урам), Жылға урамы бар. Жылға урамында урам бар. Талип урамы ла бар. Йылғада балыклар күп. Ташбаш, щукә һ.б.

Кызлар тауында бала-сағa унда уйнай әле. Бөтә йакын ауылдар күренеп тора. Элек ситкә кызларны йебәрмәгәннәр. Бер-бересенә туған булып йәшәйбеҙ. Нурлығайан ағай була ине. Әкәмәт уйлап щығарып сөйләй ине.

Кушаматлар: Советтар әкиәсе, Ғәлимә әкиәсе, Нәкиә әкиәсе, Яппар әкиәсе. Бер осорҙа туғаннар.

Күрше ауылда Нәкиә әвей бар ийе. Минең балам бер сутка иланы. Өшкөргәйне, су, жирде өшкөрөп бирде. Кара кешенең күзе тейгән, ди. Бала азак бер сутка йоклады. Ул әбей үлеп китте ийе.

Мунса эйәһе малды йаратмаса, мал шыбыр суға бата. Безнең кара сыйыр бар иде. Тынғысызлана. Ул сыйырны саттык ийе. Су инәсе йук. Быуа киткәщ, балык йук ийе.

Әүер бавай сана йасай. Ул әле лә йасай. Ат жигә торған. Бәләкәй итеп эшләгән берәүне, музейға, ди.

Атлар аз: айғыр, бейә, күк, төнә, аклы-карасы.

Аш-су төрләренән чәк-чәк, тайикмәк бар. Ыумащ – шурма. Борщаҡ ашына шурма салалар иде.

Мин килен булып төшкәщ, күрше әбей щаҡыра иде. Табаҡка ике щүмешшалынған ашны күрдем. Тиз генә аша да, шыҡ, ди. Шуны онотмайым. Рәхмәт инде аларға.

Исламовлар, Ханнановлар ауылда күп. Хайруллинлар бар. Шамсутдиновлар бар.

Сары мәтрүшкә, көрән мәтрүшкә, жул япрағы, ҡарлыған йапрағы, ҡурай еләге йапрағы, ҡызыл баш – клевер йыйабыз. Бәрәнге лә үстерәбез. Баҡса да тотабыз. Борощ та үстерәбез.

Ҡорот йуҡ. Ҡатыҡ, эремчек, сөт, ҡызыл эремчек бар.

Бала чакта сәсне ҡатык белән йыуа идек. Сигез ҡыз үстек. Көл салып, су алып ҡайната идек. Селтә дип атала.

Лапсан күлдәк кейәбез. Лапсан – ул ҡаты тәбиғәтле, йомроланмай торған тукыма. Йылы нәски – жөннәски, диләр. Әле лә бәйләйбез. Биш энә менән бәйләйбез. Орсоҡ менән жөн әзерләйсең.

Атай – эткәй, әсәй – энкәй, олатай – бабыҡай, ҡарт бавай, өләсәй – әбей, энекәй, нәнәйкә, ҡәйнә – бианай, ҡайны – биатай, ейән, ейәнсәр – онуҡлар, бүлә – туран.

(Хужахмәтов Айнур Оскар улы яҙып алды).

## ШЫУҒАН АУЫЛЫ

**Ғилязева Гадавия Абзал ҡыҙы, 1943 йылғы** (фотола – һулдан өсөнсө)
**Нәбиуллина Афида Ғәйнетдин ҡыҙы, 1928 йылғы** (фотола – уңда)
**Зыяҡаева Миннизифа Хөсәйен ҡыҙы, 1956 йылғы** (фотола – һулдан икенсе)

**Ғилязева Гадавия Абзал ҡыҙы**: Уҡыдым ауылда. Өч кенә класс укыдым, йығылып, бүтән укый алманым. Бер йыл Уфала больниста йаттым айаҡ белән. Малай, килен бар. Озаҡ йылны шкулда техничка булып эшләдем, биш йыл. Шуның белән пенсийаға чыҡтым. Пенсийа шул инде, минимальный. Балаларым минеке берәү генә, өйзә икәү бергә торабыз. Малай, килен. Внук Себердә, внучка укып чыкты.

Аттар айырыла. Олорағын тай тиләр. Ат ни, барсы да бер төслө түгел инде, ағы да бар, ҡарасы да, рыжий.

Йомаҡ: пич астында бызау йеүеш – тел. Бәләкәй генә чүлмәгем, тәмле булды чүмәрем.

гөлйемеш – гөлжимеш, муйыл – шоморт, ташбаҡа – ташбаҡа, тоҡ – ҡапчыҡ, күнәк – бидрә, турғай – чыпчыҡ, боҙ өҫтөнә сыҡҡан һыу – шәре, сәтләүек – чикләвек.

**Нәбиуллина Афида Ғәйнетдин ҡыҙы:** Мин колхозда разнорабочий. Ике йыл ғына укыдым русча, өчөнчө белән дүртенчене ҡабатладым. Мин Саҡмағош районыныҡы, Байбулат ауылыныҡы, анда дүрт класс бөтөрөп килдем Баҡалы районына. Әтәй белән инәйләр мында күчтеләр дә, мин алар белән килдем. Мында килгәчтен өчөнчө белән дүртенчене русса ҡабатладым, анан укый алмадым, суғыш сыҡты. Утыз туғызынчы йылны килдек Шүгәнгә, анан суң суғыш чыҡкач, мин укый алмадым. Дүрт класс бөтөргән көйө ҡалдым. Анан, инәйләргә эйәреп, эш башладыҡ. Утауға эйәреп йөрөп, анар суң ҡырҡ өсөнчө йылны по вербовке киттек Ленинградский областҡа, торнға барҙым. Ҡырҡ өч-ҡырҡ дүртенче йылны анда булдым. Ҡырҡ бишенче йыл суғыш бөткәндә, мин анда ийем. Шунан беззе ҡайтарзылар отпускыға, беззең договор биш йыллыҡ ийе, ике йылдан суң ҡайттыҡ отпускыға. Ә безне бында ҡайтканчы икенче кешеләр тип, ә без ҡалдыҡ бер документсыз. Бер документым йуҡ анда эшләгәнгә. Шуны эзләйбез әле. Кешеләргә медаль бирделәр, ә миңә медаль йуҡ, что мин эшләмәгәнмен колхозда. Шунан ҡайтҡач, инде нейзә, колхозда, анан ҡырҡ сигезенче йылны бабай белән өйләнештек, анан суң дүрт балам булды, шунан разнорабочий. Ике ҡызым, ике малайым бар. Ике ҡызым Уфада, икесе дә пенсийада хәзер, берсе Михайловкада учитель булып эшләй шкулда, берсе үзем белән йәшәй.

**Зыяҡаева Миннизифа Хөсәйен ҡыҙы:** Ҡартәтәй – олатай, ҡартинәй – өләсәй, энем – ҡустым, баҡа – баҡа, почмаҡ – мөйөш, сынаяҡ – жоморо, бәлүдә, ужау – баҡырса, аш сүмесе.

Минең ике ҡызым: берсе Себердә, Нефтеюганскийдә, берсе мында Баҡалыда. Өч внугым бар.

(Ҡотлоәхмәтова Эльнара Рафиҡ ҡыҙы яҙып алды).

## ЯҢЫ ҠАТАЙ АУЫЛЫ

**Шәмсутдинова Гөлсинә Әнис ҡыҙы, 1966 йылғы**

Жиргә кеше тыуа, эти-әни йанында үсә. Анан үзе ғаилә ҡора. Уаҡыт щаба. Шулай быуынлар алмашына. Безнең бурыщыбыз үткәннәрде барлап, киләщәк быуынға тапшырырға.

Район үзәге Бакалыдан сигез щаҡрым йыраҡлыкта тәбиғәтнең иң матур төбәгендә урнлашҡан Ҡатай ауылының дә матур үткәне бар. Ауылдың үткәне – ул ата-бабаларыбызның йәшәйеше, ололар ҡатнашҡан уаҡиғалар, уларның тормош йулы.

Һәр йылны сабантуй үткәрелә.

Хәдерге уаҡыттағы сайлаулар зур бәйрәм итеп үткәрелә, концерт программалары белән. Шунан соң, Өлкәннәр көнө һәр йылны үткәрелә. Быйыл беренще октябрзә була. Сигезенще март бәйрәме ауыл хатын-ҡызларын жыйып үткәрелә. Былар бит бар жирдә лә бар әйбер түгел бит.

Жиренә житкереп туйлар үткәрелә. Туй йоласы элеккещә кеүек булмаса да инде, никах матур итеп ҡыз йағында укытыла. Ауылда ике мәщет бар. Никахтан соң йәшләр обязательно мәщеткә баралар. Азаҡтан инде

туй сразу була. Сразу булмаса да жигет ҡызны алырға килә. Шулай уйын-көлкө белән ҡыз сатыу була. Шишмәгә су йулы күрсәтеүләр бар киленгә. Ул йолалар саҡлана әле ауылыбызда.

Элек Ҡатайда мийещ щығарущылар күп булған. Алар барсы да ана шул Күчүм нәселенән булған. Уларның барсы да мәрхүм, Кучүмов Мөстәким абый исән. Мийещ щығарып бөткән дә, ул оста байанщы, түбәгә менеп, байанда уйнап, жырлап ултыра торған ғәдәте булған. Әле саман да аны Ҡатайлар сағынып искә алалар инде.

Атамаларға килгәндә, Бащыу шишмәсе бар инде. Халыҡ шул шишмәгә суға барған. Басыу уртасындағы шишмә, бик матур итеп уратып алынған, анда оло самауыр ҡуйылған, "Бащыу сисмәсе" дип йазып ҡуйылған. Бюджет работниклары постоянно барып щистартабыз.

Ҡирәмәт тауы бар. Аны марилар табыныу урыны, изге урын дип атағанлар. Пионер уыҡытында һәр йылны 19 майда пионерлар кищтән щығып, костер яндырыр булған. Ул ғәдәтне йәшләр әле лә дауам итә. Тирә-йаҡтан ҡунаҡ-фәлән килсә инде, без шул тауға алып менәбез. Унан бөтөн Ҡатай ущ төбөндәгеләй генә күренә. На самом деле Ҡатай бик матур ауыл ул, гел урман арасында.

Балыҡлар бар. Уфалардан, щиттән киләләр. Ауыл халҡының аға уаҡыты йуҡ. Без унда бер дә су керергә уаҡыт таба алмайбыз, эш күп. Шул жиләккә барғанда айаҡ жууып сыҡсаҡ ҡына.

Тағы "Бикләнде" дигән атама бар бит инде.

Туҡмаҡлы шишмәсе, Салҡын шишмә бар.

Безнең урам Щейәле ҡул дип атала. Элек анда щейәлек булған.

Назыулат щоҡоро бар. Историясын бер дә белмәймен. Өлкәнләрдән сорап ҡарадым.

Элек, мин килгәндә, күберәк "ç", "ҙ" хәрефтәрен ҡушып сөйләшәләр ине – "Ҙәлифә", "Ҙәңгәр", "Çыйыр" тип сөйләшәләр ине. Хәзер алай дип сөйләшеүсе йуҡ. Хәзер балалар тик русща сөйләшә. Мин аларға викториналар үткәрәм, алар миңа русща отвечать итәләр.

Мин узем Татарстан йағынныкы. Аҡтаныш ҡызымын. Минең ата-бабалар башта Борай районына килеп ултырғанлар, шунан малайзары батып үлә лә Ағизел буйында, күсеп китәләр. Щуҡындырыузан ҡащып килгәнләр. Ауылның шул йағы үзенщәлекле: син башҡорт, син татар дигән кеше йуҡ. Ауыл бик дус йаший. Бездә ике тел уҡытыла: татар теле, башҡорт теле.

Йәнлектәргә килгәндә, төлке күп бездә, бүре. Айыу күренмәй бик, техниканан ҡурҡалыр, ҡасышып бөткәннәр. Пышыйлар йыш осрай.

Сынаяҡ – йомро, сынаяҡ аçты – бәлүдә, чәщке асты, әрләй – тиргәй, насар – әщәке, баҡырса – сүмещ, тәйикмәк – ҡоймаҡ, сәк-сәк – төш, сәк-сәк, бәлеш – бәрәңге тәкәсе, әсәй, атай – әни (инәй), эти; эткәй, энкәй, инәкәй, өләсәй, ҡартатай – ҡызның әни-этисе – әби, бабай, этидекен – ҡартый, ҡартатай, атайҙан оло кеше – зуринәй, зуратай, зүрнәй, зүрәтей, абзатай, абзинәй, әсәйҙән оло кеше – щибәр апа (йәшерәген), туған апа (иң олосо), иркә апа, туған апа.

(Абдуллина Лилиә Байыҡ ҡыҙы яҙып алды)

## Баҡалы районының ерле һөйләш үҙенсәлектәре

Баҡалы районы үҙенең һөйләш үҙенсәлектәре буйынса төньяҡ-көнбайыш диалекттың түбәнге ағиҙел-ыҡ һөйләшенә ҡарай. Баҡалы районы ерлегендә һөйләштең түбәндәге тел үҙенсәлектәрен билдәләп үтергә мөмкин.

Фонетика өлкәһендә. Был бүлектә һүҙ составындағы телмәр өндәренең әҙәби тел менән айырмалы яҡтары күрһәтелеп үтелә.

Һуҙынҡы фонемалар системаһында ерле һөйләш үҙенсәлектәре ҙур сағылыш тапмаған. Бында О – Ы күсешен күрһәтергә мөмкин: *бозау – быҙау.* Айырым һүҙҙәрҙә *ж* тартынҡыһынан һуң әҙәби *е* өнө урынына *и* һуҙынҡыһы ҡулланыла: *жиде – ете, жингәй – енгәй, җир – ер, жигерме – егерме.*

Тартынҡы өндәр системаһында һөйләш үҙенсәлектәре киң таралған. Бында башҡорт теленең үҙенсәкле *һ* өнө һөйләштә *с* фонемаһына күсеүе төп диалект билдәләренең береһе булып тора: *сандуғач – һандуғас,сандыҡ – һандыҡ,сыйыр саудыҡ – һыйыр һауҙыҡ, сук – һуҡ,сөт – һөт, су – һыу.* Миçалдарҙан күренеүенсә, бында һүҙ башындағы күсеш бирелгән. Шулай уҡ *с – һ* өндәренең сиратлашыуы һүҙ нигеҙенә 3-сө зат эйәлек категорияһы аффиксы ҡушылғанда ла күҙәтелә. Мәçәлән, *һыу инәсе – һыу инәһе, апасы – апаһы,уртасы – уртаһы, шишмәсе – шишмәһе, уртасы – уртаһы.* Ошо уҡ фонетик күренеш ҡылым һөйкәлештәре яһалышында осрай: *ҡалмасын – ҡалмаһын, кубәйсен – кубәйһен* (бойороҡ һөйкәлеше), *әрләшсә – әрләшһә, кутәрелсә – кутәрелһә, еңмәсәң – еңмәһәң* (шарт һөйкәлеше), *төшәсен – төшәһең, курсәтә – курһәтә* (хәбәр һөйкәлеше).

Күп кенә һүҙҙәрҙә башҡорт әҙәби телендәге *ҙ* өнө һөйләштә *з* фонемаһына күсә: *зур – ҙур, хезмәт – хеҙмәт, беззең – беҙҙең, намаз – намаҙ, үзем – үҙем, хәзер – хәҙер, аз – аҙ.*

Башҡорт теленең үҙенә генә хас *ç* өнө түбәнге ағиҙел-ыҡ һөйләшендә *с* фонемаһына күсә: *өстәл – өçтәл, дуçлыҡ – дуслыҡ, басыу – баçыу, асрайбыз – аçрайбыҙ, палас – балаç.*

Бәшмәк – бездә гөмбә. Бездә лисички бар. Шунан суң рыжики жыйабыз без. Ҡайын гөмбәсе бар. Әле опятаға уже барып булмый, айулар йөрөгәч, без урманға бара алмайбыз. Гөмбәгә йөрөдөк тә, но бездең йаҡта айу күп. Безде айулар басты. Туҡсан алтынчы-туҡсан жетенче жылдамы мынанда питомник бар ине безнең, шушы питомникта Рәхимкүл тигән ауылдан бал ҡортларын китереп ултырттылар. Анда нападать итә башлағас айулар, теге айулар безнең йаҡҡа күчтеләр, хәзер бездә айу күп. Кешегә ташланғаннары йуҡ былай. Үзебез гөмбәгә менгән инек опята ҡарарға, уже аларның йатҡан урындары бар. Мынанда Яңы Уразай тигән ауыл да бар. Тау башында бөтәсе лә, әллә ничәсе йатҡандыр тидәр, бөтөнләй туҡлауыҡ йасап бөтөргәндәр. Туҡлауыҡ – анда тапап бөтөргәннәр. Бүреләр дә бар. Әле бездең күптән түгел ана шушы айу бер кешенең ике сарығын ботарлаған. Беренче көннө күреп кенә ҡайтҡан, алып ҡайтмаған, шунан суң икенче көннө барған, уже теге үләксәләре йуҡ, ти. Алып китеп, күмеп ҡуа, диләр бит. Шундый хәлләр. Мин питомникта ла эшләп алдым, почтальон булып ун ике генә йыл эшләйем, анарға хәтлем туғыз йыл питомникта эшләдем. Шушы питомникта эшләгәндә болан ҡаршыма килеп чыҡты, ул миңәргә ҡарай, мин уңарға ҡарайым. Шунан суң бер-беребезгә ҡарашып тордоҡ та, ул китте үз йулына, мин киттем үз йулыма. Мына шушы айу эзләре мына шулай йаталар ине, баласы ла бар ине. Безне питомникҡа барғанда озатып бара ине, йуллары бар, шунда китәләр ине ул айулар. Жиләк тә ашыйлар, ҡурай жиләге лә ашыйлар. Ул анда хикмәт ул, бер йағында син жыйасың, икенче йағында шатыр-шотор килә бит инде, ансы айудыр тисең, өндәшмәй, тын ғына, үз йулыңнан китәсең.

Мәтрүшкә жыйабыз, ҡайын жиләгенең йапрағын жыйам мин, шунан суң әле клеверның башын жыйдым. Ансы ҡолаҡ шаулауларын бетерә, баш ауыртҡанын да әйбәтли. Зәңгәр чичкәле – василек, гөлжимеш жыйдым. Шуларны ҡулланам мин.

Лопухны әрекмән дибез. Әрекмән тамыры, андыз тамыры да жыйам мин. Андыз тамыры иммунитетты ла күтәрә ул, йөрәккә хәл кертә. Русса девясил буладыр ул.

(Ҡотлоәхмәтова Эльнара Рафиҡ ҡыҙы яҙып алды).

**Гәрәева Рәфиҙә Әсхәт ҡыҙы, 1956 йылғы**

Алтмыш дүрт йәштәмен. Бу ауылдың килене. Күрше ауылдан килдем. Көнтуыш ауылында инде ҡырҡ биш йыл. Нәрсә тип әйтәйем. Почтала начальник отделения булып эшләнем. Шунан пенсияға чыҡтым. Өч балам бар. Шушы ауылда йәшәйем.

Минең белеүем буйынча инде, был Көнтуыш ауылына мең дә жите йөз житмешенсе-сиксән бишенче йылларда нигез салынған. Сездең тип әйтәйем, БГУ-ла уҡыта безнең Рәиф Әмиров, әле эшләйдерме инде, ул үзе Ҡолой Балтачтан. Шул Ҡолой Балтачның дүрт малайының берсе Көнтуышҡа килеп ултырған булған. Ниләре инде, зур сулар йуҡ инде бында. Кече Мата, Оло Мата тигән йылғабыз бар. Аның суы бик йомшаҡ. Суңғы йылларда бигерәк тә урман эченән чыҡҡан шишмә суы – ул бигерәк йомшаҡ су ул, бик тәмле су. Шушы йылларда инде туҡсанынсы йыллардан суң, быуалар быуып, йал итәргә бик матур быуалар булды. Балыҡлар жибәреп. Но урманға бай йаҡ бездә. Жимеш-жиләккә бай йаҡ, гөмбәләр – барсы ла бар. Урманыбыз бик матур. Төрлө урман, төрлө ағачлар үсә. Жәнлектәребез – айыуларыбыз, бүреләребез дә бар. Балыҡлар ғына түгел.

Башҡортостанда ниндәй жимеш-жиләкләр бар, барсы ла бездең урманда бар. Ҡурай жиләге бар бездә. Миләше, баланы күп, ҡарағаты. Шунан суң бәләкәй чаҡта әйтәләр ине, ҡайын жиләге, тип әйтәләр ине. Ул

облепиха булған. Сырғанаҡ. Бына ул да бар бездә. Бөрлөгән бездә əз. Но ҡайын жиләк күп. Йөрәк өчөн файдалы жиләк. Бездә инде гөмбә... Мин үзем гөмбәче түгел. Но гөмбәгә тирә-йаҡтан да киләләр. Гөмбә – ул бәшмәк. Бына аҡ гөмбә, тиләр, груздь бар бездә, шуңа әтәч гөмбәсе тиләр бездә, бына оранжевый төстә. Мин гөмбәсе түгел, шуға әйтә алмайым. Тағы урмандың тағы бездә элек-электән бына урман ултыртырға посадкалар бездә үстерәләр ине. Башҡортостандың күп районларына алып китәләр ине. Нәрсә әйтәйем тағы. Жәнлектәр барсы ла бар: ҡуйаны, төлкөсө, әйткәнемчә, айыу, бүресе. Ауылға зыйан килтергәнләре йуҡ. Тыныч ҡына.

Дауа үләндәре жыйабыз үзебез белгәнләрне. Мәтрүшкә тибез бит инде. Сарыс та, түрәме лә бар бездә. Улар ике төрлө. Шунан суң, үгәй анай йапрағы тип әйтәбез, шунан меңйапраҡ. Бына ҡомаҡ бар. Үләнләр күп. Ҡуллана белгән кешегә. Ауыл, шишмә буйында мелисса. Ул йаҡка бай йаҡ безнең йаҡ.

Шомортно уны безнең халыҡ элек-электән йорт тирәсенә ултырткан. Һәр беребездә миләш, балан, су буйларда алмалар ултыртыу инде. Ул элек-электән бездә булған. Ҡарағат, шоморт, балан, йүкә урманлары бар. Бездә өч-дүрт кеше ҡорт асрай. Бал ҡорто әйбәт тәбиғәтле жирдә генә уңа бит инде.

Жиләк жыйыуға бергә йөрөүчән инек. Баланға йөрөйбез. Тыныч безнең ауыл. Тәбиғәте бик матур. Жәй көнө бигерәк матур. Шулай йәшәп йатабыҙ, но ауыл ҡартайҙы инде. Бездән йәшләр бик əз.

Туғанлыҡ атамалары бездә төрлөчә әйтелә. Күбесенчә инәй, әтәй, тип әйтелә. Безнең ауылда әнкәй, әткәй, тип әйтелә инде. Шунан суң инәкәй, әтәкәй тигән кешеләр ҙә бар. Әтей, әней тигәне лә бар. Бабушка, дедушка – зүрәтәй, зүрәнкәй. Дәүәтей, дәүәней. Элек ҡартинәй, ҡартәтәй.

Минең племяницам, ағинәй, ти. Ә бездә ағәбей, тиҙәр. Ағәбей, аҡбабай. Чибәрәбей, чибәрбабай. Шунан йыраҡәбей, йыраҡбабай. Элегерәк әйтәләр ине абызәбей, абызбабай. Уҡығаныраҡ, олораҡ кешеләргә. Абый, апа, жиңгәшәй. Кеселәргә исеме белән. Энем тип әйтәбез. Сеңлем. Ә иремнең әнкәсенә – әнкәй, әткәй тинек. Барыбер. Минекеләргә ул да шулай әйтә. Хәзер генә әйтәләр. Бына минекенә әбей, бабай, тип әйтелде ул, хәзер бына шулай китте, минең үземдең ҡызларым, әнкәй, ти, ә ҡәйнәсенә – әней. Кейәү, например, әнкәй, тип әйтә үзенең әнкәсенә, ә миңә – әней.

(Аблаева Яҙгөл Айбулат ҡыҙы яҙып алды).

**Әхмәтғәниева Гөлсибәр Хәмиҙулла ҡыҙы, 1958 йылғы**

Ҡыйғы районының Абзан ауылынан бер мең туғыз йөз сиксән беренче йылда килен булып төштөм. Бисер, селтәр менән шөғөлләнәм. “Аманат” төркөмөнә йөрөйөм.

Ауыл Мата йылғасы буйына урыннашҡан, ауыл уртасынан тағын бер йылға аға, аны Кече Мата дип йөртәләр. Анық суы бик чиста, суында бәрде (хариус) балығы бар, ә ул тик экологик йаҡтан йахшы йылғаларда ғына йәший. Тирә-йағын урман уратып алған, ул жиләк, гөмбәгә бай, төрле жәнлекләр йәший, рысь, айулар бар, үткән йыл Сахипова Диниянең сыйырын ашады.

Бында кисеү тайаҡ ул кочерга була. Йоморо – чашка. Сынайаҡ табағы – блюдечко. Аш сүмесе – половник. Фәрзә – штора. Ҡалаҡ, ҡашыҡ – ложка. Инәкәй – әсәй.

Таулар бик күп. Ауылны өч йаҡлап таулар уратып алған.

Ауыл эчендәге таулардан Ҡойы тауы ауыл уртасында тора, анда ҡойы булған, шуның өчен ауыл халҡы шулай дип атаған.

Ҡашҡар тауы, ул урында Ҡашҡар исемле кеше йәшәгән.

Бурсыҡ тауы – элек заманда монда кешеләр бурсыҡ аулаған, хәзер дә анда ул бик йыш очырай.

Ҡазған тау – бу тауны кешеләр ҡазып йул салғаннар.

Түбәтәй тауның төзөлөшө шуңа ошаған.

Чоҡорлар да күп. Ҡырыҡчоҡор – анда чыннан да ҡырҡ чоҡор бар, диләр.

Өч ҡарағай чоҡорында өч ҡарағай үсә.

Аҡ балчыҡ чоҡорынан аҡ балчыҡ алалар.

Писук базы – бу чоҡордан песок алалар.

Дегет базы дип атала, бу урында элек дегет ҡайнатҡаннар, чоҡор бик тирән базға ошаған.

Хәсән тарлауы – Бөрйәндән килгән Хәсән исемле кеше Көнтүгеш бабайның ҡызына өйләнгән, бабасы аңа жир бүлеп биргән, бу жирне әле дә Хәсән тарлауы дип йөртәләр, ауылға кергәндә уң йаҡта элеккеге колхоз фермасы артында.

Ғәттәр делянкасы – Ғәттәр ҡарт озаҡ йыллар урманда киселгән ағачларны саҡлаған, соңраҡ бу жир анық исеме белән йөртөлә.

Шайдулла отруб, Йосоп отруб – мең туғыз йөз унынчы йылда ауылдан ун өч йорт жир кистереп айырылып күчеп чығалар. Шәйдулла, Йосоп, Сәхәп. Ун житенче йылдан соң кире ауылға ҡайтҡаннар.

Сәлим хажи буасы – Сәлим хажи Мата йылғасына буа буған, тегермән тотҡан.

Рәскәле йаланы – Рәскәле йылғасы буйындағы зур йалан.

Балан ҡуаҡ – бу жирдә балан ҡуаҡлары бик күп.

Жите ат батҡан ҡуаҡлыҡ – бу урында Гражданнар суғышы йылларында аҡларның жите аты батҡан.

Саңғырау төбәк – шомло жир булғанлыҡтан шулай атағаннар.

Ташлыкүл – бу жирдә ташлар күп, чишмәсе бар, төбөндә ташлар йата.

Зиреклекүл – урманның шушы жирендә зирек ағачы күп.

Тегермән йулы – ауылдан йыраҡ түгел Ар йылғасында су тегермәне булған. Тегермәнгә бара торған йулны шулай атағаннар.

Мата күпер – ауыл уртасында Мата йылғасы аға, йылға аша салынған күпер.

Ҡабыҡ күпер – Рәскәле йылғасы аша салынған бу күпердән халыҡ йүкә ҡабығы ташыған.

Ар күпере – Ар йылғасы аша салынған.

Кече Мата йылғасы бик матур, чиста сулы, йыраҡ урманнардан ағып килә, Көнтүгеш ауылында Оло Мата йылғасына ҡушыла.

Олы Мата йылғасы Мата ауылы тирәсендә чыға, Ар йылғасына ҡойа.

Көйөк чишмә – әбий-бабайлар сөйләүенә ҡарағанда, бу жирдә изге кеше күмелгән, шунда чишмә чыҡҡан. Чишмәдәге ташта бер үсемлек үсә. Ҡартлар монда килеп намаз уҡыйлар, хәйер салалар.

Хәйретдин чишмә – шул тирәдә Хәйретдин исемле кешенең ҡорт баҡчасы булған.

Яҡты күл – бу күл Яңа Уразай ауылына йаҡын, монда табан балығы бик шәп, тирә йағы бик матур, монда халыҡ йал итергә йөрий.

Упҡын – бер мең туғыз йөз илле бишенче йылда жир убыла һәм күлгә әйләнә.

Чарлаҡлы күл – бу күл тирәсендә аҡчарлаҡлар күп.

Мунчала күл – бу күлдә йүкә батырып мунчала әзерләгәннәр.

Мүкле күл – бу күлдә мүк чығаралар.

Кисәкчүк – Иванай белән Көнтүгеш ауылы йулында.

Сәхәп чишмәсе, Әрәмә чишмә дигән чишмәләр, Мәмәтлекүл, Түгәрәккүл, Аҡкош күле дигән күлләр бар.

(Вәкилова Диана Тимерйән ҡыҙы яҙып алды).

## МАТЫ АУЫЛЫ

**Солтанова Эльвира Вәлихан ҡыҙы, 1973 йылғы** (фотола – һулдан икенсе)
**Шәйбәкова Әнүдә Сәрүәретдин ҡыҙы, 1970 йылғы** (фотола – һулдан өсөнсө)

Бер мең алты йөз ҡырҡ беренче йылда Себер даруғасының Уфа өйәҙе Таныл волосы Унлар ауылы “йасаҡлы башҡортларына” патша Михаил Федорович Романов исеме белән жир биләргә грамота бирелгән. Был жирләр хәҙерге Балтач районы жирләре була инде. Унлар ауылы вотчиналарының ата-бабалары “башҡорт татарлары” тип атағаннар һәм татарча сөйләшкәннәр (бу мең сигез йөз утызынчы йылғы йазманан күренә). Унлар ауылы кешесе Чыпчыҡ Суриков бер мең алты йөз ҡырҡ беренче йылда Чыпчыҡ ауылына нигеҙ салыучыларзың берсе була. Ә Илекәй ауылына нигеҙ салыучы – Илекәй Исәмбәтов.

Мата ауылына бер мең жите йөз унынчы йылда нигеҙ салына. Бу моннан ике йөз туҡсан йыл элек булған. Мата – ғәрәп-фарсы сүзе икән. “Ма” – пак, чиста, “та” – су дигәнне анлата икән. Бу турада миңә Мата ауылынан Сәрвәров Шәмсемөхәммәт бабай үҙенең әтисенән, ҡарт әтисенән үк күчеп килгән “Ҡөрьән” китабының житенсе бите читенә ҡулдан йазып ҡалдырған истәлектәрен уҡып күрсәткән. Мата йылғасының сыуы ауыл йанында ҡышын туңмый. Безнең башҡорт ата-бабаларыбыз, биредәге мал асрау һәм суғарыу өчөн унайлы шартларны күреп моннан ике йөз туҡсан йыл чамасы элек, ул ваҡыттағы Себер даруғасы Уфа өйәзе Таныл (Балтач) волосының Илекәй (Иске Ауыл), Иске Балтач (Ҡолый) ауылларынан күчеп килеп урынлашҡаннар. Менә аларның иң башлап килгәннәре һәм аларның исемләре: Ҡазбулатов Нуриман, Ғаделгәрәй, Шаммас, Шамидан, Сәфәрғали, Ғабделғазиз.

Ҡортчолоҡ, мал-тыуар менән шөғөлләнәбез. Балыҡны күп тотабыз: хариус, бәрҙе, шекерей, ҡызылтүш, этләш, ташбаш дигәндәр йөрөй беззең суларза.

Бездә ҡушма урман, күп ағачлар үсә: нарат, аҡ шыршы, ҡара шыршы, саған, усаҡ, йүкә, терке ағачлары үсә. Жиләк-жимеш ағачларынан: торн, алма. Слива, ҡызыл ҡарағат, ҡара ҡарағат үсә. Йәй көннәре гөмбә, жир жиләге, ҡайын жиләге, балан, чейә жыйабыз.

Икмәкне “әпей” тибез. Уны магазиндан алған йуҡ, үзебез пешерәбез. Ҡомалаҡ йыйып, уны ҡайнатып, үзем әпей пешерәм. Уғыз эшлибез. Бызау тыуғач, тәүзә аны туйғанчы сөт имездерәбез, анан суң сыйырны сауып алабыз, сөтне чиста сауытҡа һөзөп алабыз, шунан табаларны майлап, тоз һалып бешерәбез. Тәмле килеп сыға. Уғыҙ шәңгәсен эшлибез, әпей өстөндә бәрәңге була. Баурсаҡны ла туйларға, бәйрәмләргә үзебез эшлибез.

Зур апа, бәләкәй апа, чибәр апа – оло апайларға шулай өндәшәбез. Акбабай, ағинәй – дядя, тетя.

(Саньярова Рәмилә Рәмил ҡызы, Фәхретдинова Юлиә Рәфил ҡызы менән
Саникина Сулпан Рауил ҡызы яҙып алды).

### Талипов Мөҙәрис Әхнәф улы, 1957 йылғы

Тудыҡ Явьязы дигән ауылда, быннан алты километр, урман эсендә тора инде. Турыға менеп. Беҙ шунда тыуҙыҡ, дүрт класны тыуған ауылда уҡыныҡ, бишенсе класҡа күсеп килдек. Бишенсе класты был мәктәптә башланыҡ. Хәзер ауылым йуҡ, утыз алты өй бар ине. Фермалары бар ине, тауыҡ фермасы, йоморҡа салдыра торған. Магазин, клуб, бөтә нимә бар ине. Матур шишмәләре, хәҙер йуҡ, кеше тормай инде, бер ун-ун биш йыллап.

Мин һөнәр буйынса мөдир булып сыҡтым. Сигеҙ йыл элек йабылды мәктәп. По известным причинам инде. Хәзер өйҙә генә. Уҡытмайым, үззәренең уҡытыусылары йетәрлек. Бирскийҙы, биофакты тамамланым.

Мата – фарсы теленән ингән, “чиста сыу” тип аталған. Точный переводы. Фарсы теленән алына инде был. Шул ике йағына ауыл ултырған инде. Тегесе Тушҡыр сыуы тип атала. Унысының историясын белмәйем инде. Мата йылғаһы Яңыштан тигән ауылдан башланып алты километр ағып төшә. Бер мең йете йөз унынсы йылларҙа тип әйтелә инде, мында күсеп килгәндәр инде. Бер нисә семья инде. Вот Балтас районының Илекәй ауылыннан күскәннәр. Историяда бында бар ул. Бик теүәл түгел инде. Завклубта бар ул. Был йерләре урман булған инде элек. Был мәктәп урынында зират булған, шул бәләкәй булса да. Өс зират беззә, беренсе зират, аннан зур зират, әле действующий. Һәм ауылға кергәс тә йәшерелгән. Бында зиратты күсермәгәндәр инде, бында мәсет булған инде элек. Өстөнә генә эшләгәндәр, наверно. Бына был бағаналарны, ҡапҡа бағаналарын эшләгәндә бер-ике кеше башы сыҡты инде. Уларны теге зиратҡа илтеп күмдек. Оло кешеләр ҙә, балалар ҙа булғандыр инде. Череп бәләкәй ине. Унда элек мәсет булған, мәсет йортона күмгәндәр, бәлки. Башҡа йер булмағанмы икән. Шул ваҡыта бәләкәй булған бит инде, өс зират бит инде беззең.

Беззә Аҡбур тауы бар. Ғөмөргә шунан аҡбур алып, мейестә “үртәп” йандырып, шуны төйөп, һәр бер кешелә киле тигән әйбер бар ине, музейларҙа барҙыр ул киле, төйә инек инде бәләкәй саҡта. Усаҡта йандырасың да ап-аҡ бур была ине.

Ә бына бында Дилеш тигән тау бар. Дилмөхәммәт тигән кеше булған бында, Мәскәүҙән бер купец килгән бында. Бына шул купец Дилмөхәммәт тигән кешене йаллап, кеше таптырып, атлар таптырып, тегермәнде төзөтөп, үзе ауырып үлеп китә инде ул. Шул Дилмөхәммәткә тороп ҡала инде. Был историяла шулай йазылған инде. Дилеш тау тибеҙ инде. Бик матур.

Күк-тейен тигән бар. Йәшел тау. Историясы шулай килгән элек-электән, йәшел тау, Күк-тейен, унының историясын белмәйем.

Шишмә бар, благоустроенный, йулдан килгәндә күренә тегендә. Күчтә шишмәһе, тип йөрөтәбез. Бында элек тегермәнсе бар ине Костя исемле, халыҡ теләндә Костяны Күчтә тип йөрткәндәр. Хәҙер шул исем китте инде. Унын электростанциясы бар ине. Ун икегә тиклем йана. Бына без үскәндә инде ул. Төннә ун икегә тиклем ут бирәләр ине, уннан сүндерәләр ине. Тегермән бар ине. Шунда тегермән тарттырып, ауыл халҡы ғөмөргә балыҡ тоталар ине. Буа буылған иде. Шулай тегермәне булғас, ауыл халҡына бик әйбәт булды инде ул. Суңынан теге "ватсовый" аҡ тегермәннәр китте. Уннан бетте инде ул тегермән. Урыны бар. Аның шишмәсе бар ине бик матур, бик тәмле сыулы. Уға беседкалар эшләп благоустроили. Әйбәт, таза итеп тотабыз инде. Йәшләр ҙә, без зә йал итергә йөрөйбез. Йыраҡ түгел. Барып килеп була инде.

Ауыллар нәселдәргә бүленә, бар инде история бында. Нур нәселдәре, Султан нәселдәре. Электән арада начальниклары инде. Һәр бер ауылдағыса инде. Тамғалары ла барҙыр инде. Мин белмәйем. Элегерәк булғандыр инде. Тамғалары ла, маллары ла булғандыр.

Ауылда ҡорт тоталар инде. Бөтөн семьялар ҡорт менән заниматься итәләр. Фермалар йуҡ, күреп торасығыҙ, мәктәп бетте, садик та күсергә тора. Солоҡсолоҡ менән шөғөлләнәлар инде. Урманға ҡуйып тотоп шуларҙы, балын алып шуларҙан, солоҡсолоҡ тип атала инде ул обычно. Күргәнегез бар инде. Ә былай бөтә өйзәрзә ҡорт тотабыз инде. Етмеш-йөз баш. Дадан тибез инде умартаны. Дымар, гожгот тиләр инде обычно. Центробочкалар инде. Ну ҡырғычлары бар инде. Ҡыра торған. Электрический да бар. Обычно пычаҡ белән ҡырабыз инде без. Амшанник тибез инде, ҡортлар тора торған. Ҡышҡылыҡҡа шунда ҡуйабыз.

Башҡорт ҡортлары инде местныйзар. Тегендей Карпатский беззә йуғ инде. Уны кертмәнеләр ҙә үзебеззеке. Килтерелгән ҡорттар йуҡ беззә. Аның менән заниматься итмәйләр былай. Йарамай ҙа инде бығай ул беззә. Смешивать итәргә.

Без обычно прополис менән заниматься итәбез. Настойлар эшләйбез, спиртовой анда, йыуынырға нитергә. Йарҙамы, файҙасы күп инде. Былған бөтә сирләрне үтерә тейләр. Кәрәз тип йөрөтәбез. Заброс тейгән әйберне. Печатныйҙы ҡырабыз. Кәрәк булғанда серкәһен дә алабыз. Специальный сетка ҡуйып йыйабыз. Унан да тоже дарулар эшләйҙәр. Үлгән ҡортларҙан настойлар эшләйләр. Китапта бар инде унын рецепттары. Ну обычно үлгән ҡортларны йыйабыз ҙа араҡыға салып ҡуйабыз. Сөт менән бергә эсәбеҙ, аз-азлап. Ҡараңғыла ултыра инде ул. Күпме булса ла ултыра ул. Араҡыла бер нимә лә эшләмәй. Ну атна-ун көн тотабыз инде. Сөт менән йаҡшыраҡ үзләштерелә. Тағын личинкаларыннан настой йасайбыз. Тоже араҡыға салабыз. Йөз граммға утызлап личинка һалабыҙ. Бабочка мольның личинкасына инде. Мырт тип атайбыз. Балауыз ашай торған моль. Аш ҡазаннарына, ҡан тамырларына килешә. Ир-кешеләргә файдасы бар. Хатын-ҡызларға ла файҙасы бар инде. Беҙ улай сатыу менән ҡыйышмайбыҙ. Уға күп итеп эшләргә кәрәк. Үзебезгә генә эшләйбез.

(Вәлиева Гөлназ Даурат ҡыҙы яҙып алды).

## МӘНӘГӘҘ АУЫЛЫ

### Закирова Рәмзиә Николай ҡыҙы, 1969 йылғы

Бер мең туғыз йөз алтмыш туғызынчы йылда Балтас районы Асаевка ауылында тыуып үстем. Менәгәҙ ауылына мең туғыз йөз сиксән сигезенче йылның ноябрендә килен булып төштөм. Ҡул эшләре менән шөғөлләнәм. Беззең ике ҡызыбыз бар: Гүзәл һәм Гөлназ.

Ауылда Тушҡыр һәм Мәнәгәҙ йылғалары бар. Танып – мул сулы йылға, шунда су керәбез. Ул урын “Осло Туғай” дип атала.

Тел үзенсәлектәребез:

Үрҙәк – үрдәк, әтәч – әтәс, ҡаз – ҡаҙ, тавыҡ – тауыҡ, олатай – зурәтей, өләсәй – зуринәй, аҡбабай – оло ағай (дядя), аҡәбей – оло инәй (тетя), сенер, сеңлекәш – бәләкәй туғандар, абый, апа – оло туғандар, әпей – икмәк, гөлжимеш – шиповник.

(Саньярова Рәмилә Рәмил ҡыҙы менән Фәхретдинова Юлиә Рәфил ҡыҙы яҙып алды).

## НӨРКӘ АУЫЛЫ

*Нөркә ауылының "Гөлбәзир" ансамбле "Балан бүкәнләү" йолаһын күрһәтә*

**Шайбакова Миннур Сәйетғәли ҡыҙы, 1931 йылғы**

Был – Нөркә ауылы. Гөлбәзир тауы, ике Салават йуллары, сызасы бар. Йер-су атамалары бик күп.

Мин Иске Яҡшыйҙан үзем. Технищка булып эшләнем. Мәктәптә генә уҡытыущы булып та йөрөр идем. Эшкә кереп булманы. Залда ғына йөрөнөм... Безнең бик матур, көщлө мәктәп. Анда ҡайсы ғына уҡысалар да маҡтап торалар. Жите бала табып үстердем. Икесе фажиғәле үлеп ҡалды, бишәүсе, шөкөр, исән. Мына шулай, балалар менән йәшәп йатам. Кейәү хажға барҙы. Дин йулында улар, Аллаға шөкөр. Төрлө байрамларға, Салауат көннәренә бер ҡасан ҡалдырмайлар. Даже Саратовҡа тиклем барып йеттем.

Илле өщөнщө йылдан инде бында килгән инем. Шул алтышынсы йылларҙан булған инде балас суға башлауым. Колхозда ана, аҙаҡ мәктәптә технищка булып керҙем, иптәшемнең апасы бик ҡаты оста ийе. Ул өйрәтә торҙо, мин эшләй торҙом. Ирем ҡул станогы эшләгән ийе. Анан суң инде баласны ҡысҡарта инем йөннәрен. Мына былар барысы ҙа сарыҡ йөнө белән эшләнгән. Әле мин үзебезнең өйгә жите метр итеп, илле метрҙан йөн палас суҡтым, узорлар суҡтым. "Райхан"ға өс ҡабат төшөрҙөләр. Балалар өйләнгәщ, быны, әнкәй, алып ҡуйсаҡ буламы, тинеләр ҙә, теше жите буйны өщ ҡызға бүлеп бирдем дә ҡуйдым. Алары аларҙа әле. Бер дигән, бер ниндий бозолмаған. Үзем манып эшләҙем бөтөнөсөн. Бер узорын да табып эшләмәнем. Үзем эшләнем. Тавып эшләнем.

Бер ултырғанда баласты утыз метр эшләнем. Элек бит жөннәр йуҡ, шунан суң сарыҡ йөнө менән эшләп, хәр бересен алтышар-алтышар итеп йыйнап, мына, хәр бересенә көнө-төнө щалып алып барам да, өщ ҡават бының белән. Быны белгән кеше берәү дә ҡалмады.

Мынысы сепрәк балас дип кенә атала. Ҡалғаннары ковер дип аталалар. Шул йөн балас дип тә атыйым. Теге йыл барҙыҡ Ишембайға. Торатауға барған инек. Ҡараным, бересе дә оҡшамады. Минекен килеп ҡарағыз, тигән инем. Туғанҡайым, синең бит ковер, дип вис йаҙып алды. Кем булғанныр. Эшләй алмасам, звонить итермен, адресыңны бир, ди. Улар аны ковер диләр. Өс ҡат сепрәк ҡағам, алты ҡат була, узор матур итеп йатсын өчөн. Әле Ҡазахстанға барғанда вис алып барҙым. Сарыҡ йөнө әҙ ҡулланам. Хәҙер әҙер йөннәр бар. Ҡазанна ҡайнатып вис ҡуйасын. Төсләр биреп хәр бересен. Алтышар ҡабат ҡағам. Күлмәк туза ла, йастыҡ туза ла, шуны йыуам да салып ҡуйам. Ҡартым алмас борон. Ҡулын майзан сөртәм тип. Йәшереп ҡуйам. Бересе дә йаңы түгел. Йаҡши итеп йыуам. Алтмыш саҡрымға йөрөнөк. Комбайнға. Ирем менән бергә йөрөнөм. Жите бала үстердем. Бересе өс йәшеннә самауырға бешеп үлде. Бересе балсыҡ астында ҡалды. Ике малайым жигерме жите йыл Себердә эшләне. Әле пенсионерлар хәзер.

Күзлек кейгәнем йуҡ. Күзлексез уҡыйым. Ике күзгә лә операцийа йасаттым. Биш мең түләдек тә. Түләүлегә йөрөнөк без. Күззәр күрә, Аллаға шөкөр. Урамға сығам, щаҡырған йергә йөрөп йатам.

Ҡазахстанға барҙым. Мынау кейемнәрне йалтырлаҡларны, ишшеү өйҙә бар. Вис шуны Ҡазахстанлар биреп ҡайтарҙы бүләк итеп. Теге урынныҡ йапмаларын мин шуларға жигермене эшләп ҡуйҙым әле, ҡайтсалар дип. Тик мынауындый щир щыҡҡач, ҡайталмаҙыдар. Ҡазахстанға ике ҡават барҙыҡ.

Эй, ҡочаҡлап алды. Ун сигез маржа йаттыҡ. Русса белмәйем. Минең ҡызым руссаға тәржемә итте. Открытканан башҡа подарок кәрәкмәй, тине. Ҡайғым шулай иткән иде.

Бына был китабым үземнеке. Малайым үлгән ийе. Бөтә әрнегәнем шунда. Шуңа китап бастырып сығарҙылар. Мынысын улыма йаззым. Үлмәсә, йазмас инем:

Малайым да күренекле кеше. Салауат Фәтхетдинов менән бергә уҡынылар. Әлфрид Якшимбетов, Шакиров Жәүитләр, Салауат илле йәшемә одейал йеvәрҙе. Жәвит былтыр нәмә генә алып килмәгән. Зөлфиә бенән бергә. Бүләге, открыткаһы, нәмә генә йуҡ. Мин Уфала булып ҡалғанмын. Балалар анда ла бар. Йарай, икенсе уаҡыт күрербез, тип ҡалғаннар. Концерт ҡуйып, килеп йөрөнөләр. Минең малайым байанист иде. Салауат өщ ҡават килде. Сезнә рәхәт йырлавы, тип. Улым, балаҡай тере көйө балсыҡ аҫтында ҡалды. Үлде. Мына ошо шиғырҙы уҡыганна Салауаттың илауы... Был китапны уға ике бирҙем. Алла бирсә, йәйгә туҡсан йәшем була. Тағы ла Хоҙай Тәғәлә күпме бирер.

Әле жигерме ике йыл киленем белән торам. Әйттем әле, тағы жигерме ике йыл тороп булса, йарыр әле ул, дип. Киленне өщ ҡызға алыштырмайым. Өщ ҡызым бар, өщ ҡыз ҡайта ҙа, икене ҡуна ҙа китә. Мин тағын киленгә ҡалам. Килен шафир, ҡайҙа мине щаҡыралар, илтеп ҡуйа, барыв ала. Малайым Щеберҙә йөрөй, егерме икенче йыл эшләҙе. Машина безгә ҡала, ул киткәщ. Шулай.Аллаға шөкөр.

(Абдуллина Гөлфирә Риф ҡыҙы менән Хужахмәтов Айнур Оскар улы яҙып алды).

## ТУШҠЫР АУЫЛЫ

**Батырова Ғәлиә Сәйетгәрәй ҡыҙы, 1940 йылғы**

Һөнәрем буйынча ҡырҡ йыл медсестра булып Тушҡыр ауылында стационарда эшләдем. Бүздәк районынан килен булып төштөм.

Бәләкәй чаҡтан уҡ мин ҡул эшләренә тартылдым инде. Күршедә бер чигеүче бар иде, анда кереп ҡарап ултыра идем дә чыҡҡач өйдә чигә идем. Шунан әтийем, ҡайда барса да жипләр алып ҡайтып бирә. Бына бәләкәй чаҡтан инде шундыйға, анан чигү чиктем, уҡығанда да, эшләгәндә дә, мында килгәч тә, балалар булғач та, балаларға бөтә нәрсәде үзем бәйләп бирә идем. Минең ҡызларым да оста, улар да белә. Бөтөн бәйләм нидәрде дә, ваҡытлары булғанда, уҡыу арасында джемпердар бәйләп, элек йуғ ине бит магазинда, только ҡул белән үзебез бәйләп бирә идек балаларға.

Жилеттар бәйләдек. Минем ирем механизатор инде, өшөмәсен тип быңдай зур свитердар бәйләр идек. Ул ҡалын жилеттар, өшөмәсен дип, чиктем.

Мендәрләрем, шәлдәрем бар. Әле менә быңдай салфетканы врачҡа да, медсестраға бирдем. Салфетка дип атала инде. Бынысы ни, жиләк, жир жиләге, шушындай аҡ чәчкә, букетиктар бәйләгәнмен. Лилиә чәчкәсен бәйлим.

Ауыл электәнге әле лә шулай аталып йөрөй иде. Урамдары ла, тегендә – Базар урамы, бында – Ширдәк урам. Башҡа үтә атама йуҡ.

Урман ултырткан Хәзиәкбәр урманы, Дәүли йаланы, унысы да лесник, Көсәк шишмәсе, Оло шишмә, Ғәниәхмәт шишмәсе бар.

Байрәм булса, пирожки пешерәм, нәрсәдән булса да, балалар төрлө йердән ҡайталар, шәңгә пешерәм, любой нәмәнән, бәрәңгедән дә, эремчектән дә, кишердән дә төрлө пирожкидар, пирогтар пешерәм. Итле аш йаратам.

Без элек малны бөтөнөсөн ҡарадыҡ. Әле ун тауығым бар, аны ҡышҡа ҡарамайбыз хәзер, жәйгелеккә генә алып, жәй көнө йомортҡа салдырабыз да ҡышҡа ҡалдырмайбыз, инде. Ҡартайзыҡ, малыбыз-фәлән йуҡ. Баҡсаға әз генә бәрәңге ултыртабыз. Ҡарағат – ҡарлыған үстерәбез. Ҡартлыҡ житте, сиксән йәш, бабайыма сиксән биш.

Земляника – жиләк, черепаха – ташбаҡа, муйыл – шоморт, күшмә, күшеп жөрөй, шмель – дөңгәш.

(Саникина Сулпан Рауил ҡыҙы яҙып алды).

**Ихсанова Гөлшат Ғәйнелйән ҡыҙы, 1953 йылғы**

Мин шушы Тушҡыр ауылында тыуып үскәнмен, мында ғөмер кичердем. Инде миңә алтмыш жите йәш. Мин пенсиядәге ветеран уҡытыучы, Башҡортостанның мәғариф отличнигы. Мин инде хә лайыҡлы йалда, эшләмәйем. Ҡырҡ йыл мәктәптә эшләдем, рус теле әзәбиәте һәм татар теле әзәбиәте дәресләрен алып бардым. Шулай уҡ башҡорт теле дә уҡытырға тура килде соңғы ваҡытта, переквалифицироваться итеп. Менә инде шулай йалдамын. Бу – минең ансамбль. Мин етәкләйем йегерме йылдан артыҡ бу ансамблне. Мин, ғөмүмән, мәктәптә уҡытыу белән бер рәттә культура-мәдәниәт учағы минең өстә булды. Мәдәниәт учағында башта балалар белән бейеү түгәрәкләре, жыр түгәрәкләре, әзәби түгәрәкләр белән эшләдем, анан соң инде менә уҡытыудан туктағач инде, менә шул хатын-ҡызлар төркөме, ансамбль ойоштордыҡ, "Ҡартаймас" ансамбле. Һәм шушы ансамбль белән без бик күп халыҡ жырлары башҡардыҡ, шунан ике комплект костюм тектердек, үзебезнең кесәләрдән, тырышып. Клубыбыз, культура учағы, бик матур. Клубны тик тотмайыҡ, йал учағы йасайыҡ  халыҡ өчөн дип, шундый мәзәниәт учағында дип, тырышып, менә шулай инде йегерме йылдан артыҡ инде шушы ансамблебез йәшәп килә, эшләп килә. Һәм инде бик күп кенә район мәзәниәт чараларында ҡатнашабыз, конкурсларда. Менә инде бер ничә йыл конкурсларда ансамбль призовой урыннар, беренче урыннар алып йөрөдөк инде. Мин үзем йалғыз да жырлайым, шиғырлар да сөйләйем, ҡубызда да уйнайым. Шиғыр конкурсларында Әнғәм Атнабаевның шиғырларына бағышланған шиғыр конкурсында жиңеүче булдым. Өчөнчө йыл бағай. Шунан Республикада шиғыр сөйләү буйынча "Нәфис сүз", сөйләүчеләр арасында нәфис сүз призлы урыннар йаулап, беренче, икенче урыннар республикада да алған нәтижәләрем бар. Хәзер онотоп бетереп тә барам инде. Халыҡ жырлары жырлана. "Ата-аналар доғасы" дигән жырны бик йаратып башҡардыҡ инде. Бу безнең йаҡларда жырлана. Айдар Файзрахманов та үз ансамбле белән жырлай бит инде шушы жырны. Шунан соң мин үзем дә таҡмаҡлар ижад итәм. Менә без Дүртөйләгә бардыҡ, анда таҡмаҡларны үзем ижад итеп барған идем инде, оноттом инде мин аларның сүзләрен. Ансамбль белән жырладыҡ. Бер дә аны хә мин хәтерләмәйем. Шунан шулар белән бер рәттән үзем күңелдә былған нәрсәләрне менә шул шиғыр йулларына да төшөреп, шиғырләр дә йазам инде. Менә минең беренче китабым инде ике мең бишенче йылда чыҡҡан иде, "Күңелем гөлләре" дип атала инде ул китап. Шунан соң бу сборниклар да чыкты инде, анда менә ун биш авторның ижад жимешләре, район житәкчеләре йардәме белән чыкты инде бу "Туған жирдә тыуған хисләр" дип атала. Шунан "Әзәби балҡыш", мынсы йазыучылар берлеге белән, бергә ижад ителгән, мында минең шиғырлар шәлкеме бар инде.

Безнең Менәгәз йылғасының тау йағы атала Башҡорт очы, башҡорт йағы дип. Шунан инде анда Байрамша нәселе күберәк инде йәшәйбез, именно шул Байрамша нәселенән Бикташ, Уразмәт, Тимерғәзе йаҡлар өскө йағы, тау йағы инде. Шунан бу йаҡта Балтачтан кергән йаҡта мында Типтәрләр дип әйтәләр инде, ул Типтәр йағы дип атала инде. Ғәбжәлилләр алар инде әйтелгәннәр инде татар йағынан, теге жир кирәк былып, чуҡындырыудан ҡачып килгән кешеләр, шунан балта осталары шулай килеп урнашҡаннар. Шунан йылға

буйына килеп урнашҡаннар инде, в основном, Бикташлар су буйындараҡ урнашҡаннар. Шунан безнең белекей чаҡта мында урыслар да бар инде, урыслар йәшәйдер иде.

Менә инде без мында мәктәптә, Балтачта музыка мәктәбендә, школа искусствта уҡытыучы Рая Хамаевна белән бик тығыз бәйләнештә ижад итәбез. Унан менә әле безнең ауылда, в основном, баян, хромка, ну ансы минең өйдә инде, ҡубыз, шунан соң мандолинада уйнаучылар бар иде инде. Хәзер алар шәхәргә күчеп киттеләр инде, шунан өйрәнеү дәрәжәсендә генә ҡурайда уйнаучылар бар.Безнең өйдә ҡурай да тора, өйрәнеү дәрәжәсендә инде генә, ансын бик оста итеп уйнамайбыз инде, йәшләр гитарада уйнайлар, мында да электро-гитара да бар. Менә Балтачта быйыл Жиңеүнең житмеш биш йыллығына памятник ачтылар бит инде, һәйкәл ачтылар, менә шул һәйкәл ул Уразай ауылында тыуып үскән ҡызның образын гәүдәләндергән һәйкәл былды инде ул.

Йарты Тушҡыр инде анда. Сигез нәселдән таралған мында Тушҡырда халыҡ. Ансын сельсоветта беләләрдер инде күпме халыҡ йәшәгәнен. Шунан йегерменче йылда Хәтер йылы, Дан йылы дип иғлан ителгәч инде, шиғырлар йаздым аңа бағышланған, шунан менә ковидҡа кереп киткәч, шиғырләр йаздыҡ. Менә инде Рая Хамаевна “Игенчеләргә” дигән жыр йазайыҡ але, Гөлшат апа, дип сораған иде, аңа шиғыр йазған идем инде. Игенчеләр турасында шиғыр.

Менә шунан үзебезнең ауылдан житмеш биш йыллыҡҡа инде, шулай йазасым килде житмеш биш кешенең исемен алып. Житмеш биш йаугирнең исемен алып, шиғыр йаздым. Безнең ауылдан бит инде суғышҡа киткәннәр ике йөз житмеш дүрт кеше, шуның йөз дә ҡырыҡ сигезе йауларда йатып ҡалған, йөз дә йегерме алты кеше тыуған йағына ҡайталған. Менә шуңа нитеп инде үземнең белгән бабайларымның исемнәрен әйтеп, житмеш биш кешенең исемен әйтеп менә шулай шиғыр йаздым. Бик күп кенә отзывлар килде инде, балаларыннан бу йаугирләрнең, алар инде хә исән түгелләр бит инде. Безнең ауылда бөгөнгесе көндә бер генә суғыш ветераны да йуҡ инде. Берәү дә йуҡ. Минең эткәйем үземнең тоже суғыш ветераны иде, лейтенант дәрәжәсендә. Менә бер, былай бик озын инде ул, әйме, бер ничәсен генә уҡып күрсәтәм:

Шакир, Ислам, Әрхәм, Батыр,
Вафый, Дәүлий, Тахирлар,
Фәссәғаи, Зыя, Вәли, Ғәли –
Оло быуын йаугирлар.
Менә шулар, менә тағын:
Имаммөхәммәт, Сәйет, Фәхим,
Ғәбдрәхим, Фәйзелхаҡ,
Сәғди, Хөрмәт хәм Нариман
Сүләделәр сүзне хаҡ.
Истә Зөлкә Филәғәйнең
Безнең өйгә килгәне,
Ғәйнелйан фашистны жиңде,
Без бәхетле, дигәне.
Хис онотылмай хәтеремдә
Шаулы мәктәп йыллары.
Зөфәр, Нурихан, Хәмәт аға –
Халҡымның чын уллары.      Шундый формада әйтеп инде житмеш биш йаугирне йазғанмын.

(Вәлиева Гөлназ Даурат ҡыҙы яҙып алды).

**Хәсәнйәнова Рәлиә Әсхәт ҡыҙы, 1952 йылғы**

Беззең ауыл бик оло тарихлы. Был йаклар бик матур жирләр булған. Бер мең алты йөз сиксәненче йылларны урынлашҡаннар был йаҡларға. Мин үзем күрше ауылдан, илле йылдан ашыу йәшәйем, килен булып төштөм бында.

Тушҡыр ауылына ун житенче ғасыр азағында Ҡыр Танып ырыуынан Уразмәт, Бикташ, Байрамша, Исмағыйл бабаларыбыҙ нигез салған. Аларның быуын чылбырлары-шәжәрәләре мәктәп музейында саҡлана. Бу урында йуан ҡарағайларда, йүкәләрдә ҡырғый ҡортлар ойа ҡорған. Урманнарында төрле жәнлекләр, йылғаларында балыҡ күп үрчегән. Күлләрендә аҡкошлар бала үстергән. Әнә шундый күл буйында бабаларыбыҙ йортларны салған. Ата-бабаларыбыз башҡортларга хас сунарчылыҡ, умартачылыҡ, балыҡ тоту, урман әрчеп сөрөнтө жир эшкәртү, игенчелек менән шөғөлләнгәнгәр. Бер мең жите йөз унынчы йылда, ҡайсы бер материалдар буйынча мең сигез йөз сигезенче йылларда, башҡорт ата-бабаларыбыз үз жирләрендә йасаклы татарларны керткән.

Ауылдың исеме – Тушҡыр. Исеменә бәйле бер нисә легенда бар. Урманды эшкәртеп, был йерҙәргә күсә башлағас, игенчелек менән шөғөлләнә башлағандар. Шул ваҡытта күргәннәр: йерҙәре ничектер түбәнерәк, ә ҡырҙары өҫтәрәк, түш кеүек урынлашҡан. Шуның өсөн Түшҡыр тип йөртә башлағаннар. Икенсе фараз буйынса, йылға исеменән алынған. Шулай уҡ йаз көнө ҡарны чоҡоп аласың да, су чыға, шуны беҙҙә “Түш сыуы” тейҙәр. Ошондай ҙа версия бар.

Тушҡыр йылғасынан тыш, Менәгәз йылғасы аға. Ул беззең ауылыбыззы башҡортлар һәм типтәрләр йағына бүлә кебек. Беззең ата-бабаларыбыз башҡорт нәселенән булған, ә ун сигезенсе быуаттарҙа бында Татарстан йаҡларынан татарлар килгән (унда көчләп чуҡындырыу башланыу сәбәпле). Беззекеләр уларҙы

ҡаршы алғаннар, ун биш дисәтинә йер бүлеп биргән. Ә бына марый халҡын нишләптер үззәренә алмағандар. Йегерменсе быуаттарҙа беззең ауыл өс өлөшкә бүленгән, өс мәсет булған. Утызынсы йылларза районда икенче булып беззең ауылыбызза электростанция төзөлгән булған. Шул йылларны ике ҡатлы мәктәп төзөлдө бөтә районға, кирпич заводы булдырылғайны. Бөйөк Ватан суғышы заманаларында ауылыбыззан ике йөззән ашыу ир-егет киткән. Шуларҙың житмеш өсө генә кире әйләнеп ҡайтҡан.

Әлеге ваҡытта өс йөззән ашыу йорт бар. Ауылда “Ҡартаймаслар” фольклор ансамбле эшләп килә.

Үзебезгә күлдәкләр тектереп алдыҡ. Ун биш йыл инде уға хәзер. Конкурстарҙа йыш ҡатнашабыз. Беззең районда “Тыуған йаҡ моңдары” дигән конкурс, шәжәрә байрамнары ойошторола. Беззә уникальный музей бар ине, экспонаттарға бик бай, әммә, ҡызғанычка ҡаршы, пожарҙа күп нимәне йуғалттыҡ. Йыш ҡына сәхнәлә йола-байрамнарҙы күрсәтәбез. Ауылда никах туйлары, бәпес туйлары, ҡаз өмәләре, мал өмәләре, өй салғас, табын ҡороу үткәреләә. Табында мотлаҡ әпий, бәлеш, аш булырға тейеш. Әпийҙе ҡомалаҡтан эшләйбез. Ауылда ҡортчолоҡ менән күп шөғөлләнәләр. Мал, ҡош-ҡорт үрсетәбез.

(Саньярова Рәмилә Рәмил ҡыҙы менән Фәхретдинова Юлиә Рәфил ҡыҙы яҙып алды).

## ТҮБӘНГЕ ҺИКЕЯҘ АУЫЛЫ

### Ғәлләмова Әлфиә Вәғиз ҡыҙы, 1955 йылғы

Мин житмеч сигезенче йылдан башлап Түбән Сикеязда йәшәйем. Тыумышым белән Ҡумыязы ауылынан. Иптәшемне мында эшкә жибәрделәр дә, ветврач булып эшкә башлады, шунан миңә лә бында күчергә тура килде. Өйләнешеп, бында йәшәй башладыҡ. Мәктәпне бөткәч, медучилище бөтөрдөм Оренбургта. Ҡайттым, үзебезден районда эшләдем. Сикеязда мында участок больницасы бар ийе. Участок больницасында жигерме йыл эшләдем. Шунан больницаны бөтөрдөләр, йаптылар. Больницаны йапҡач, бер йыл сельсоветта эшләдем. Сельсоветта бер йыл эшләгәндән суң мында ололар йорто, дом-интернат ачылды. Шунда директор булып сигез йыл эшләдем. Сигез йыл эшләгәч, тағы шул интернатларны йаба башладылар. Элекке больница зданиесында булды ул. Больницаны йапҡандан сун таралғайны интернат, шунда ачылды инде. Үзем башлап ачып шулай, ремонтлар эшләп, газлар кертеп, шулай йөрөдөм инде. Бик әйбәт итеп кенә эшләп, йәшәп йата инек матур ғына, облогораживать итеп здание, территорияны, шулай йаптылар. Мына пожарлар чыға башлады. Шунан бөттө эш. Эшсезлек. Пенсияға чыҡтым. Пенсиядамын, алтмыш биш йәш булды быйыл. Шулай әкрентләп үзэшсән сәнғәт түңәрәгенә ҡушылып киттем. Үзебездең бергә эшләгән бында коллегалар, бергә эшләгән иптәшләр бергә, барысы ла танышлар. Мәчеткә йөрөй башладым шулай.

Имам йорто булғач, имамыбыз бар, хәзрәт саҡырып, ҡөрьән уҡытабыз, исем ҡушабыз. Исемне былай ғына ҡушмайбыз инде, үзебезнең динебез ҡушҡанча, мосолман йолаларын саҡларға тырышабыз. Үземдең дә икенче улымның берсе Әмир исемле, икенчесе – Әминә.

Бу ауыл түбән жирдә урынлашҡан, элек бит инде су буйларына урынлашҡан. Ике йерзән су аға. Салҡын чишмә, Ғомәр чишмәсе, Сәрби чишмәсе бар. Аның сыуы сып-сыуыҡ, тамаҡты ла шештермәй, эсселә эчсәң дә. Шундай шифалы, тәмле сыуы. Өйгә су керсә лә, шунан барып алабыз.

Без бәләкәй чаҡта “Әбәк”, “Ҡачыш”, черта сызып уйнай идерек. Йаз көнө ҡар иреп бөтөү белән “Черта” уйнала. “Суҡыр тәкә” уйнайдыр идек, күзләрне бәйләп. “Лапа” уйнай идек, мына йөгереп кенә китәсең дә, йергә басмасҡа, тиз генә бейегерәк йергә басырға кирәк.

(Ҡотлоәхмәтова Эльнара Рафиҡ ҡыҙы яҙып алды).

### Йыһангирова Гөлфирә Ғәли ҡыҙы, 1948 йылғы

Үзебезнең жирле сүләш, әйттем бит инде, анда местный наречиеға керә: менә бармайым, ҡайтмайым дигән кебек. Ҡайтмим, татарча бөтөннәй китапча былса, ҡайтмим булырға тийеш, ә безнең, получается, ҡайбер уаҡытта, ҡайтмайым, эй, кит әле, бармайым мииин, дигән кебек нәрсәләр дә бар бит инде оборотларда. Шуңарға мыны конкретно ғына именно шул тел, шулай ғына сүләшә халыҡ, дип әйтеп былмай. Мына мин әле үзебезчә сүләшәм.

Бушкилде урамы дигән ийем бит, Бушкилде дип атала, Победа урамы ул. Ул урында ауыл йуғийе безнең, бөтөнләй йуғийе. Шуннан колхоз мына мындағы магазинны урыннаштырыр өчөн, колзоз салған магазиннар бынаулар, Акберов дигән колхоз председателе ийе безнең, шушы Акберов абый, колхоз исәбеннән ике өй, әйе, ике өй, Хаматшиннарға, тағы кемнеке әле анда, Зиниә апаларға, ике өй сатыв алып, быларға ҡайандыр күчертеп ҡайтарып бирде. Шунан үзе шул уҡ урынға урнашты, шушы урамға. Ул нейҙә ийе, Яңы Яҡшый, өч километр мыннан, шул ауылдан йөрөп эшләйҙер ийе Вәсми абый. Как будто бушҡа килде, буш килде. Ә, буш килде, буш килде, шулай итеп киткән инде ул. Әле дә шулай диләр инде, ул Победа хөкүмәт йазыуы буйынча, улица Победы. Тегендә – улица Мира. Мынсы мына – Центральная улица. Аңарҙың артындағысы мына безнең урам – Садовая улица. Анан дальше – Рабочая улица. Заречная, тегендә – Хаков урамы, аны элек Чәкән урам дип, исеме ничек булған икәнен белмәйем, хәтерләмәйем. Безнең үзебезнең бер геройыбыз бар, ул Афганистанда үлеп ҡалған, летчик, шул Рамил Хаковның исеме бирелде. Ул туған урам инде. Обиходта ул исемнәр гел урысча бара. Ҡайсы урамда? Садоваяда. Ҡайсы урамда? Рабочаяда. Урысча әйтелә инде. Былай Победы урамы димәйбез инде ул, Бушкилде, дибез, Түбәноч, Юғароч, Чәкән оч. Чәкәннең урамы расположениесы мынаулай

чәкәнгә оҡшап тора, клюшкаға, шуңарҙан алынды микән ул. Чәкән уйный торған, чәкән уйнағаннар бит инде. Шулай булды микән? Чынлап уйнаҙылар микән? Ауылның историясын йазған ийем мин. Мин аны йазып, кешегә бирдем.

Безнең ауылның башы, башлануы бу төштә бумаған ул, ауылны чыҡҡач, тегеләйгә китә Яңы Яҡшый дигән ауыл, шул ауыл йағында йылға аға Сикеяз дигән йылға, безнең ауылға исем бирелгән нижнее течение реки Сикеяздан. Юғары Сикеяз бар өстә, шул ауылдан ағып килә йылға, мына ул безнең Чәкән урамын бүлеп, Заречнаяны бүлеп тора инде. Аннан ул Йоҡҡа барып тоташа. Йоҡ йылғаһына. Йоҡ – Таныпҡа. Йоҡ – ул удмурт сүзе микән ул, тегендә Пермь Йоҡларынан уҡ ағып килә бит ул йылға. Ошолай йазылырға тийеш ул, аны дөрөс бирмәйенчә, ул хәзер Юг булып, Көньяҡ йылғаға әйләнеп ҡалды. Ә тегендә, иптәшем исән чаҡта теге йаҡҡа барғаныбыз бар ийек, менә шушылай була ийе. Нәмәкәйский ошибка була әле ул? Юг булғас, әлбиттә, был Көньяҡ дийелгән. Фактически ул Йоҡ булырға тийеш. Ул безнең башҡорт, татар сүзе түгел. Тегендә удмуртлармы йәшәй торған жирдән килә йылға. Тегендә Йоҡ, мында ҙа Йоҡ. Мына килеп тоташа. Ғүмер баҡый Йоҡ булып йөрөнө, мына хәзер – Юг, Көньяҡ йылғаға әйләнде ҙә ҡуйҙы ул менә. Ничә йыл элек? Урысча йаза башлағас исемнәрне, миннән соранылар аны, мин аны уйламый әйттем просто. Урысча нисек була икән? Ничек йазырға икән? Әәә, Юг, наверное, дигән дә ҡуйғанмын. Була бит шундый уаҡыт, нәрсә беләндер занимаешься, и синә сорау бирәләр. Автоматически ниндәйҙер чүп йауап бирәсең, юг, наверное, дигәнне сельсовет та йазған да жибәргән. Мөмкин булған да бит шул килеш йазырға, урысча да, башҡортча да, татарча да – Йоҡ. Безнең андый дөрөс түгел нәмәләр күв инде ул. Мынауынан боролоп кергән жирдә дә Нижнее Сикеязово 9 километр дийелгән. Элеккеге “Башкирия” дигән машинкалар бар ийе бит, шунда тройка, девяткаларның ас йаҡлары асҡа сәленеп, бер иш басыла ийе. Басҡанда теге өч алама чыҡҡандыр, туғызға әйләнгән. Әлегәчә шулай указатель тора. Бер үк заманда эшләнделәр ул язулар барысы да.

Сикеяз – мына Зәки абыйығыз бар бит, сезне ҡаршалғанда ҡоҙа булып килде бит, аның әтәсе әйткән, бу восточный языктан низменное место дигәнне аңната, ди мына шушы. Түбән урын. Алай дисәң, Юғары Сикеяз түбән урында түгел ул. Бу ғәрәп телендә или турецкиймы, ғәрәп телендәҙер инде ул. Ғәрәп телендә булса, мынсы минем предположение ғына, ғәрәп телендә сикеяз түбәнге уйсыу урын булғач, ул Түбән Сикеязы йылға ағышы буйынчаҙан түбән ул. Тегесе – Юғары Сикеяз, мынаулай Сикеяз аҡҡан жир, и мынаулайтып килеп аға ул, элек мынауында булған ауыл, мында аларның через речку зиратлары, шунан мында йәшәй-йәшәй, йәшәй-йәшәй, арталар бит инде халыҡ, жирне бүлешкәнбез бит инде, мында бер көтөү бала туды, үсте, өйләнде, аларны ҡайадыр башҡа чығарыр кирәк, вот и новые земли осваивали. Йылғаның бу йағына урнаша башлағаннар шушылар мында күчеп инде. Суңынан мында ут чығып, мындағы ауылның бөтөн корены йанып, мында хәзер пустырь, анан мында киткән инде ауыл. Йүнне генә, бай ғына, хәлле генә кешеләр килеп утырғаннар аннан ауыл мында ниткәч ужы, Фәйруш ҡарт килеп утырған, тегермән дә тотҡан. Мифтахетдин хәлфә булған, мына безнең әлеге главаның прадеды була, пра пра булмаса. Шулар торғаннар. Ауылда батрак булып, теләсә ҡайда йөрүче бер ничә генә семья булған. Мында шул ҡәҙәре трудолюбивый халыҡ торған булған. Зурнәйем мына әйтәҙер ийе, ул батрак булып йөрөгән кеше үзенең өйөндә эшләсе кимәгән кеше, ди. Тамағы туйды, әзерәк семьясына алып ҡайтты, ә бит үзеңнең эшеңне бит, ди, көн йоҡламай, төн йоҡламай эшләргә ҙә эшләргә, эшләргә ҙә эшләргә кәрәк. И вот нанимают инде ана шундый кешеләрҙе. Шулай тиҙер ийе зурнәйем.

Зурнәй – ул өләсәй була, зур инәй, атайымның инәсе. Ҡартый дийәргә можытлар. Суңғы йылларда мына китте бит инде, нәнәй дигән сүз чыҡты, мин аны бер йердә дә ишеткәнем йуҡ. Ул ниндиҙер чужой сүз ул. Нянька дигән кебек. Минең зурнәйем, ой, властный ҡортҡа ийе. Әнкәйемнең инәсен ҡартый дип әйтегез, ул зурнәй түгел, мин зурнәй, диҙер ине. Бу зурнәйем үлгәнче, теге зурнәйемә үзе алдында зурнәй дибез, ә былай ҡартый дип сүйләйҙер ийек инде. Мына зурнәй бар бит инде, әйме, зурнәйнең ҡәйнәсе исән икән, ди, әйме, ана шул ҡортҡаға әйтелә инде ҡартый дип. Ҡарт инәй формасы инде.

Бигерәк гөрләп тораҙыр ийе ауыл, ныҡ зур ийе. Һәйбәт ауыл ийе. Мында куспром да булған ул. Суғыш алдынан ҡуйылған әле ул куспром. Сикеязның тейаҡ башында. Лесопильный нәмәләр, ҡап суҡҡаннар. Башта бик ауыр заманнарда йәшәгән инде безнең халыҡ. Ҡап суғыу ничек була? Ҡыш көнө йүкәнән суйып төшөрәләр ҡабығын. Ағачы ғына ҡала, ансы утынға китә. Леспромхозныҡы булғач, башҡа төрлө эшкә дә киткәндер. Ул ҡәҙәрен белергә вағийем әле анда. Ҡабығынан, суға батырып, мунчала төшөрәләр. Шул мунчаланы жәйәләр, киптерәләр. Шунан ары бәндәгә тараталар. Шунан ҡап эшләйләр. Мунчаланы ленталап теләләр. Телеп-телеп, телеп-телеп, станокта озоно буйға тезәләр. Арҡырыға бер очтан бирә лә берәү, икенчесе кирегә үткәреп бирә. Шунан ҡаҡҡыс белән ҡаға баралар. Шулайтып шаҡмаҡ-шаҡмаҡ килеп чыға, шуңарҙан ҡап эшләйләр. Астына жгут кебек эшләнгәнен ситләренә тегеп чығалар. Тара итеп ҡулланалар инде аны. Күрше-тирәләр, Сафия апалар, Хәдисә апалар, Фәриҙә апалар эшләйҙер ийе безнең ҡырда. Ленталап телгәндә ваҡ ҡына труха кебекләр дә була ийе, без шуның белән уйнарға керәҙер ийек. Шунда мунчала арасында буталанып йата торған ийек. Ныҡ ауыр вахытта йәшәгәнбез. Әле мин уйлайым да, хәзер өй сайын машина, кемгә ҡарама, йахшы машинала ҡатын-ҡыз. Бу начармы ни тормош? Душ бар, туалет бар, стиральный машина-автомат, сундук-сундук... әле мына сундугым йанған ийе, ууу, ҡайа итәм мин мыны, чаптырдыҡ та магазиннан алып ҡайтып тағын берне шаҡылдатып утыртып ҡуйдыҡ. Шуннан мынсын ремонтлап бирҙеләр. Хәзер мынсы – мяснойлар, мынсы – овощи-фруктылар. Әбей-пенсионер. Начар разве шушы тормош? Мәңге житмәйәчәк. Тырышҡан кеше йәшәй торған замана, тырыша торған, эшләй торған. Алма беш, ауызыма төш, тип йатҡан белән булмай.

Мында трудолюбивый халыҡ торған булған, динем бит инде. Мында раскулачивать итәргә разнарядка килә, ди. Зурнәйем сөйләй инде. Разнарядка димәй инде ул, нарят, ди. Нарят килә, ди, ә кеше йуҡ ди

раскулачивать итәргә. Ә заданияны үтәргә, кеше табарға кирәк. Безнекеләрне раскулачивать итмәс өчөн, элек бит инде мында кеше жибәреп эшләткәннәр, тегенән кешеләр килеп. Үзеңнекен суғып йығып булмай ич, дигән кебек, Ғәли исемле кешене, Ғәлиев булғандырмы, Ғәлиме, шул Ғәли дигәне исемдә ҡалған инде, былар алты почмаҡлы өйнөң бер печен тиз генә сүтеп алғаннар, бынсы ишағал, йәнәсе. Шунан квартираға теге Ғәлине кереткәннәр. Аларның чиннекләрендә, әле мин хәтерләйем әле, калхуз ашлыҡларын килтереп салып саҡлайҙыр ийе. Булған инде, муллаларны-нейләрне жибәргәннәр инде.

Чиннек – ул йарылған бүрәнәнән эшләнгән, ҡыйыҡ астында, анда ашлыҡ салалар. Келәт кебегерәк дип әйтәйемме, но келәт ваҡ, чиннек зур. Ныҡ зур ул. Ул бүленгән була тегеләйгә дә, былайға да. Дүрт келәтең инеп утыра анда. Ашлыҡлары ике ҡапчыҡ ҡына булмаған бит, жирләре күп булған, йәшәргә кирәк булған. Сенник дигәндән түгел микән, сено сүзенән. Мына пүнәтәй понятые дигәннән әйләнгән бит. Шуның кебек.

Ишағал – ул сени. Ишектең алдындағы, таҡтаҙан була. Анан дальше бура менән өй китә. Чолан түгел, чолан ишағалда була, бүлеп ҡуйасың. Бездә чоланда оно да тора, ашлығы да тора.

Шерпекә дигән сүз бар. Заноза. Мына бу Фәнилә – минең ҡайын шерпекәм. Золовкам. Ҡайынсеңлем. Мин генә әйтәм уға шулай тип, шайартып. Ҡайын шерпекә – минең генә сүзем ул. Үрҙәктә, ҡазда да була шерпекә. Йөннәрен-нейләрен тазартҡач ҡала ич чығып бөтмәгән чүбе. Ана шуны да шерпекә дибез.

Быйыл Рәмилә Сәлимгәрәева маҡтап китте әле мине. Быйыл уйнаҙым мин әпә ҡортҡаны. Әпә дийем, азаҡтан ғына теле ачыла. "Әбейләргә ни житмәй"ҙә уйнаҙым. Менә, ди, аның бит менә, ди, матур күренәйем димәгән, ди. Маҡтаҙы инде. Образ буйынча мин матур күренергә тейеш түгелмен. Ҡартлар йортонда йатам мин ҡортҡа. Мин этемә дә кирәкмәймен. Нейә мин матур күренергә тейеш? Кем алдында рисоваться итергә? Постелдән дә тормай, йата ҙа йата, йата ҙа йата. Шуннан тегенең күршеләре барысы да йәбешеп кейәүгә әлеге шул Зәкейгә тағылырға тырышалар. Зәкей уйнай инде ул ролде. Хәҙер мин туалетҡа барам. Әйләнеп килдем, шунан үзем дә уйламағанмын, ачыуы килгән, образ буйынча инде, йәнәсе, ҡомғанны китереп шап иттереп утыртып, ууууххх, дийеп йатҡан ийем карауатҡа. Шуны Сәлимгәрәева әйтә инде, менә бит аның, ди, менә шушы ҡомғаны белән генә дә бөтөн пьесаның сүзен әйтеп ҡуйды бит мына, ди. Шундый остамын мин, маҡтанырға йаратам, әйеме? Бөтөн нәселебез белән талантлы кешеләр инде без былай. Бер туған энекәшем ғүмер буйы шушы клубта завклуб булып эшләгән кеше. Халыҡ жырларын жырлайҙыр ийем. Хәзер бик булмай. Аның өчөн бит распеваться итергә кирәк бик озаҡ. Менә минең шул хәтлем "Сәлимәкәй"не жырласым килә. Мин беләм, дип кенә булмай бит.

Безнең национальныйларны уйласаң, жыйыннар булған, ул да зурнәйем сөйләүе буйынча ғына беләм мин. Атлар жигеп китәҙер ийек, ди, тирмәләр ҡороп йатаҙыр ийек, ди, ҡубызда уйнайҙыр ийек, ди. Мин вабще уйлайҙыр ийем, мин татармын, дип уйлайҙыр ийем. Әнкәйем минем – типтәр. Иске Яҡшыйныҡы, Балтач ҡырындағы. Ә эткәйемнәр – нәселе буйынча... безнең ничәле анда ун өчмө, ун өч буын билгелесе менә. Оказывается, безнекеләр йазып, малайына биреп ҡалдыра барғаннар. Буйынан буйына, буйынан буйына. Шул саҡланған. Ул ҡәғаз сарғайып бөткән, энем менән мин алып ҡалдым. Унда разветвлениелар, уууу, йарты союз тулған төслө инде. Ҡазбулат нәселе без. Милләт йазылмаған анда, әммә бер нәмәкәй бар, менә – Ҡазбулат. Ул бит инде татар исеме түгел, башҡорт исеме, әйбит. Шунан дальше, дальше китә анда. Айыҡкол, ул да бер нисек тә татар исеме түгел. Корень кебек йасадым да мин зурәтәйемдең этәсенән башлап, Нурмөхәмәттән башлап, аннан киттем инде. Ҡалған веткаларын белмәйем ич инде мин. Нурмөхәмәт ҡартҡа ҡәҙәресен йазылып килгәннәр инде. Ул бер дини китап эчендә саҡлай торған ҡәғаз ийе инде ул. Ул ҡәғазы йуҡ, мына энем күчереп йазып ҡалдырған. Ҡәғаз бит крошится, аны саҡлап булмай бер ничек тә. Әткәйемдән дальшесы энем бит инде. Шунан аның малайы, Илнурның малайы тағын. Мына шулар ун өчөнчө колено килеп чыға.

(Хөснөтдинова Рәмилә Янсаф ҡыҙы яҙып алды).

### Мифтахов Зәки Хәблислам улы, 1945 йылғы

Әтейемнәр сөйләүе буйынча, бер мең сигез йөз туҡсан өчөнчө йылда эргәлә Мишәр дигән ауыл булған. Кеше күп булған. Жир аз булған. Танып йағына чығып, кешеләр ҡалын урман аша чыҡып, су кичеп йәшәй башлағанлар. Илекәй дигән боронғо ауыл бар. Бер мең туғыз йөз беренче йыллыҡ зыйарат ташлары бар. Шунан да күчеп килгәнләр. Без – Танып башҡортлары. Ҡыл Танып башҡортлары. Әтей тулы әйталмады инде. Был безнең ауыл – жир биргәнгә генә күчеп килгәнләр. Йөз дә утыз йыл ауылға. Илекәйдән, Мишәрдән күчкәнләр. Йолалар бик күп. Бер бәләкәй генә ауыл булған. Пермдан булырға тейеш. Пищинка дип атала. Әтей әйтә. Аны Иске Пищинка дип атала, ди. Историктар Сикеяз дип йазғанлар. Ул дөрөс түгел. Зыйараты ла икенче ул. Сикеяз атамасы – йылға исеме ул. Шул йылға алты километр Юғары Сикеяз бар. Тәтешледә. Ул боронғо ул. Язы – урын (местность), Сике – түбән дигән сүз ул. Бында саз ул. Халыҡ басучылыҡ белән шөғөлләнә. Малсылыҡ тағы ла. Урман, саз булған. Күл ситендә ултырған булған. Су бик йаҡын. Күлләр бик күп. Шишмәләр бик күп. Сәрби шишмәсе бар.

Ауыл йәшәй. Председатель шәп булды. Тоже бик әйбәт. Колхоз йәшәй. Кешеләргә эш бар.

Сунарсылар йуҡ. Йал итеү өсөн генә бар. Әтейләр элек йөрөй ине. Болан, ҡуйан, тейен бар. Проволканы бөгөп, ҡуйан тозаҡҡа эләктерәләр инде. Тере ҡуйан да алып ҡайталар инде. Мылтыҡ менән йөрөй инеләр. Без ҡуйаннарҙы бала чаҡта ҡыуа инек. Әзәйделәр. Төлкөләр күбәйде. Тауыҡ урлайлар. Охотник йуҡ.

Умартачылык белән эшләйләр. Ҡыр ҡортларын тоталар. Бортничество инде. Йүкә балы бик тәмле. Бында урмандар хәзер Пермдеке.

Элек балыкчылар күп булған. Шүкә, бәрҙе (шамбы), жәйен бар. Бында организация. Балыҡ тотоу буйынча үтә анда. Әзәйде хәҙер. Колхоз башланғандан бирле, йылғаға ағыу сибәләр. Сыу киптереп, кәмене алар.

Ауылда мәзәкләр йөрөй инде ул, бар алар. Хәмит бабай кеше көлдөргән бит. Бер ҡатынны алып ҡайтҡан ултыртып машинала. Буран булған. Ҡатын: уф, буран, дигән. Бабай, ууу, бына ҡайтсам, өйҙә ысын буран була, дигән.

Шул бабайның абыйы армияға киткән. Гражданский хуғыш булған. Алкиноға тиклем сборға барып, бабайны урлап алып чыҡҡан. Атлы казаклар сизгәнләр. Ҡыуып чыҡҡанлар. Был тотҡан да, кереп киткән. Ат көчлө булған. Ағизел аша йөзөп сыҡҡан. Казаклар сыға алмаған. Өс суғышта булған. Герман суғышында снайперза булған. Ике винтовка белән етмеш ике немецты атҡан. Малайы Балтачта йәшәй. Георгиевский знаклы мидалы булған. Аңламай, улы уйнатып йөрөткән. Герой булған.

Щәкән урамы бар ауылда. Хоккей уйнағанлар. Сәкән инде. Шуға оҡшаған урам.

Хаков урамы – капитан, афганец инде. Бушкилде урамы – хәлле кешеләр йәшәгән урам. Бушҡараҡ килгән кешеләр йәшәгән. Центральная урамы бар.

(Хужахмәтов Айнур Оскар улы яҙып алды).

**Сәләхова Зөһрә Сәхи ҡыҙы, 1948йылғы** (фотола –һулдан беренсе)

Борай районының Иске Бикмәт ауылыннан чемоданым күтәреп, жәйәүләп Сикиязға кийәүгә килдем. Ҡырҡ йылдан артыҡ ғөмер үтеп киткән. Иптәшем белән өч ҡыз тәрбийәләп үстердек. Утыз биш йыл рус теле һәм әдәбийәтенән уҡыттым. Иптәшем дә шул уҡ фән буйынча ҡырҡ йыл эшләде. Мал асрайбыз, баҡча үстерәбез. Шиғырләр йазам. Менә “Үзем ич бу...” дигәне.

Бер кечкенә ҡызчыҡ, чана тартып,
Төплө пийма кийеп, төренеп шәленә,
Танау тартып, мыш-мыш килеп
Әй үрмәлий тауның башына...
Пәрәүәз күл бар, су тегермәне бар ийе, ана шул Кизгән йылғасы буйында. Шунан Өсперкә күпере, Спиридонов булған, буғай, ул урысның фамилийасы, бы йаҡта ул Ишмәмәткә щыҡҡанда, ана шунда тегермән булған тағын элек. Ана шунда урыс йәшәгән тегермәнще. Көнйаҡта да бар ийе тегермән, анда урыс кешесе Мишка абый йәшәде, ул Мишка абый тегермәне.

Кейезлек басущылар күп булды, өй эшләүщеләр, пищ щығарыущылар, балта осталары. Мына без үзебез дә бәләкәйдән эрләргә үрәндек. Лампаны ҡабызсаң, керосин бөтә, диләр ийе инәйләр, күрше ҡыз белән тәрәзә төбөнә айаҡ ощона утырабыз көнжәләдән эрләргә, шуны үзебез үрәнәбез, теге эрләй торған пашаш тейдерийек. Алама нейләрне бездән эрләтәләр, колхозға щымылдыҡ суғалар, жәйәргә ашлыҡҡа.

(Йомағужин Айҙар Ғариф улы яҙып алды).

## БИГӘНӘЙ АУЫЛЫ

### Халиҡов Ҡадир Нәғим улы, 1969 йылғы

Ауылыбызға мең дә жиде йөз ҡырҡ беренще йылны нигез салына. Быйыл йубилей йылы, ике йөз сиксән йыл була. Уфа өйәзе Ҡазан йулы волысы кешеләре Йософ Ишмурзин, Ҡазаҡ Ҡалҡанов, Сарбай Ғайнунов дигән Бигәнәй ауылы кешеләренә йасаҡ түләп Бигәнәй буйына килеп утыралар, уларға жир бирәләр. Йасаҡ түләүще

кешеләр: Ишбулат Әлмәтов, Усман Ҡотлин, Бикәй Ишхаков, Темәнәй Ишемкәйев килеп утыралар. Ун йортҡа жир бүлеп бирәләр. Бер мең жиде йөз ҡырҡ сигезенще йылда туҡсан биш кеше була, бер мең сигез йөз ун алтынщы йылда – туҡсан ике, бер мең сигез йөз утыз дүртенще йылда – йөз утыз дүрт, мең туғыз йөз йегерменще йылда дүрт йөз ун ике кеше йәший. Ауылның ике тегермәне була, мәщете була.

Минең төп маҡщатым – шушы Бигәнәй ауылының шәжәрәсен төзеү. Уфада архивта да булдым, ревизийа материалларын тикшердем. Бигәнәй ауылына Темәнәй Ишемкәйев дигән кеше нигез салған. Уның алты улы булған: Ғабдрахманның ике улы булған, Абдулның алты улы, Ғабдулланың жиде улы, Ғәбдрахимныҡы – туғыз, Абдрахманныҡы – өщ. Шушы нәселләрдән Бигәнәй ауылы үсеп бара.

Борай районында Кәңгелде дигән ауыл булған. Кешеләр Кәңгелдедән айырылып щығып, иске Кәңгелде һәм Йаңы Кәңгелде төзегәннәр. Йаңы Кәңгелде ауылын биш кеше башлап ебәрә, биш йортта шулай лампа ҡабызалар. Халыҡ телендә аны Бишҡыуыҡ (лампа, пузырь), йәғни биш лампа дип атай башлайлар.

Йаңы Кәңгелде белән Бигәнәй арасын йылға бүлеп тора, күпер салына. Ике ауыл халҡы арасында тартҡылаш башлана, Бигәнәй халҡы усал булған, сәнәкләр тотоп, күпердән щығармағанлар. Сәйфелмөлек исемле кеше иң усал булған, кешеләрне ҡамсылаған, диләр. Йаңы Кәңгелделәр башҡа йул табып, йылғаның сайыраҡ урынын ҡарап, урап йөрегәнләр.

Ике ауылның да имамлары булған, ике йаҡта да мәщет булған. Колхозлашыу ощоро башланғащ, Йаңы Кәңгелделәр Щулпан колхозын, Бигәнәйдәр Йаңы йул колхозын төзегәннәр.

Мең туғыз йөз утыз биш – утыз сигезенще йылларда Верховный Совет ҡарары нигезендә Йаңы Кәңгелде ауылы Бигәнәй ауылы белән берләштерелә. Ике ауылды йылға ғына бүлеп тора. Йул ащыла, күпердән йөрей башлайлар, дуслашыу, ашҡа йөрөшеү башлана. Бөген Йаңы Кәңгелде исеме онотылған, хәзер уны бик сирәкләр белә. Хәзер Бигәнәй булып йөрей, тик безнең өщен Бишҡыуыҡ ауылы булып ҡалды. Бер-беребезне хөрмәт итеп, бер-беребезгә ҡунаҡҡа йөрешеп йәшәсәк тә, шушы ауыл белән ауыл арасында ығы-зығы сизелә, йәшәп килә.

Минең маҡсат – шушы ауылларның шәжәрәсен төзеп, халыҡны туғанлаштырыу. Шәжәрә төзеүне иң беренще шушы Йаңы Кәңгелде ауылынан башлап йебәрдем. Бөтен халыҡны жыйып, аңлатып. Бик күп кеше үзләренең бер-бересенә туған икәнен аңладылар. Шушы уҡ тәртиптә Бигәнәй ауылының шәжәрәсен дә эшләргә исәп тотам.

Хәзерге көндә Бигәнәй ауылында сиксәнләп өй бар, йөз йегерме тирәсе кеше йәшәй, башланғыщ мәктәп бар ийе. Бөгөнгө көндә мәктәп йуҡ, бөтеүенә ике йыл. Бишҡыуыҡ йағы халҡы күпләп мал, ҡорт асрай. Сыйыр маллары тоталар, сарыҡ асрайлар. Бу ауыл йағы ҡартыраҡ. Быйма, тула пасыущылар бар иде, әле шөгелләнмәйләр.

Шуны әйтмәй булмай, Бигәнәй ауылында Башҡортощтан Республикасында иң беренщеләрдән Советтар Сойузы геройы орденын алған Сәхип Нурлығайан улы Майский тыуған. Уға бағышлап бюст салырға ла ирештек.

(Абдуллина Лилиә Байыҡ ҡыҙы яҙып алды).

## БОРАЙ АУЫЛЫ

### Фәтхетдинова Эльвира Рәүис ҡыҙы, 1987 йылғы

Вострецово – ҡатнаш ауыл. Мының йартысы Казанцево була, йартысы Ҡарғалы була, Новокаргино. Дүртөйле районы Иске Ҡарғалы дигән ауылдан алты ғайлә күщеп ҡайта, һәм алар башта уҡ Идел буйына бармыйлар, алар, “грязный луг” дибез инде дальнейе поле, шунда шишмә буйына урыннашҡан булалар. Бик күп йәшәмәгәннәр анда, сизеп ҡалғаннар, Идел буйында су да йаҡын бит инде, зур Ағидел бит инде, шунда күщенеп килгәннәр былар. Алар шуңарға Йаңы Ҡарғалы дип исем биргәннәр. Ә Казанцево, Икона Божйа Матери Казанцево, шуңарға бағышлап “Казанцево” дип исем биргәннәр. Ә шунан бит инде Степан Сергеевич Вострецов безнең суғыш ветераны бит инде, зур ғына исемле бит инде, герой бит инде ул безнең. Шуңарға арнап Ҡарғалы белән Казанцевоны ҡушҡаннар, бер ауыл йасағаннар, щөнки ауыл ул тегесе аста, ул Идел буйында, ә мынысы тау битендә, шуларды ҡушып Вострецово дип исем биргәннәр. С.С.Вострецов – Граждандар суғышы ветераны.

Ҡыстыбый бешерәбез, ощпощмаҡлар бешерәбез. Ощпощмаҡ бешерер өщөн бәрәнге белән ит фаршы, ғади ғына ҡамыр, йомортҡа салмасҡа, йомортҡа салсаң, ҡатыраҡ була. Анда мин салам дрожжи, су, песок та, тоз да, май, комбағыш майы.

Муйыл ағащлары бар бездә, ҡызыл миләш, ҡара миләш, баланнар, йүкәләр, имәннәр бар бездә. Ҡуаҡлар, щитләүек ҡуаҡлары бар.Казыйаҡ (примула), мәтрүшкәләр инде, сары мәтрүшкәләр, ҡызыл мәтрүшкәләр, ромашкалар. Айыу ҡамыры (бойарышник), гөлжимеш (шиповник), ҡура жиләге, жир жиләге ҡайын жиләге, жиләк (клубника). Лягушка – баҡа, черепаха – ташбаҡа, угол – пощмаҡ, мөгөш, мешок – ҡапщыҡ, забор – ҡойма, двор (ишек алды) – ихата, крыльцо – ишек алды, хлеб – эпей.

Мама – йәшерәкләр “әней”, өлкәнерәкләр “әнкәй” дип өйрәнгән.Папа – йәшерәкләр “әтей”, өлкәнерәкләр “әткәй” дип өйрәнгән. Бабушка по линии матери – нәнәй, по линии отца – зурнәй. Дедушка по линии матери – ҡартәтәй, по линии отца – зурәтәй.Младший брат – “апайым” дибез ҡызға да, малайға да. Бер туған энекәшемә – “энекәш” дип өндәшәм, ике-өс туғаннарға аларның исеме һәм апайым дип әйтәбез, Ринат апайым.Старшая сестра – апа.Старший брат – абый.

(Абдуллина Гөлфирә Риф ҡыҙы яҙып алды).

## ДАУЫТЛАР АУЫЛЫ

**Дауытова Фирүзә Тәхәүи ҡыҙы, 1942 йылғы**
**Рәхмәтуллин Фәнис Лотфый улы, 1939 йылғы**

Безнең уҡытущы Шәкиров Наил Ғәфифович бар ийе, ул тарих уҡытадырийе. Ауыл тарихы турында ул эзләде материаллар. Мына дүрт ул килгән, шуның Дауыт баба дигәне шушы ауылға килгән. Ни өщен дигәндә, бу ауыл ағащ белән ҡапланған, ауыл булмаған инде, ағащ белән ҡапланған булған, элек бит жир күп кирәк булған инде. Шуңа бу иң тынщ урын булған, безнең ауыл. Мына безнең Әйүпов Хәмзә абыйлар бар ийе, шул урын как раз шушы Дауыт баба килеп төпләнгән урын, өщ пощмаҡ формасында, бу йаҡтан Оло шишмә ағып килә, бу йаҡтан Салҡын шишмә ағып килә, өщенще йаҡтан Утар шишмәсе ағып килә, хәзер Утар йылғасы дип йөретелә инде. Мына шулайтырып ул суның иң күп жиренә, файдалы урынға урынлашҡан инде. Ә былай инде ағащны төпләп, ул үзенә жир эшләгән инде. Шунан Дауыт ауылына килгәннән соң, бик күп, ун бер баласы булған аның, иптәше белән килгән инде ул. Шунан бер ҡызы аның булған, ун малайы булған. Шушы ҡызны ул биргән Иске Тазға кейәүгә. Шунан Утар йылға буйына, ул үзе утарын эшләткән, маллар асраған, маллар алып килгән, шуңа күрә аны Утар йылға дип атаған. Шушы шишмәләрне өс төрлегә бүлгән: тәмле суға, щиста суға, шунан соң салҡын, Утар йылға шул мал өщен файдалы дип. Шуңа күрә мына уртаға урынлашҡан инде, өщ шишмәдән, зур йылға йуҡ бездә, шушы шишмәләр инде. Ә Оло шишмәнең инде, дөресен генә әйткәндә, без ҡуштыҡ исемен килгәщ. Аның шишмәсен, мына үлде инде ул, Галийев Әхмәтфәйез бар ийе, Тимерхан шишмәсе дип әйтәләр ийе аны элек, дип сөйләде ул, но анысын точно тикшерәлмәдек инде.

Ауыл бик әйбәт урынға урынлашҡан, шишмәләр күп, урманында да шишмәләр күп. Халыҡ бик күп булған инде, щөнки аның балалары таралған. Мына бу Дауыт бабаның нәселе Ленин-Бүләктә йәшәгән, күщкән булған, ул жиденще быуын булған Ғаббас бабай, ул Ленин-Бүләктә йәшәгән. Башта ул Ленин- Бүләк дип аталмаған, Баразы-Бүләк дип аталған, щөнки безнең Ҡарағыштан ингәщ, Баразы-Бүләк дигән жиребез бар, шуңардан алынған ул, Баразы-Бүләк дигән Ғаббас бабайның бабаларының бабалары. Мына революцийадан соң инде, аны әйләндергәннәр Ленин-Бүләккә, хәзер йуҡ инде ул ауыл, бер генә кеше ҡалды. Балалары таралғаннар инде, шушы Дауыт баба безгә килгән. Баҡалыда йәшәгән Файаз абзый дигән ни бар, ул тарихны йазған булған, хәзер ул йазыу, сораштым мин, Бирскида ҡызында, имеш. Мин аның ул йазыуын үзем күрәлмәдем. Шунан хәзер бу тарихны йазыуға без өщенще тапҡыр алындыҡ. Беренщесендә Наил Шакиров абый эшләде инде, шәжәрәләрнең барысында ул эшләгән ийе. Шунан эшләде бездә Талипова Фәнирә дигән, ул татар теле, әдәбиәте уҡытадырийе, музей да эшләгәнийе мәктәптә, ул тоже йаңартты әзерәк, ну мына хәзер без өщенще тапҡыр, Борайда йәшәй ул, аның әнисе Дауыт ауылыныҡы, Зоха апа, аның ҡызы Гилфанова Гөлназ Ғәделйәновна, мына безнең маҡсат инде, ул эшләп бөтөргәщ, китап итеп бастырыу.

Без бик озаҡ ҡына палас суҡтыҡ. Саттылар тирә-йаҡҡа. Ҡоралларны үзебезнең ирләр эшләп бирде. Ну ҡул эшләренән щигү эшләре бара, әлеге вахытта шул бәйләү, мына тапочкалар, костюмнар. Бәйләйләр инде, жип күп бит хәзер, ә без палас суҡҡан ваҡытта сарыҡ йөнен эрләп. Өмә итеп, жип эрләйдерийек. Орщоҡ өмәсе үткәрәдерийек, жип кирәк бит. Ун бишәр кеше буладырийыҡ, гармун уйнарға мына Рәфим абыйларда, анда инде жыр-бийү, ул гармун уйнай, үзебез эрләйбез, үзебез жырлайбыз, шулай бик матур итеп үткәрәдерийек. Пима да бастылар Хаким абзыйлар, оста пима басущылар ийе бит инде. Өй эшләүщеләребез дә бик осталар ийе, Ғариф абзыйлар, Хаким абзыйлар.

Хәтеремдә минем, анда әле суға ғына башлағаннар ийе, Уфадан килделәр артислар, Тәнзилә Үзәнбаева һәм Хәлит Фатихов килде. Мына иң беренще алар Хәмдийә ападан, Уфаға паласны, ул вахытта әле без бик сатмайдырийыҡ, үзебездә генә ийе, алар сатып алып киттеләр. Алар иң беренще мына сиксән сумны, башта сиксән сумға саталар ийе инде, соңнан ҡиммәтләнде. Мына шулай заказ бирәләр ийе килеп, Кәшкәләүдән дә бирделәр, башҡа ауылдан, күрәләр дә инде. Туйға бүләк итәдерийек.

(Йомағужин Айҙар Ғариф улы яҙып алды).

## ИҪКЕ ҠАРАҒОШ АУЫЛЫ

**Бәҙртдинов Рим Низай улы, 1955 йылғы**

Безнең Иске Ҡарағош ауылы инде ул башта Барыщ күл буйында урыннашҡан булған. Ул күлнең тарихы ла ней инде, бик тирән күл. Анан Барыщ шишмәсе щыға башлый бит инде, Барыщ шишмәсе килеп, йылға булып ағып инде, шуңа күл образовать итә. Ул күл үз вахытында инде халыҡлар анда торған була, зыйраты да бар. Шул вахытта инде маллар төшеп үлә башлый, шунан кешеләр тирән булғащ инде, уртасы туңмаған була инде. Боздан керә дә инде маллар, үләләр. Аның ҡырында ғына шишмә була, тоже йаҡын, ул шишмә тоже урғылып аҡкан була, анысына Ҡара тәкә дигән исем ҡушалар. Ҡара тәкә төшеп үлгән була инде. Шунан халыҡ инде күщеп утырырға уйлый, бер өлеш халыҡ килеп был йаҡта таба инде. Мына әле утырған урын Ҡарағыш бер оло күл ҡырында, Оло күл дибез, Оло күл. Мында шул ауыл өщкә бүленеп китә, бер өлеше мына Ишмәмәт. Бер өлеш шунда күщкән, дигән фараз бара инде. Бер өлеше Имән ауыл образовать иткән, диләр. Ана шул өщ

ауыл барлыҡҡа килгән, биш йөз йыл элек бу була. Шунан соң бу ауыл жирне килеп тапҡащ инде Оло күл, күл бик зур күл була, аның шишмәләре әле дә күп, дүрт шишмәсе әле дә исән. Уртасында шишмә була, балыҡлар, ҡошлар күп була. И мында шушыннан Эрбет йуулы узған була, Бирскидан Екатеринбургка дибез хәзер инде, йул үткән була. Халыҡ безнең мына ошо йул буйына утырған, артыҡ әйберләрне сатырбыз дип. Бу күлнең тирә-йағы ҡара урман була. Ҡарағайлары әле мына түктергән щаҡта да, без аны түктердек, ҡарағайлары щыға ийе. Анда ҡара ҡошлар ойа ҡорған була, ҡара ҡош. Ҡара ҡошлар да була, аҡ ҡошлар да. Шунан Ҡара ҡош дигән исем ала бу ауыл. Мында дүрт кеше күщәләр. Ташбулат дигән башҡорт, Рысҡул башҡорт, Әткинә ҡарт типтәр була и Байтур. Байтур удмурт була инде, ул мосолман динен ҡабул итә дә, ауылда дүрт ырыу килеп образовать итәләр. Ун жиде өй генә күщә анда, ҡалғаннары ана шулай таралған була инде. Ағасларны кисеп, халыҡ арткандан арта инде, ауыл зур ауылға образоваться итә. Шунан меңдә жиде йөз ҡырҡ икенще йылны инде Йанышев дигән генерал мында грамота бирә, ауыл исеменә. Ә күщеүе иртәрәк була инде. Бу Кизгәнбаш волосына кергән була инде, безнең мына йылға аша ғына. Аның бер үзенщәлеге була инде. Мына ошо Барыщ йылғасы аҡҡан, теге йаҡтан Иреште йылғасы дибез. Иреште йылғасы теге йағы уже Мишкә белән Балтащ районы, быйағы безнең район инде.

Безнең ауыл тирәсендә йегерме биш күл, шуңа күрә Оло күл дигәннәр анысын. Аның ҡырында ғына, арасы биш-алты метр ғына, Ҡызылкүл дибез инде, суы ҡызыл булғанға күрә. Шунан Щоңғоло күл, аның суы төшөп тә киткән ийе. Аның суы алтмыш сигезләрдә микән бөткән ийе, анан обратно ҡалкты. Ҡырында ғына су керә торған күл бар, Су керә торған күл дип. Шунан аның ҡырында Турат батҡан күл диләр инде, туры ат батҡан. Аның ҡырында ғына Рәшидә күле диләр, бер ҡыз төшеп үлгән. Ну барысында шутласаң,йегерме биш күл инде. Анан Басыу күле диләр инде.Йаҡтыкүл – суы щиста булғанға күрә. Шунан Киндеркүле, анда киндер батырғаннар. Мына шушы нәҡ Кизгәнбаш белән ике арада инде Киндеркүле.

Шишмәләр, безнең ун ике шишмә генә бар, мына шушы Олокүлнең генә әлеге көндә дүрт шишмәсе бар. Меңдә сигез йөз илленче йылларны Йаңы Ҡарағошҡа күщеп китә бер өлеш халыҡ. Мына Йаңы Ҡарағош йул буйында инде ул. Йаңы Ҡарғошҡа күщәләр, анда тағын ауыл образовать итәләр безнекеләр. Шунан революцийанан соң инде, жир бирәләр бит инде, шунан Фрунзе ауылы образуется. Йегерме хужалыҡ Фрунзе дигән жиргә күщеп китеп, ағасларын төпләп, жир эшлийләр. Мына Ленин-Бүләк дигән ауылы, ана улар Дауытлар ауылына күщкәннәр. Аның ҡырында ғына Торатау дибез инде. Торатау шишмәсе йылға булып аға, мына әле генә көз көне, Уфадан килеп бийологлар, археологлар анда килеп эшләде. Ну безнең Фрунзеның да уже үзендә генә биш-алты шишмә, анда тағын шишмәләр күп инде безнең.

Шунан колхозлашыу щорында инде,йегерме туғызынщы йылны мына колхозға керәләр инде, анан тараладар да, йегерме туғызның азағында йаңыдан колхоз ойошторалар. Шул вахытта инде, шул щорларда инде теге ауылларда инде колхозлар ойоша, айырым колхозлар була анда. Һәр бер ауылның үзенең колхозы була. Шулай уҡ безнең ауылның ике мәхәлләсе булған, ике мәщете. Әлеге көндә бер мәщет. Бер мәщетне кисәләр инде утыз икенще йылны, икенщесен кискән булабыз утыз алтынщы йылны һәм шуңардан утыз алтынщы йылны мәктәп төзейләр. Меңдә туғыз йөз ун жиденще йылны мына перепись була, временно правительство килгәщ, перепись үткәрәләр майда, шунда өщ йөздән артыҡ двор була бездә, анда меңдә ике йөзләп кеше йәшәгән була.

Бигерәк тә инде безнең бу тарихны өйрәнә Карамов Сәләхетдин абый, аның китаплары күп хәзер. Ул үзебезнең ауылдан щыҡҡан кеше ул, элекке судйа, Краснодар йаҡларында эшләгән кеше. Шунан минем коллега, инженер-механик, хажға барып ҡайтып, мәщет салып, хажый булып йөрей. Шунан Фәридә Тимербайева безнеке бит инде. Хәзерге көндә ауылда өщ йөз уннан сиксәнендә генә төтен щыға.

Шунан алыплар зыйраты дибез инде, ауыл эщендә ул. Алар шул жирдә ҡащандыр йәшәгән булғаннар, күмелгәннәр. Без ана шунда пекарня салғанда, щоҡотҡас, сөйәктәре щыҡты инде, эре сөйәкләр, Баҡалы ауылында да бар. Барыщкүл буйындағысын кәртәләп алды мына хажый үзе. Шунан хәзрәт зыйратлары бар, бересе ҡорос хәзрәте, нищек ҡоростор инде ул, ирле-хатынлы. Икенщесе хәзрәт, аның йазмалары элеккеге фарси телендә эшләнгән ул, ҡойоп йазылған йасы ташта. Ул где-то ун сигезенще ғасырларда булған инде.

Кизгәнбашлар жир өсен суғышҡан Фрунзе ҡырында, Спорлы жир дип атала. Шунан Ҡазаҡ күле диләр инде, анда ҡащандыр суғыш йылында ҡазаҡлар килеп йәшәгәннәр. Шунда утырмалары булған, соңынан киткәннәр суғыш бөткәщ. Шунан эвакуйированный кешеләр дә булған инде. Ленинграттан килгәннәр инде алар в основном. Вахытында госпиталь да булған бездә ауылда.

Шунан Щирки төпләүе диләр инде, пещәннек. Анан Мулла күле, ҡырында мулла йәшәгән. Азый сазы, Азый күле диләр инде, Азый бабайларның баҡщасында ийе ул, шуңа Азыйзыҡы дип әйткәннәр инде. Шунан Ғүмәр бабай гел щистартҡас, Ғүмәр күле диләр инде. Ҡарамалы күл бар. Шунан Ҡарағош йылғасы бар, бездән Дауытларға табан аға ул. Анан Садри күле дибез, мына Садри бабай щистартып торған булған инде. Шунан Хаматша күле, шундай ҡартларның щистартып торған күлләре. Тағын Үгез күле, үгез төшеп үлгән инде. Шунан Кәбестә сазы, шул басыуда кәбестә үстерәләр ийе, шул сазны сибәләр ийе, шуңа Кәбестә сазы дип исем ҡушҡаннар инде. Шунан кер йыуа торған күлләр. Шадыбаш тауы бар, шул Шадыға табан киткәндә. Мәктәп ҡырында Сәмитауы, бик текә тау. Географийауҡытущысы сорағанда инде бер уҡущыдан мәктәптә: “Иң зур таулар ниндәй тау?”, тегесе “Сәми тауы” дигән инде, башҡа тау күрмәгәщ.

Тайлар йаланы бар, сабантуй була анда, Ҡортбаҡща йаланы бар. Рәжәп төпләүе бар, Рәжәп бабай төпләгән. Кем пещән щапҡан, шуның исеме. Төки малайы үлгән йалан диләр, исем шулай ҡушылған. Деңгерзек күпере бар, деңгерәгәнгә күрә.

Табан балыҡ, шунан аҡ карась, теге ҡушымтасы карп белән бергә. Алабуға, шүкә, бәрде, шамбы, щабаҡ, ҡызылкүз. Төлке, ҡуйан, терпе, тейен, бобер, рысь, пошой, бүре, айыу, куница,йенот. Аҡҡош, щелән, щарлаҡ, хәзер элек булмаған ҡошлар барлыҡҡа киләдерийе. Ҡыр үрдәкләренең туғыз төрлөсө бар, су тауығы, тетерев.

Ауылның тарихы безнең тирәнте инде ул, аущылыҡ булған, игенщелек, малщылыҡ. Тегермәннәр булған, жил тегермәне дә, су тегермәне дә. Шунан элек кейезлек басущылар күп ийе инде, пима басущылар. Тегеүщеләр, туннар тегәләр ийе, толоплар, сырмалар сырыйлар ийе. Магазиннар тотҡаннар, өщәр магазин булған. Шунан Эрбетйулында була инде ул, Кизгәнбаш дибез инде волость, анда зур базар, данлыҡлы, республика кимәлендә.

Алмағащ, ҡарағат, балан, ҡура жиләге, ҡара ҡура жиләге, баҡса жиләге, ҡара миләш, ҡызыл миләш бар. Щәйнүк, таба, мис (зур кәстрүл), табағащ, кисә тайағы (кочерга), сосҡо, йолпощ (иләк), бал ҡалаҡ, аш ҡалаҡ, жәйенкә (блюдце), щынайаҡ, йомро, кәсә, тәрлинкә, аш щумеще. Күгел (пирог с картошкой), шәнгә, төрмә (рис белән ҡабаҡ), бәлеш, туҡмащ, бишбармаҡ, тош (сәк-сәк, бауырсаҡ), тәйикмәк (әщегә бешерелә), гөбәдийә, ҡоймаҡ (щөщөгә бешерелә), эремщек.Зур әтәйнең атасы ҡартатай була, зур инәйнең инәсе ҡартый була, әтей-әнейнең апасын – аҡ әбей, абыйны – аҡ бабай диләр. Сеңлекәшнең балалары (племянники) щибәр апа дип өндәшә.

(Йомағужин Айҙар Ғариф улы яҙып алды).

## ИҪКЕ ТАҘЛАР АУЫЛЫ

### Хәйруллина Фәнзирә Вафый ҡыҙы, 1963 йылғы

Башта педучилище музыкальный бөтердем, анан заочно географический факультетны бөтердем. Уҡытущы булып эшләдем шушы мәктәптә. Шушы музейны житәкләдем нищә йыллар буйына, былтырға хәтлем, пенсийаға щыҡҡанщы.

Мәктәп ун бер йыллыҡ. Уҡущылар быйыл алтмыш туғыз-житмещ тирәсе. Әлегә ҡәдәр күп була иде, азаҡҡы йылларда әзәйзе.

Әптерәй щишмәсе бар. Анда тегермәнще Әбдрәхмән бабай йәшәгән. Иң беренще районда су тегермәне төзегән кешеләрнең бересе инде ул. Минең апа исән әле туҡсан биш йәшлек. Ул сөйләй иде, суғыш вахытында нищек итеп шул бабай балаларны сөйәк тарттырып ащлыҡтан алып ҡалған. Буа булған анда. Аҡҡош күле шул буаға тоташҡан. Иң беренще ут алған районнар. Бәләкәй генә электростанцийа йасағаннар да, шул су тегермәне дә булған.

Бейек таулар түгел бездә. Бәләкәй генә таузы бездә Ҡалатау тип йөреткән булалар. Ҡанатощ тигән тау, Бүре тауы бар. Щоҡырлар бар һәр бересенең үзенең. Ҡарағош щоҡыры ни өщен шулай аталған? Ҡарағошлар гел ҡыщҡырғаннар шул тауда.

Иске Йорт – ул Искеташтан кешеләр күщкән дә, урын житмәй башлағащ, Йаңы Тазға күщкәнще әле бу, ике щоҡор урынына урыннашҡаннар, шунда щишмә, йылға ағып йатҡан инде, шул урыннары жайсыз булған, шунан күщкәннәр әлеге Йаңы Таз йағына. Йаңы Таз халҡы аны Иске Йорт тийеп йөретә. Күщкән ауыл. Озаҡ йәшәмәгәннәр только. Бер генә зыйарат булған да, мында күщкәннәр. Мындағы әбейләр аны Иске Йорт тип сөйләйләр иде. Иске Йорт булғащ, аларның бабалары йәшәгән йорт була бит инде.

Блюдце без щынайаҡ тибез, йоморо – чашка, тәлинкә тибез тарелка, аш щүмеще, су щүмеще айырым, кәстрүлне мис, жамыйаҡ – бәләкәй табаҡ була.Грибы – гөмбә.Аҡ гөмбә, грузди, лисички, ҡайын гөмбәсе.Лягушка – баҡа, черепаха – ташбаҡа, жаба – гөбөрле баҡа, угол – мөгөш, пощмаҡ. Аш-су пешерә торған йаҡ – кәберкә. Мешок – ҡапщыҡ, зурысы арыш ҡапщығы.Хлеб – эпи, ведро – бидрә.

(Ҡотлоәхмәтова Эльнара Рафиҡ ҡыҙы яҙып алды).

### Шафиҡова Әнибә Лотфулла ҡыҙы, 1959 йылғы

Ғүмеремнең күп эш дәүере китапханада эшләүгә тура килде, утыз бер йыл булды быйыл китапханада эшләүгә. Башта сельхозны бөтердем дә, сельхозтехникумды, бер нищә йыл ғына сельхозда эшләдем, анан килеп мәктәптә эшләдем. Мәктәптә эшләгәндә щиттән торып Бөре дәүләт педагогийа институтының биологийа факультетын бөтердем. Былтыр заочно Аҡмулланы да бөтердек китапхана системасы буйынща. Анан мына туҡсанынщы йылдан башлап китапханада хезмәт итәм. Бөгенге көндә пенсийадамын, ләкин эшләп йөрейем.

Бер генә ҡызым бар, Астрахан өлкәсендә йәшәйләр, өщ онығым бар.

Мең жиде йөз ҡырҡ сигезенще йылда перепись алыу вахытында ике ауыл да булған: Иске Таз да, Йаңы Таз да. Мең алты йөзенще йыллар азағында килеп урыннашҡаннар, аннардан да иртәрәктер инде ул.

Әптерәй щишмәсе бар. Әптерәй бабай безнең Иске Тазлар ауылыныҡы булған, әтиләре килгән кешеләр булған, урыс булғаннар, Федор Маркин. Суғыштан суңғы йылларда ашлыҡларны эшкәрткәндә тоташтырып, барабанын әйләндереп, ашлыҡны щистартадыр идек,дип әнкәйләр сөйләйдер иде, улар сөйләүе буйынща. Ә аннан безнең ГЭС та төзелгәйне, беренще станцийа, суғыштансуңғы йылларда. Борай районының иң башта Иске Тазлар, Кесе Йар, Йанғызлы ауылларында ут булған инде. Йанауыл щишмәсе бар. Анан йыраҡ түгел Имәнғол йылғасы дигән щишмә бар тағы.

Вәғәлийәс йылға кебек булған элек, хәзер щоҡырға ғына ҡалды инде, суы бөттө. Без бәләкәй щаҡтауҡырға йөрегәндә дә йаз көне аның суы тирән генә буладыр иде дә, йүрей генә шунда батабыз да, кирегә ҡайтып китәбез.

Баздә Аҡкош күленә киленнәргә су йулы күрсәтеү йоласы бар ийе, хәзер йаңыща. Элек төшкән йәш киленне Аҡкош күленә суға алып баралар ийе, Аҡкош күленән су алып ҡайтырға. Хәзер суңғы йылларда инде бөтә районның йәш кәләшләре, кийәүләре анда килеп, тәнкә салалар күлгә, тәнкә салып, йозаҡ биклэп, ащҡыщын күлгә ташлайлар.

Килен иренең әсәһе менән атаһына әнкәй, әткәй ди. Элек мына борынғылар, безнең әнкәйләр инәй, әтей диләр ине, безнең зурәнәй, зурәтәйләр бабам белән әбейем була инде. Әсәй, атай – әткәй, әнкәй була.Апай, ағайға – апа, абый.Кесе туған – апайым (сеңлем, энем). Ҡыз булса да, малай булса да апайым. Аҡ әбей, аҡ бабай, щибәр апа, зур әбей бар. Минең әнкәйемде бөтә туғаннары бәлкәттәй диләр ийе – бәләкәй түтәй.

Тәйикмәк, бәлеш, тош, ҡош теле (хворост), көлщә, төрмә пешерәбез. Мәк үскән щаҡта мәк шәнгәләре пешерәләр иде.Ҡатыҡ, эремщек, сөт өсте (сметана).

Элек безнең Иске Тазлар ауылында йәшелщә баҡщасы бар ийе. Кеше ул вахытта кәбестә дә үстермәй, бик ул ҡәдәр ҡыйар да үстермәйдер ийе. Бөтен халыҡҡа хезмәт көненә шунан кәбестә, ҡыйар бирәләр ийе, суған, бөтә нәрсә. Анан алма баҡщасында алмағащ, ҡурай жиләк, крыжовник үсәдер ийе. Хезмәт хаҡына шунан калхозщыларға бирәләр ийе. Бала-щаға баҡщаға барадыр ийек инде. Алма баҡщасы сетка белән уратып алынған ийе. Ул ауылдан йыраҡ иде. Сетканы беребез бөгәрләп тора, икенщебез өстенән керәдер ийек.

Шоморт (муйыл) ағащы да бар бездә. Шуны күп итеп жыйалар ийе дә элек әнкәйләр, сөйләшеп тегермәнгә алып менәләр ийе, онно тартмайлар ийе ул көндө, шоморт тарталар ийе, талҡан шикелле әйбер эшләйләр ийе. Тарталар ийе, самауырдан ағызып, ҡайнар су салып. Шомортҡа төшәдер ийек, анан ҡызыл ҡарағатҡа, ҡара ҡарағатҡа, бөрлегәнгә, ул бит безгә жиде-сигез щаҡырым. Көпщә ашайдыр ийек, ул балтырған. Ирен йардырғыщ.

(Ҡотлоәхмәтова Эльнара Рафиҡ ҡыҙы яҙып алды).

## ИШМӘМӘТ АУЫЛЫ

### Харасов Фәнәүи Авзал улы, 1940 йылғы

Ишмәмәт ауылы Башҡортостанның төнйаҡ-көнбатыш өлөшенә керә, Кизгән йылғасы буйында урынлашҡан. Безнең Ишмәмәт меңдә жиде йөз унынщы йылның унынщы октябреннән ауыл булып урынлашҡан. Элек Ҡазырмәт, шунан соң тора-тора Ишмәмәт исеме ҡушылған. Безнең әллә ниндәй тарихлы урыннар йуҡ, безнең иң билгеле урын Ыйыҡтау дигән бер тау бар, шунда түбән төшкәщ күле дә бар балыҡлы, табан балыҡ йәшәй. Шунан ул тауға мына шушы безнең Кәшкәләүләр, Ҡарағошлар, Балтащ районнарынан, ауыллардан шунда майевкаға жыйылалар ийе. Безде инде как уҡыущылар, флагтар тотоп, шунда уҡытыущылар белән тезелешеп менәдерийек. Безнең өщен ойоштырылмаған инде ул, но без былай ҡатнаштыҡ инде. Беренще май бәйрәме.

Ыйыҡ күл бик матур, анда кешеләр йал итергә баралар. Элек аңардан ҡыш буйы боз кисеп, йомшаҡ су шул хәтлем, бозны ташый торғайныҡ, кем ат белән, кем бәләкәй сана белән. Мына шулай иттереп аны ҡыш буйы ватып ҡына алып төшерәбез дә, мискә салып эретеп, йомшаҡ су эщәдерийек.

Шунан ауыл Кизгән йылғасы буйында булғащ, алай бездә шишмә-мазар атап әйтергә йуҡ, Стапан шишмә буйы бар. Бер Степан дигән кеше, ул кем булғандыр инде, мәғайын ул, мин уйлайым, Бөйек Ватан суғышы вахытында Ленинграттан, Украйинадан эвакуацийа белән килгән кешелер ул.

Тегермән эшләгән, Журавлев Александр һәм ҡатыны Журавлева Александра бик йаҡшы кешеләр ийе. Инәйләр теге урлаштырып, йәшереп алып ҡайтҡан арышларны киптереп, төннә көйәнтә белән алып төшеп, начальство күренмәгәндә Санька авзыйны алып щығып, тарттырып менәләр ийе. Башҡа ауыллар ащығып аптырап торса да, Ишмәмәтләр шул бидрә хисабына йәшәп ҡалдылар. Аның Баҡалыда абыйы булған, Михаил Журавлев, Кәшкәләү тегермәнендә лә шул, алар бер туған булған. Кизгән йылғасын буып, су тегермәне ҡорғаннар. Бу эштә башлап йөрүще Имән ауылы кешесе Файырша ҡарт булған, әле башта иң беренще. Соңыннан бу тегермәнне Бөре шәһәренән килгән Капустин дигән бай зурайтып салдырған, ә аннан соң шушы Санька авзыйлар семйалары белән бер жирдән таралғаннар инде ҡайандыр, өщ туған. Алар ҡайанщыҡҡаннары билдәле түгел. Зыйараты Ишмәмәттә, урыс булса да үзебезнең зыйаратҡа күмәбез, дигәннәр инде, үзе дә күмегез дип әйткән инде мосолманлар белән бергә. Щөнки ул мосолманнарга бик күп йарзам итте.

Мең дә туғыз йөз икенще йылларда кещ кенә мәдрәсә салғаннар, мулла булып Әхмәт Хажи эшләгән. Хасбулат ҡарт ул Иске Кизгәннән килгән, Иске Кизгәннән килеп Баҡалыға, шушы сигез домның берсенә урыннашҡан. Шушы Хасбулатның бер малайы Ишмәмәткә килгән Әхмәт Хажи, бер малайы Баҡалыда ҡалған. Ә шушы Хасбулатны Баҡалы белән ней арасында үтергәннәр. Берәүләр әйтәләр, Кизгәнбаш базарынан ҡайтҡанда нищә тәнкә аҡща өщен үтергәннәр дип, ә берәүләр әйтәләр, Дауытлар белән урман өщен бәхәс булғанда, шуның өщен дауытлар үтергәннәр дип. Меңдә туғыз йөз жиденще йылда мәщетне зурайтып салғаннар. Революцийадан соң мәктәп итеп үзгәртелгән, аны азаҡтан күщереп, балалар баҡщасы итеп салдылар.

Бөйек Ватан суғышында ҡатнашҡан житмеш ике кеше, утыз жидесе үлеп ҡалған, утыз бише исән ҡайтҡан. Эвакуацийаға Украйинадан ике семйа килгән биш кеше, Белорусийадан бер семйа килгән ике кеше. Бөгенге көндә ҡырҡ биш өйдә төтен щыға, йөздә биш кеше йәшәй.

Мына безнең ауылның күренекле кешеләренән Мөхәметдинов Ибрагим Хәйбрахман улы, утызынщы йылғы, ул башҡорт, башланғыщ белемне Ишмәмәт ауылында ала, бишенще, алтынщы, жиденще класларны Дауытлар ауылында, сигезенще, туғызынщы, унынщы класларны Йаңы Кизгән урта мәктәбендә уҡый. Илленще йылда Совет армийасына алына, Ульйановский училище связида уҡый, с отличийем тамамлап щыға, илле өщенще-илле туғызынщы йылллардаМахачкалада, илле туғызынщы-алтмыш бишенщейылларда Германийада, Магдебург шәһәрендә хезмәт итә, алтмыш бишенще-алтмыш жиденщейылларда Саратов областенда войскада, алтмыш жите-житмеш алтыдаТуркменийада начальник связи дивизии вазифасында хезмәт итә, житмеш алтынщы йылда Туркистан военный округында в качестве старший офицер штаба связи в звании подполковника, житмеш туғызынщы йылда Совет армийасынан увольняться итеп ҡайта. За службу Родине третьей степени ордены белән бүләкләнә.

Ауылдың исеме, әллә бар ул Ишмәмәт дигән кеше, шуңардан ғына йазмадылармы икән. Ә Ҡадырмәт дип, щөнки аңарға иң беренще грамота бирелгән булған шушы ауылға утырырға.

Шунан безнең зур байар жире бар Уңдарышево, теләмәсәңдә ашлыҡ бирә торған басыу ул. Хәзер инде ҡара урман басты, ҡуйан да йөрей алмый. Шунан Тегермән быуасы бар, балыҡлы бик әйвәт урын булды инде.

(Йомағужин Айҙар Ғариф улы яҙып алды).

## КӘШКӘЛӘҮ АУЫЛЫ

### Муллаҡаев Реавис Рифҡәт улы, 1949 йылғы

Безнең элек-электән ҡалған апайым Хәмәтдин хәзрәт дигән кеше.Бик уҡымышлы кеше булған инде ул Хәмәтдин хәзрәт. Мәлик абый шуның энесе, ул беренще уҡытущы. Шуның истәлекләре әлегә ҡәдәр саҡланған, йылйазма булып. Зурнәйләрнең, ата-бабаларның сүләгәннәрен әледә хәтерләйем, щөнки мәктәптә крайны өйрәнү бар ийе, без анда бик актив йөрейдерийек. Бик актив булды Фәхрази Фәйсолтанович.

Атмаларға без бик күп ихтибар итәбез, щөнки анық үзендә күпмелер сер йата. Әйтәләр бит инде: “Тел астында тел бар, жир астында йул бар”, мына шундай мәҡәл бар. Мына шуның өщен без атамаларның хәр берсен өйрәнгәнбез. Атамаларның күбесе кеше исеме белән бәйле, хайуан исемләре белән дә бәйле, мәсәлән, Әхмәр ҡул бар, шунан Хәйбәт тауы, Хәсбулат таулары, Ғәбдрәхим ҡойосо, Вәғиз йаланы, Рәхимә щоҡоро, Үрәзи шишмәсе, мына былары кешеләр белән бәйләнгәннәр. Мәсәлән, мына Әхмәр ҡул дип ни өщен аталған, безнең Советлар Сойузы Геройы ошо ауылдан бит инде Ахмет Закиров, шушы ауылда тыуған, шушы ауылда үскән. Анық йыраҡ бабасы Әхмәт, мына элек тирә-йаҡ урман белән ҡапланған булған, айыу алып ҡайта жәйә-уҡ белән атып, мылтыҡ-фәлән булмай бит инде, ҡораллар булмай. Шунан айыуны атып алып ҡайта да, болдорына сала үлгәндер инде дип, шунан иртән торса, айыу терелеп басҡан була.

Шунан соң мына Үрәзи шишмәсе, безнең мына таллыҡлар басты инде, элек бөтен ауыл халҡы шушы Үрәзи шишмәсенән су эщте. Үрәзи шишмәсе изге урын дип саҡланадырийе. Минем зур әнейем йөз дә биш йәшкә ҡәдәр йәшәне, мине дүрт йәштән ул үзе белән йөретте, анық белән дәже көйәнтәләп мин суға да барадырийем. Башта баралар ийе, башта йуынып алар щиттә генә йырғанаҡта, анан бисмилаларын әйтеп намазды уҡыған щаҡлары бар ийе. Шунан соң шулайтып бу суны бик ныҡ изгеләп тоттолар. Уразай дигән кеше булған, шушы жирлектән. Бу Уразай дигән кеше батша сәйәсәтенә ҡаршы щығып, халыҡ арасында аңлату эшләре алып бара, шунан хөкүмәтнең ҡыйырсытыуына риза булмасҡа өндей халыҡны, әлбәттә, мының өщен аңа зур эзәрлекләүләр көтелә, мыны эзәрлеклей башлайлар. Шунан соң хәзер бу Асҡын йағына урманға щығып китәргә мәжбүр була, ә ғайләсе мында ҡала, шушы урында. Шунан соң хәзер эзәрлеклей-эзәрлеклей мыны тота алмағащ, йәш кенә ҡызы була мының, йәш ҡызын алып щығып, мына шул Үрәзи шишмәсенең урынына барып бу ҡызны йандыралар. Шунан соң зурнәйләр сүләйдерийе инде, ана шул йандырған урындан, анық күмелгән урынынан шишмә щыҡҡан,ди. Мына бу легенда. Мына шуның өщен халыҡ аны бик ныҡ изге урын итеп ҡабул иттеләр.

Анан соң мына тағын Әүлиә шишмәсе бар, бу шишмә тау башында. Анда “Молодежь, берегите нашу ценность” дип тимер белән йазылып ҡуйылған. Бу шишмәнең сере шуңарда: ҡайсы бер кешегә щыға, ҡайсы бер щыҡмый. Мына шундай сәйерлеге бар.

Салҡын шишмәбез бар Фрунзеда. Андада халыҡ ҡулланды. Салҡын шишмәне хәзер Камилә шишмәсе дип йөретәләр, щөнки Камилә әбей үзе баҡыйлыҡҡа күщкән ваҡытта улына васыйат итеп ҡалдыра, Зөлфәр дигән улы бар ийе. Мына мин Камилә әбейне дә, Зөлфәр улын да хәтерләйем, без Фрунзеға йөрейдерийек, зур инәй шул йаҡтан булғащ. “Улым, донйалыҡта мәшәҡәттең дә мәшәҡәте синең өщен ул Салҡын шишмә булсын”, дип шундай васыйат ҡалдыра, шушы улы инде әнисенең сүзенә тоғро ҡала, Салҡын шишмәне постойанно ҡарай, щистарта. Шунан соң хәзер Камилә шишмәсе дип атадылар.

Торатау легендасы бар бит инде, щөнки зур инәй сүләйдерийе.Йаңғырау тау дипме, анда элек халыҡ жыйылған. Жыйыннар булған ана шул Торатауда. Шунан соң ул Торатауның башында ғына шишмә щыға, Торатау шишмәсе дә бар. Шунда батша ҡеуәтенә ҡаршы жыйылып бит инде киңәшләшкәннәр. Анан соң мына Ҡарыш ауылында безнең Батырша, Абдулла Ғәлийев, мына шул Батырша Хатмулла хәзрәт белән бәйләнештә булғаннар. Шушы Батырша, аны Кизгәнбаш мулласы дип тә йөреткәннәр. Кизгәнбаш мына Ҡарағышҡа где-то

ике генә километр, терәлеп тора ул, элек волость булған. Шунан соң шушы Кизгәнбаш мулласы да, Ҡарыш мулласы да бик күренекле кеше була инде. Аның хаҡында материаллар мына Ҡарышта да, бездә лә бар ул, туплағанмыз. Шушы даже Батырша да, халыҡны жыйып, ошо Торатауда жыйылыш үткәргән була, шуның өщен Йаңғырау тау булғас,Торатау дип атағаннар. Торатау – бейек тау ул, анда ағас үсә, но башыннан арҡылып шишмә аға инде.

Отец – эти, мать – әни, отец – эткәй, мать – әнкәй.Бабушка – зур әней, бабушка – нәнәй, дедушка – зур этей.Младший брат –энекәш, младшая сестра – сеңлекәш, младший брат, младшая сестра – апайым.Старший брат –абый, дядя, младший брат отца – абзый, старшая сестра – апа.Теща – бийанай, әби, отец – бийатай, бабай.Килен, кейәү, жизнәй, жиңгәсәй. Золовка – ҡайынсеңел (хатын-ҡызға), ҡәйнеш, ҡайнаға (ирләргә).

Шукә, алабуға, щабаҡ, хариус бар. Йүкә, усаҡ, ҡайын, имән, ҡарама, зирек, ҡарағай, саған, элмә үсә. Боярышник – айыу ҡамыры, ҡамыр жимеш; шиповник – гөлжимеш; балан, миләш, муйыл, ҡарағат, ҡура жиләге үсә, клубника – жир жиләге, земляника – ҡайын жиләге. Самец – ата, самка – инә: ата эт, инә эт, ата ҡаз, инә ҡаз.Лягушка – баҡа, черепаха – ташбаҡа, божья коровка – кигәүен ҡаш (кигәүен килә ҡас, ҡас, ҡайда осоп китә, ҡыз баланың тормош иптәше шул йаҡтан була). Угол – мөгөш, мешок – ҡапщыҡ, хлеб – әпи, ведро – бидрә, коромысло – көйәнтә, воробей – шыпщыҡ, шерстяные носки – ойоҡбаш, зимняя шапка – бүрек, кәпәс, летняя кепка – кипке, түбәтәй.

Элекке мына жите ырыу булған, шунның өще генә ҡалды. Иң оло Босҡон нәселе, мин үземдә шушы Босҡонға керәм. Ул электән иң таралғаны. Тағы Сәғит нәселе бар, анан Тысҡан нәселе, мынау хәзрәтнең йазмаларында Мөстәкәй дип тә хәтерләгән, Йулдаш, Биктимер, алар йуҡлар ищ бездә. Ҡалды Босҡон, Сәғит, Тысҡан нәселе, иң зурысы Босҡон.

Мищ щығаралар, шунан мына элек-электән ҡалған ҡул осталары, мына ошо как раз Босҡон нәселе Хаким хаҡында сүләдем бит инде, мин уҡыдым Әсфәндийәровларның, Хисәметдиноваларның китапларын, анда мына шушы Йансәйет ауыллары күскән, Хакимнәр ҡатай нәселенекеләр икән. Аларның тамғалары балта, щүкеш, тырма, ураҡ, бездә дә основной ҡораллар шулар бит инде.

(Йомағужин Айҙар Ғариф улы яҙып алды).

## ҠАЙЫНЛЫҠ АУЫЛЫ

**Нәсибуллина Зинфира Фәнүс ҡыҙы, 1973 йылғы**

Безнең ауылда Хакимова Венера Хатмулла ҡызы бик күп бәйетләр йаза, әле ул пенсийада. Уны әйтмәй китмәй булмай. Аның бәйетләре бала щаҡта үлгән кешеләргә бағышланған. "Мөршидә" бәйетен сөйләп үтәм.

Әти-әниле татыу торғанда,
Ҡайғы килде бер матур ҡызға.
Әнисе үлде,
Ҡыз йәтим ҡалды,
Ғөмөрлеккә ҡайғы күрергә.
Әтисе аны бик йаратты,
Ҡыйнамады, бер сүз әйтмәде,
Тик йауыз хатын
Ҡара йөрәкле,
Ирен йауыз эшкә өйрәтте.
"Ирем, мин сине йаратыр идем,
Әгәр шушы ҡызың булмаса,
Йә утҡа ташла, йә суға ташла,
Булмасын ул йаҡты донйада.
Бернән-бер көндө этисе ҡызға:
"Әйзә, ҡызым, зыйаратҡа, – тиде,
–Әнәйең ҡәберен күреп ҡайтарсың,
Баш ощона щәщәк салырсың".
Эти ҡулында йалтырый пыщаҡ,
Жыйған щәщәкләре бер ҡощаҡ.
"– Әти, син мине суйсаң да риза,
Нищлим соң мин, бәхетем булмағащ?"
Суйдым баламны, ғәзиз баламны,
Йауыз ҡатын сүзен тыңлағащ.
Суйдым баламны, ғәзиз баламны,
Тормощомда йәмнәр тапмағащ.

Был бәйеттән тыш, Венера ападың "Гүзәлиә", Илмира беләнИльвира", "Ләйсән", "Филус" бәйеттәре бар.

Ҡайынлыҡ ауылында өщ йөздән артыҡ кеше йәший. Ун бер йыллыҡ мәктәп бар. Мәщет бар, аны минең иптәшем салдырды. Үзем китапхана мөдире булғащ, төрле мероприйатийелар үткәрергә тырышам. Табикмәк бәйрәмен бер ике-өщ йыл үткәрә бащланыҡ. Науруз, сабантуйлар үткәрәбез, тирмәләр ҡороп.

Ауыл халҡы ҡош-ҡорт асрайлар, умарта тоталар. Сыйыр малын күпләп тоталар, хәзер кәзә дә асрай башладылар, үрдәк, ҡаз асрайлар.

(Абдуллина Лилиә Байыҡ ҡыҙы яҙып алды).

## АБЗАЙ АУЫЛЫ

### Хәкимова Раушания Рим ҡыҙы, 1973 йылғы

Мин Абзай ауылы турында сөйлимен. Тыуған төбәкне уйлағанда уның тарихы, үткән байлығына соҡланасың.Абзай ауылына мең дә жите йөз siксән өсенче – мең дә жите йөз туҡсан өсенщейылларза нигез салына. Тарихи мәғлүмәтләр буйынща, нигез салыущылар булып Биктуған Абзайев, Әбделзәлим Мөслимов тора. Шушы йаҡта бик зур ауыл була, пощталары, зернотоклары туҡсанынщы йылларза ғына бөтә. Ауыл ултырған жире бик матур, уныикегә йарып Ҡойашлыжылғасы аға. Аның бер йағында башҡортлар булса, икенсе йағында типтәрләр була. Ауылда иң беренще основное население башҡортлар була, шунан соң типтәрләр Ҡазан йағыннан жир сорап киләләр һәм уларны населять итәләр. Шул вахыттан бирле ауылда ике зыйарат була, әлеге вахыттала шул ғәзәт саҡлана. Жылғаның бер йағында – башҡорт зыйараты, икенсещендә – типтәрләр зыйараты.

Борай районы халҡының сөйләш үзенсәлеге бик ҡызыҡлы. Бездә “ди” дип сөйләшәләр, “ти” дип түгел. Мәсәлән, тәтешлеләр “ти” дип сөйләшә: “шулай ти”, “былай ти”. Борайлар “иш” ди: “шулай иш”, “былай иш”, “алай итмә инде иш”. Без шулай сөйләшкәщ, Борайдан икәнне барсы да белеп торалар. “Шулай эшләдек”, диләр, ә без “шулай ҡыйыштыҡ” дибез. “Ҡойма”ны Ҡаратамаҡта – “текмә” диләр.

Гөлйемеш – гөлжимеш, йер йеләге – жир жиләге, клубника – баҡща жиләге, тәлмәрйен – баҡа, ҡамҡа – щыпщык бөжәге, мөйөш – мөйөщ, бощмаҡ, ҡапсыҡ – ҡапщык, биҙрә – бидрә, турғай – шыпщыҡ, өләсәй – дәү әний, олатай – ҡарт әтий, дәү әтий, әсәйҙән кесе кеше – сеңлекәщ, кесе ир туған – энекәш, атанан өлкән – абзый, апа, алма әбей, бал әбий, йөн ойоҡбаш – жөн ойоҡбаш, боҙ өҫтөнә ҡалҡып сыҡҡан һыу – туш.

(Абдуллина Лилиә Байыҡ ҡыҙы яҙып алды).

## ҠАРАТАМАҠ АУЫЛЫ

### Закирова Нәзиә Ҡәүи ҡыҙы, 1964 йылғы

Унынщы класты Ҡайынлыҡ ауылында бөтердем. Башҡорт дәүләт университетында уҡыным, уны бөтергәщ инде, Ҡаратамаҡ ауылында эшләдем, анда йәшәдем, мәктәптә уҡыттым, хәзер дә уҡытам, эшемде бик йаратам. Шул уҡ вахытта инде, шушы университетта уҡығанда, фольклор жыйып, диалект сүзләр жыйып, тикшерә инек. Бик күп йылдар буйына ауылдың шәжәрәсен эшләдем. Йардам итеүщеләр булды.

Ҡаратамаҡ ауылының нищек барлыҡҡа килеү тарихы бик ҡызыҡлы. Күщмәкәй дигән жирдә бер ауыл булған, шул ауылдан жите кеше Ҡаратамаҡ ауылына күщеп килгәннәр. Ҡушманаҡҡа ла, Абзайға ла шушы ауылдан күщеп килгәннәр. Былар килеп урынлашҡаннар, өйләр салғаннар. Безнең ауылның төп кешеләре – шушы жите кеше булған. Әлеге вахытта шушы жите кешенән өщөнөң шәжәрәсе безгә ҡәдәр килеп житкән. Элекке вахытта үззәрендә жирләре булған инде, игенщелек, малщылыҡ менән шөгелләнгәннәр, балык тотҡаннар.

Бу төп татар ауылы, әлеге вахытта башҡорттар да бар, марыйлар да бар. Бик дус, татыу, бердәм йәшәй халыҡ. Үзем филолог булғащ, диалект сүзләр ҡызыҡсындыра. Аралашҡанда диалект менән сөйләшәбез: “бармайым”, “ҡайтмайым” дип. Бездә башҡорт теле менән татар теле бергә ҡатыш: саф татарща, саф башҡортща ғына сөйләшмибез. Шундый диалект бездә. Без башҡорт телен йаратабыз, ул дәүләт теле бит инде. Балалар рус телендә уҡысалар да, башҡорт телен бик йаҡшы уҡыталар. Уҡыущылар, конкурстарда ҡатнашып, призлы урыннар алып ҡайталар. Йаңыраҡ Уфада Нәсимә Фагимовнаның уҡыущылары урын алып ҡайттылар. Башҡорт телен уҡытыу йаҡшы ҡуйылған, балалар бик йаратып уҡыйлар. Башҡорт теле бит – йомшаҡ тел, матур тел, мин үзем дә йаратам башҡорт телен. Унда нищек ишетелә – шулай йазыла.

Мин үзем эзләнергә йаратам. Щиттә булған ауылдашларымның нәселен тикшерәм, суғышта булғаннардың, әленән-әле щығып тора, бик күп йаңылыҡтар табыла.

Ауылыбызда элек-электән байтаҡ йолалар саҡланып ҡалған, мәсәлән, ҡарға боткасы, сабантуйлар бик күңелле үтә. Науруз бәйрәмен бик йаратып, бөтен ауыл менән бергә үткәрәбез. Март айында. Балаларға алдан щиғырлар таратып бирәбез, ҡунаҡлар щаҡырабыз, бәйрәмгә матур табын әзерләйбез. Аннан ары ҡара-ҡаршы жырлар жырлайбыз. Йегетләр бер төрле жыр жырлай, ҡызлар бер төрле, балалар бер төрлө. Күпщелекощраҡта ололар ҡатнаша.

Тәбикмәк бәйрәме лә бик күңелле үтә. Бәйрәмгә килгән һәр бер кеше берәй ризыҡ бешереп килә, тәбикмәкме, башҡа әйберме. Һәм һәр бер кеше жырмы, бейеүме әзерләп килә. Бәйрәмне йанварь айында жырлап, бейеп, күңелле үткәрәбез. Рецептар менән бүлешәбез. Варенье бәйрәме шушылайыраҡ үткәрелә, тик уны жиләк-жимешләр бешкәщ, көз көнө үткәрәбез.

Ауыл халҡы менән барлыҡ милли бәйрәмнәрне шулай үткәрергә тырышабыз: сигезенще март, йаңы йыл, башҡа профессиональ бәйрәмнәр һ.б.

(Абдуллина Лилиә Байыҡ ҡыҙы яҙып алды).

## ҠОҘАШ АУЫЛЫ

**Әхтәриева Финиә Әхмәтнур ҡыҙы, 1958 йылғы**

Шушы ауылда ғүмер буйы йәшәдем, утыз сигез йыл уҡытуцы булып эшләдем. Ауылда унынцы класты бөтергәц, Бирскийза литературный факультетта уҡыдым, аннан Ҡозашҡа ҡайттым.

Безнең ауыл мең дә жите йөз утыз – мең дә жите йөз утыз дүртенце йылларда барлыҡҡа килгән, дип әйтелә. Эске йылан ырыуына керә,дип йазылған. Ауылда мең дә сигез йөз сиксән житенце йылдан революцийаға кәдәр мәщет булған. Әнийем сөйләүе буйынца, мин тыуған йыл (мең дә туғыз йөз илле сигезенце йыл) мәщетнең манарасын кисеп аударғаннар. Ҡартлар йыладылар, дидер ине әнийем. Ике мең дә өщенче йылда безнеңэшҡыуарыбыз, минең уҡыуцым Хасанов Әнфи Әлфит улы әтисе исеменән мәсеткә нигез салдырды һәм ике мең дә туғызынцы йылда мәщет салынып бөтте. Мәщеткә ауыл халҡы теләп йөрей, муллабыз бар. Никахларны шунда уҡытабыз.

Ауылның тарихын сөйләгәндә шунда туҡталмай булмай: Вахитов Малик Атыевич – безнең ауылның иң күренекле кещенең бересе, мәктәпкә нигез салыуцы. Аңа мемориаль доска ҡуйылды. Ул мең сигез йөз туҡсан сигезенце йылда тыуған, ә мең туғыз йөз туҡсан икенце йылды үлде. Ул безнең әти-әниләрне уҡытҡан. Тәүдә ул Бирскийза курстарза уҡып щыҡҡан. Шушы мәктәпкә нигез салыуза ул актив ҡатнаша. Бер мең туғыз йөз ун сигезенце йыл, гражданлар суғышы ощоронда, мәктәп ащыла. Иске мәщетнең зданийесында мәктәп булған. Начальный кластар ғына булған, бишенце кластан күрше ауылға йөреп уҡыдыҡ, биш-алты щаҡрым. Житмеш бишенсе йылда мәктәпкә (иске мәщет зданийесына) пристрой эшләделәр, шунан туғыз йыллыҡҡа әйләнде. Хәзерге көндә лә эшләп килә мәктәбебез. Әлеге көндә лә балалар уҡый, бик матур ремонт йасанылар, түбәләрен йаптылар. Мәктәп йаны участкасында бик матур баҡщабыз бар.

Бик матур шәжәрә бәйрәмләре үткәрәбез. Ул бәйрәмне үткәргәндә безнең аҡсаҡалыбыз Багауетдинов Хәлил Садриевич дигән авый бик йардамитә. Сиксән дүрт йәштә, ул уҡытуцы булып та эшләде.Шулай уҡ ауылда зурлап сабантуйлар, башҡа ауыл бәйрәмләре үткәрелеп тора. “Семйа года” дигән конкурс, алтын туйлар, тыуған көннәр йыш үткәрәбез.

Йаңыраҡ, беренсе октябрь, ҡартлар көнен үткәрдек. Матур итеп бүләктәр тапшырдыҡ, жырлар жырланык, шиғырлар сөйләнек. Ололар күңелләре тулып, йылап утырдылар. Йаңы йылды тышта үткәрдек. Бына без дә инде, бывшый уҡытуцылар, йыйылышабыз, осрашабыз, шиғырлар да йазыштырған булабыз. Шушылай бик матур йәшәпйатабыз.

(Абдуллина Лилиә Байыҡ ҡыҙы яҙып алды).

## ҠОЛАЙ АУЫЛЫ

**Ғилмиянова Фәриҙә Мәхсән ҡыҙы, 1956 йылғы**

Техникум бөтердем, мәктәптә эшләдем, вожатый булып та эшләдем, китапханала да, татар теле уҡыттым. Әле пенсийадамын.

Ҡолай ауылы тарихы, күренекле кешеләре хаҡында сөйләп үтмәксемен.Бу ауыл меңдә жиде йөз жигерменщейылларда барлыкка килгән. Тәүдә башҡортлар килеп урынлашҡан булғаннар, аннан Себергән ауылынан Максютов капитан килеп, ул үзе жыймакщы булған. Аннан безнекеләр Себергән жылғасы буйына күскәннәр, шунан мишәрләр, урыслар, марыйлар килеп урынлашҡанлар. Жирләр өсөн суғышҡан халыҡ. Элек бездә завод та булған, басыущылыҡ эшенән башҡа, хатын-ҡыззар жип әзерләгәннәр, сарыҡ жөннәренән тула басҡаннар, төсләр ҡушып, щигеү беләнбулашҡаннар. Без бәләкәй щаҡларда ла щигеү щигеү белән булаща идек. Ауыл халҡы бик уңған. Ир-атлар арбалар, мини тракторлар, самауырлар эшләп, сыу баклары эшләгән бабайларыбыз бар иде. Ауылда мөржә сығарыущы данлыҡлы абыйлар бар иде. Токарь абыйыбыз бар иде Фәнәғәт дигән. Бездә Дан ордены кавалеры бар, Ҡашапов дигән кеше. Уға ауылыбызда таҡтатащлар ащылды.

Мәщетләр ащылды (ике мең сигезенце йылда Әл-Нәби мәщете), үзебезнең уҡыущылар обелиск ащтылар. Нурисламов Борис дигән уҡыущыбыз ике мең туғызынщы йылда буа эшләде. Шулай ауылны уйлаған, ҡараған данлыҡлы кешеләребез күп.

Әлеге көндә ауылда йөз дә жигерме өщ өй бар, балалар белән барлығы өщ йөз дә жигерме өщ кеше йәший. Ауылда бик матур йәшәгән йәшләребез бар. Начальный мәктәп бар: жиде бала уҡый, дүрт класс, бер уҡытыущы уҡыта.

Минең кеүек йәштәге быуын вәкилдәре “Миләш” ансамблен ойоштордоҡ. Руководителе – Сәйетгалийева Финә Әлфит ҡызы, ауылдың старостасы ла. Без бөтен ауылдағы йардамға мохтаж кешеләрне ҡарайбыз, жырлар да жыйабыз, ансамблдә жырлыйбыз, ҡурщаҡ театрлары эшләйбез. Алар белән районларда ла, ауылдарза ла щығыщ йасадыҡ. Без ололарның хәлләрен белеп, айырыуса йанғыз йәшәгәннәргә йардам итәргә, эштәрен эшләшергә йөрейбез. Йардам итәргә тырышабыз барсына ла бар эштә лә. Ауыл халҡы бик бердәм, аллаға шөкер. Мәщетләргә йөрейбез, Ураза, Ҡорбан ғәйете бәйрәмнәрен үткәрәбез. Выставкалар үткәрәбез.

Ауылыбыз бик матур. Ауылның ике башында ла шишмә бар. Йуғары ощ дип атыйбыз инде, анда – Салҡын шишмә бар. Ике шишмә ҡушылған жирдән Көмөшлө жылғасы башлана. Аңа буа эшләделәр. Бик күп балыҡлар тоталар: карп, алабоға, щүкәләр. Шулай бик матур йәшәп йатабыз.

(Абдуллина Лилиә Байыҡ ҡыҙы яҙып алды).

**Ғәлләмова Әлфиҙә Шәмси ҡыҙы, 1942 йылғы**

Мин Борай районың Түгәрәк ауылында туғанмын, шушы Борай районыкы ул. Шунан соң тормошҡа щыҡтым Ҡолайға. Шунан инде Бирскийдә уҡыдым, педагогическийда, биологический факультетны бөтердем, шунан утыз алты йыл Ҡолай ауылы мәктәбендә эшләдем. Шул ауылда кейәүдәмен.

Ҡолайда биологийа ғына уҡытмадым, тәүдә начальныйдарды уҡыттым, анан соң пенсийаға щыҡтым инде. Ғүмер буйына уҡытыущы булдым.

Ҡолай ауылында озаҡ йыллар йәшәйем. Мин бәйеттәр үрәм, ауылда үткәрелгән һәр бер йолаларда ҡатнашырға тырышам. Йаңыраҡ ҡына иске туй йолаларын тергедеп, су йулына бардыҡ, су йулында үзем йазған шиғырымны сөйләдем, бик йараттылар. Су алып, тәнкәләр салып, йәмне генә үтте. Ишек алдына ҡайтҡащ, киленне төщергәндә тағы бер шиғырымны сөйләдем. Мин шулай ауыл халҡының күңеленә матурлыҡ үрергә тырышам.

Ауылда кем үлә, аларны озатҡан уаҡытта уның турада шиғырлар йазам. Мин аларның һәр бересен дә беләм, ниндәй йаҡшылыҡтары бар, шул йаҡшылыҡларынан бик матур итеп бәйеттәр үрәм. Әгәр дә мин берәй кешегә бармасам, үпкәләйләр миңә. Улай ғына түгел, ауыл халҡының тыуған көннәренә лә шиғырлар йазып бүләк итәм: алтмыш йәшме, сиксән йәшме... Ошо айҡанлы клупта йыш ҡына матур щаралар ойоштороло. Шунда ҡатнашам.

(Абдуллина Лилиә Байыҡ ҡыҙы яҙып алды).

## ҠУҘБАЙ АУЫЛЫ

**Ғәрифуллина Вәрисә Шәрифулла ҡыҙы, 1958 йылғы**

Мин уҡытущы булып эшләдем ун жиде йыл. Бәләбәй педагогийа ущилищесында уҡыдым.Башта башланғыщ класларды уҡыттым, анан соң тарих фәннәрен уҡыттым.

Беззең ауыл электән бик зур ауыл булған. Мына мин хакимийәттә дә эшләдем, ауыл хакимийәтендә йегерме йыл эшләдем. Мин эшләй башлаған щаҡта дүрт йөзгә йаҡын кеше бар ийебеззең ауылда. Хәзер йөз сиксән тирәсе, байтаҡ кәмене. Бөгенге көндә мәктәбебез дә йуҡ, ике мең беренще йылда бик матур мәктәп салынғайны. Балалар саны кәмеү арҡасында, йаңы закондар да щығыуынан, оптимизацийа, беззең өщен бик ҡулай булмады инде ул. Мәктәптең зданийесын Мортаза Ғөбәйдуллович үзе килеп ащҡан ийе. Әлеге көндә здание буш тормай, унда ауыл хакимийәте, фельдшерский пункт, тағы ла ауыл библийатекасы, ветеринарный пункт та, клуп та шунда. Әле пощта ла шунда күщте.

Бына беззең ауылға кергәндә Танып йылғасы бит инде, Танып буйында ғына урыннашҡанбыз. Шул йылғала сыу кереп үстек, ҡомайаҡтары бар ийе. Ҡомайаҡ – сыу керә торған урын, пляж дип әйтәбез үзебезщә. Ҡомло урыннары бар ийе йар буйында әллә нищә урында, шунда ирләр ҡомайағы, ҡызлар ҡомайағы бар иде. Ҡызлар ҡомайағында ҡызлар керә ийе күберәген, ирләр йағында – ир кешеләр керә. Танып йылғасынын сүзе электән (без тыныбыраҡ аҡҡан урынында урыннашҡанбыз инде), шул тынып аҡҡан йылға сүзенән щыҡҡан дип әйтәләр. Быстрый Танып дип әйтелә ул бөгенге көндә, тарайған сайын йылға шәберәк аҡҡандыр, үзгәреп тә киткән исеме.

Беззең ауылға мынан барған щаҡта Ыйыҡ тауы бар. Анда ҡазаҡлар йәшәгән суғыш вахытында, шул тауның артҡы йағында. Шуға “Ҡазаҡлар тауы”дип атала. Әлеге аныңщоҡырлары бар. Жирдән йортлар йасап кергән булғаннар алар, урыннары бар. Ыйыҡ тауында аҡбур щығарғаннар, аҡбурны төйеп, халыҡ Борай базарына китереп сатып, үзенә ризыҡ-фәлән сатып алған инде. Беззең ауылдың халҡын ащлыҡ вахыттарында шул Ыйыҡ тауы да ҡотҡарып ҡалған.

Танып буйында ниндәй генә жимешләр йуҡ. Унда Щийә тауы бар, шунда щийәлек урыны бар. Күгән бар, ваҡ ҡына күк төсле, торндың ҡырғый варийанты. Гөлжимешләр, шоморттар, миләш үсә. Имән щитләүекләре жыйабыз. Малина – ҡурай жиләге, землянканы жир жиләге дип әйтәбез, ҡайын жиләге бар тағын, ансы бәләкәйерәге, баҡщада үскәнен викторийа дип сөйләшәбез.

Без үзебез пешерәбез ҡыстыбый: бәрәнге ҡыстыбыйы, тары ҡыстыбыйы. Анан соң бәлеш, беззең йаҡларда дөгө йармасы белән ҡабаҡтан бәлеш пешерәбез. Аны Борай бәлеше дә дип йөретәләр халыҡ телендә. Шул ҡабаҡ бәлешен тары йармасы белән дә пешерәбез. Тәйикмәк бешерәбез, ул табада пешерелә торған йоҡа ғына ризыҡ. Без аны ащы ҡамыр белән эшләйбез. Русща блины инде. Тары белән дә пешерә торғайныҡ. Тары йармасын башта без бүрттерәбез, кищтән бүттерергә ҡуйабыз сөт беләнме анда, жылы сыу беләнме. Шул бүрткән йарманы икенще көн он белән, йоморҡа белән ҡабартабыз, сып-сыйыҡ ҡына була ул. Ҡоймаҡ салған кебек табаға салып, мищтә пешерәбез. Хәзерге вахытта йә духовкада, йә өстендә пешерәбез. Ҡоймаҡ кебек ҡойоп, общий зур була һәм духовкаға тығып ҡуйабыз.

Хәзерге заманда төрмә пешерәбез. Төще ҡамырға бәрәнгедән, суғаннан төреп, эщенә йармалар салып, иттәр салып та пешерәбез, начинкаларын төрлещә эшләйбез инде, эщлекләрен. Төреп, ул йарым түгәрәк

формасында була. Щиттәрен бүлеп, духовкада пешерәбез. Төрмә дип атайбыз без аны. Вак бәлеш пешерәбез, ит белән дә, йарма, йөзөм, кабак белән дә, салабыз шунда, бик тәмле була. Рис, кабак, курәгә, йөзөм жимешләре салып пешерәбез. Был щөще камырдан.

Сәк-сәк, бауырсак та пешерәбез. Аны тош, май ашы ла дип атайбыз. Бездә артык эре пешермәйләр. Тирәйакта зур итеп тә пешеләләр, озон итеп тә, бездә биш тин акща зурлығында пешерәләр. Майға катырып, йоморткадан, йакшы ондан, щак кына шунда щәй содасы салып әзерләйбез, әз генә, баллап, майлап катырып куйабыз.

Монауында ғына безнең, әле шишмәсен матурлап ауылға чығарып ҡуйҙыҡ, Ҡара тәкә чоҡыро бар. Моның инде бер ничә версиясы бар, легендасы. Берсендә инде, имеш, шушы ауылның байының ҡорбанға дип үстергән зур тәкәсе була, бу шушы чишмә чыҡҡан жир сазлыҡҡа төшеп бата да инде, моны тартып алалмай: “Ҡара тәкәм, ҡара тәкәм!” – дип, имеш, инде бай жылап утыра инде. Шунан ҡалған дигән версия бар. Тағын бер версиясы егерменче ғасырның башы, революция чоры белән бәйле. Безнең Ҡырғызның бер ничә типтәр ғайләсе айырылып чығып, егерме сигезенче йылны Уяндыҡ ауылына нигез салалар. Сафинның, Алсуның әтәсенең ауылы Уяндыҡ ауылы, ике генә километр моннан. Буларның жире булмай. Шуннан инде бер йылны жирсез генә чығалар. Егерме туғыҙынчы йылны хөкүмәт буларға жир бүлеп бирә. Беренче артель, беренче коммуна төзейләр, беренче колхоз инде. Жир Андреевкаларныҡы була. Урыс ауылы, урыс-татар ауылы анда. Шуларныҡы була. Тегеләре инде, жирне бирмәйбез дип, монда киләләр. Ике ауылның ирләре өйелеп суғышалар инде, безнекеләр атлар белән баралар, суғышып, жиңеп ҡайталар андреевкаларны. Жиңеп ҡайтҡачтан инде, ҡара тәкә чалып, бәйрәм ойыштыралар шул чоҡыр буйында. Мынсы икенче вариант.

Өченчесе. Мынсы мин үзем шушындый атамаларны чағыштырып ҡарап килеп чыҡҡан версия. Ауыл ойошҡан уаҡытта, Нуғайауылын ойыштырғанда бөтен нәрсәне ҡарағаннар инде, ағачын, урманын, сыуын. Иң төп әйбер эчәр сыу булған. Бөтен ауылларның беренче төп нейе – эчәр сыу аның. Шушы менә язылған документларда Ҡара чишмә ... дип. Ҡара тәкә скорее всего шуның исеме булғандыр инде ул. Чишмә ҡорымасын, сыуы бетмәсен, дип инде чишмәләргә арнап ҡорбан чалған булырға тийешләр. Чишмәләр ныҡ изге чутланғаннар, изге урын чутланғаннар, чишмәләргә бағышлап ҡорбан чалып, именно ҡара тәкә чалып,

Минем версия инде, шунан ҡалғандыр исем. Теге версияларны да инҡар итмәйем мин, чөнки Бишҡура, Бишҡурай дигән ауыл бар. Бишҡураз. Бишҡураз дип йөрткән ул. Ҡырғыз ауылыннан чыҡҡан. Безнең шәжәрәләр бер ул ауыл белән. Ул елдәк ырыуына ҡарай менә ни өчендер. Ул тоже өйрәнелмәгән әле до конца. Ҡураз – китапларда язылған ул, фарсы телендә – әтәч. Биш әтәчне чалып, исеме шунан китмәде микән, чөнки Үгез дигән ауыл бар. Атсуяр дигән ауыл бар. Шишмәләргә арнап ҡорбан чалғаннар дигән версия бар инде.

Нинди күлләр бар әле безнең? Озонкүл, Чатлыкүл. Иске Идел дигән жир бар. Ағидел йылғасы үзенең ағымын чаҡ ҡына үзгәртә дә, бүленеп ҡалған жир.

Тоба дигән жир бар. Тоба – залив булып ҡалған жир. Ағымсыз, менә Ағидел йылғасы аға, Ағидел йылғасы борылған жирдә, Илеш элеваторы буйында борылып китә, шул борылған жирендә сыу залив булып эчкә кереп тора. Шундый жирләр тоба дип атала бездә, безнең яҡта.

Идел теяғында Ҡуышҡала дигән бер урын бар. Бер ничә версиясы бар. Имеш, нииндидер халыҡ йәшәгән монда ҡачандыр. Ҡуышлар ҡорып торғаннар, яз көне ул төшләрне сыу баса, шул бер жир генә ҡала. Безнеӊ элек колхозның малларын чығаралар ийе, таналарны шул яҡҡа, паром белән чығаралар. Бөтен тирә-яҡны сыу баса, шул Ҡарт тарлау ҡала да... Хатта сыу нығ күп килгән йылны сыйырларның тубығына хәтле сыу менәдер ийе анда, сыйырлар сыуда басып торадыр ийе бер ничә көн. Шул Ҡуышҡала дигән жир, имеш, теге халыҡ ҡуышларын ҡалдырып киткән. Икенче версиясы: сыу баса бөтен тирә-яҡны, ә тегендә ҡорылған ҡуыш ҡына ҡала инде утрау булып. Анда кереү бик ауыр, Ҡырғыз ауылы шул төштә булмады микән дигән дә фикер бар. Аның туфрағы ҙа ҡара балчыҡ, ҡара туфраҡ.

Уяндыҡ яғында Мәнәүез күле бар. Исеменең чығышын точно белеүче юҡ. Мәнәүез дигән исем нығ күп ул, күп. Күп жирдә бар ул. Башҡорт телендә уҡыған бар минем, м хәрефе белән б хәрефе чиратлаша. Белеуз дигән ҡыпчаҡ нейе булған. Ҡыпчаҡ ҡәбиләсе бит инде айырым төркемләрдән торған, берсе – белеуз. Белеуз – мелеуз, менә шундый бер кыпчакская орда булған.

Уртатау – Ҡара тәкә ҡырындағы ике тау уртасындағы тау.

Ҡарабай чоҡыры бар. Исеме билгеле түгел, имеш, Ҡарабай дигән эт үлгән дә диләр.

Пәрей чоҡыры бар. Түбәночта татар типтәрләре йәшәгән, түбәночнон азағындағы чоҡыр Пәрей чоҡыры дип атала. Ә юғарочта марый типтәрләре йәшәгән, аныҡы Кирәмәт чоҡыры дип атала. Кирәмәт дип аларҙа, марыйларҙа, алама жирне кирәмәт дигәннәр, без пәрей дибез бит инде. Сыуның үзенең кирәмәте булган, урманның үзенең кирәмәте булган, божестволары булган бит инде аларның.

Әүлиә зияраты дигән урын бар, урыны билгеле түгел, элекке иске ферма урыны дип кенә йөртәбез. Монауында Бийектау астында зияратлыҡ бар. Аның яры ишелеп, сөйәкләр дә чығыштыра. Аны күмештерәбез барып. Элек билгеле, дин таратучы, уҡымышлы, зыялы кешеләрнең нийен генә әүлиә зияраты дигәннәр бит инде. Аның өстенә таш ҡуйғаннар. Мин сораштырам бит инде, ауылларда йөрештерәм. Бөтен иске зиратҡа хәзерге халыҡ шундый исем бирә. Шундый кеше жирләнмәсә дә, иске зиятратны әүлиә зияраты дийеп исем ҡушалар.

Монауындағы басу Түбә басыуы дип йөртелә. Чаҡ ҡына ҡалҡуыраҡ булып тора ул. Мин боронғы карталарны ҡарадым, сигез йөз дә беренче йылғы карта. Ҡырғыз ауылының жирләре әле сөренте жирләре бик күп булмаған ул. Шушы басыу сөрөлгән булған. Ун сигеҙенче ғасыр башына ужы жирләр бүленгән булган ауыллар арасында. Ун жиденче ғасырда ҡырғыз ырыуы кешеләре теләсә ҡайсы ауылға күчеп ултыра алған. Ырыу жире. Ә ун сигеҙенче ғасырда ужы икенче ауылға күчәлмәгән, чөнки жирләр разграничивать ителгән булған. Әлеге сельсовет жирләре шулар белән туры килә. Яҡынча туры килә.

Ана шул сөйләгәннәрдән генә беләләр, бер өлеше, без татар, дип йөрей, бер өлеше, без – башҡорт, дип йөрей. Мин үзем дә ҡаршы, ҡырғызларға безнең нииндий отношение булырға тейеш, тем более Енисей ҡырғызларына... Бу вопросны өйрәнергә кирәк әле. Менә шундый төрле, өч-дүрт төрле халыҡтан басҡан халыҡ инде без шулай. Кәм дигәндә, без белгәне әле. Менә Өлфәт абыйлар генетик экспертиза эшләделәр, анализ бирделәр. I один – скандинавский, N один, C один – финно-угорский, и бер өлөшөндә I 2 маркерлары, кодлары.

(Хөснөтдинова Рәмилә Янсаф ҡыҙы менән Хөснөтдинова Илүзә Илһам ҡыҙы яҙып алды).

## ИҪӘНБАЙ АУЫЛЫ

### Бәҙретдинов Раһип Мәрүәретдин улы, 1945 йылғы

Әбиләр сөйләүе буйынча, ауылны әйләндереп алыр урманнар былған, Минеште йылғасы буйындағы жирне ачып, экреннәп-экреннәп ағачларны кисеп, жирләрне басыуларға әйләндереп, ашлыҡ чәчеп, игенчелек белән шөғөлләнеп киткәннәр. Сәүдәгәрлек белән шөғөлләнгәннәр. Зимагурлар былған (йоморҡасын, сөтөн алып китеп сатып ҡайтҡан кеше). Ҡазанға сатырға йөрөгәннәр, артабан аннан алған әйберләрне (кийем-салым, азыҡ-түлек) алып ҡайтҡаннар. Умартачылыҡ белән дә шөғөлләнгәннәр. Колхозлашыу чоронда күмәк хужалыҡ былған, бер ауыл үзе бер колхоз былған. Әлеге уаҡытта ауылда мәчет, мәктәп, магазин бар. Дини бәйрәмнәр (Ураза бәйрәме, Ҡорбан бәйрәм) үткәрелә. Әлеге уаҡытта ауылда йәшләр күпчелек малчылыҡ, игенчелек белән шөғөлләнә, Себердә хәм күрше ауылдағы колхозда эшләйләр.

Әтием, Марвартдинға, заказ бирәләр иде: йаңа суйылған сарыҡның тиресен китерәләр иде дә, шушыны йомшартып иләп бирергә ҡушалар иде, тун, толоп тегәргә. Кипкән тирене эткәй жәйеп куйа иде дә ойдәге идәнгә, жылымса су белән тирене жебетеп төрөп ҡуйа иде. Тирене төрөп, шаҡмаҡлап бастырып ҡуйа да ике сутка тора шушы көйө. Шушы тире бер-бересенә йәбешеп ийей башлай эчке йағы. Шушыны жәйеп ҡуйып әзме-күпме киптерә дә тартҡы белән тарта торған иде. Бер ничә тапҡыр ҡабатлай. Әйләндерә-әйләндерә тартҡылай да аннан тағы киптерә, аннан тағы ийәй, биш-алты тапҡыр шушылай эшкәртә иде. Аннан шушы тиренең бер ҡаты ҡубып төшә иде. Аннан шул тирене тегеүчегә бирәләр иде. Аҡ хәм сары тун тегәләр иде. Сары тун эшләр өчен тал ҡайырысын киптереп ҡайнатып, шул ҡайнатылған су сары төскә әйләнә торған иде. Шул тирене иләп бетергәннән соң, тирене жәйеп, быйай торған иде шул ҡайнатылған сары төстәге су белән. Шул тал ҡайырысының сыуы сеңеп сары төскә керә. Киптергәннән соң, тағын иләп алғачтан, тире сары төскә керә. Чабата бәйләй торған идек. Йүкә ҡайырысынан. Ыштыр белән урағаннар, балтырға чаҡлы чабатаның киндерәсе белән урап бабайлар шулай итеп йөриләр иде.

### Рәжәпова Зөләйха Лотфулла ҡыҙы, 1951 йылғы

Исәнбай ауылы территорийасына, Миңеште йылғасы буйына Исәнбай дигән кеше хатыны хәм балалары белән килеп утыра. 1726 йылда Исәнбай ҡартның исеме беренче тапҡыр йазыуда күренгән була, шул уаҡыттан бирле Исәнбай ауылы йәшәй. Ауылда алты йөз кеше, бер йөз жигерме сигез тирәсе өй,өч урам.

Ишетеү буйынча, Миңгеште дигән ҡарт булған, килә-килә Минештегә әйләнеп ҡалған, шушы йылға буйында бер чишмә ачҡан була бу ҡарт хәм шушы чишмәнең сыуын халыҡҡа эчермәгән, бу ҡартны ауылдан ҡыуғаннар. Дүртийле районында Минеште ауылы бар, бу ҡарт шунда барып утырған хәм шушы ауылға нигез салған. Әтнәкул йылғасы бар. Уйынтыҡ жирләре ҡул кебек былғанға күрә шундый исем йөрөтә. Чағыл тауы бар, Иштау бар. Урам бәйрәмнәре үткәрелә.

Без Ҡырғыз ырыуына ҡарыйбыз, ҡырғыз башҡортлары дип йөртәләр безне. Безнең телдә элек ҙ белән сүләшеү былған. Шуннан сың, бармайбыз, ҡайтмайбыз, ҡайтайыҡ, сүләшәйек, менә бу башҡортларның – әйекләре બездә бар.

(Саньярова Рәмилә Рәмил ҡыҙы яҙып алды).

## ИШҠАР АУЫЛЫ

### Фәрхетдинова Дүлә Тәкиулла ҡыҙы, 1937 йылғы

Исемем мылтыкның бер өлөшөн аңлата – дула. Больницага бардым да йатарга, минем исемемне белгәч, врач төне буйы энциклопедийа актардым, апа, ди. Исемеңне белергә ди, шунан соң син – мылтыкның бер өлөшө икән диде. Жиңел әйтелә торган исем диләр инде. Сиксән өч йәшем тулды. Шушы ауылда туып, шушында йәшәдем, бер кайда ла бармаҙым. Нәк шул урамда әз генә өскәрәк күчтем инде. Мин сигез йел правлениеда бухалтерийада эшләдем дә пенсийага чыкканчы, туксан икенче йылда пенсийага чыктым, мәктәптә лаборант булып эшләдем. Ишҡар мәктәбендә.

Илле алты йыл иптәшем белән йәшәҙем, иптәшемдә шушы ауылныкы ийе, ул үлгәнгә дүрт йыл булды, ике бала Уфада, малайым да, ҡызым да. Ҡайтып, хәл белеп, йардәмләшеп китәләр инде. Бер үзем йәшәймен.

(Саньярова Рәмилә Рәмил ҡыҙы яҙып алды).

### Фәтхетдинова Клара Мөхәмәҙи ҡыҙы, 1947 йылғы

Ишҡар аулы артыҡ ҡарт ауыл түгел, Дүртиле районында Ағидел йылғасы буйында Балтач дигән бер ауыл бар, шул аулдан күчеп килгәннәр мында. Бурлаклар вахытында Балтач аулы халҡын шушы бурлаклар талаганнар, күп жирләрне йаз көне су басҡан, шуның өчен шушында күчкәннәр. Беренче Ишҡара дигән ҡарт килгән, алар шушы аулның төп урынында түгел, ә Сарйаз йылғасының арйағындағы тауда, тигез жиргә килгәннәр, хәзер ул жир Иске йорт дип атала. Бренчедән, анда эчәргә су бик жайсыз былған, икенчедән, Екатерина ике әби-патша үткән йулның бер кисәге шушы Ишҡар аулында, бу йул Сөргөн йулы дип аталған, Екатерина ике йул салдыра шушында, эш былғанға күрә кешеләр шушында күчеп утырғаннар.

Ишҡар аулыннан бер ун километр йыраҡлыҡта Сарйаз дигән рус аулы былған, шуннан башланып килгәнгә аңа Сарйаз дип исем ҡушҡаннар.

Ишҡардан Уфаға барған йулның уң йағын башҡорт, сул йағын типтәрләр йағы дип йөрөткәннәр. Типтәрләр, скорее всего, Татарстаннан йул салырға китерелгән кешеләрдер. Типтәр: 1) тибелеп йөрөгән кешеләр, аларның жирләре дә былмаған, 2) дәфтәр сүзенән, аларны кайдадыр йазып ҡуйғаннар, ләкин ул ваҡытта дәфтәр сүзе булған микән?

Ишҡар аулында радиоузел былған, анда татарча да, русча да, башҡортча да сүләшәләр, шуның өчөн без башҡорт телен аңнай идек, теге йәки бу әдәби әсәрне уҡып, шул уҡ вахытта татарча уҡый ала идек.

Миңса (Миңниса) ҡыуағы. Ул ҡыз коллективизацийа очоронда комсомолка былған, кулакларга ҡаршы чығыш йасаған, Манчар аулыныҡы, бу аулға туғаннарына килгән былған, ҡайтып киткән чаҡта кулаклар шул ҡуаҡлыкта үтергәннәр. Ҡәбере әле дә бар.

Мөси ҡулы. Мөсифулла исемне ҡарт, Ишҡар аулы кешесе, зур йәштә былған, ҡыш көнө мунча чыҡҡачтан ак киндер кийемнәр кийеп, алмашынып китеп микән, аулдан чығып китеп, икенче көннө генә тапҡаннар, ҡанны айаҡ эзләренән барып эзләп таптыҡ, диделәр. Баштағы исеме Мөси күле (элек ул жирдә күл былған), бара-бара Мөси ҡулына әйләнде.

Ҡайын сираҡ (Ҡанлы сираҡ (айаҡ)). Артҡы урманның исеме, шушы аулда миңә сөйләгән әбинең абзыйсы ҡайдадыр мәдрәсәдә укып ҡайтҡан, хатын алып ҡайтҡан, ул мөселман былған, аҡлар белән суғышҡан уаҡытта, аҡлар быларға килгәннәр, күрәсең, бу кешенең агитацийасыннан ҡурҡып, бер сондыҡ китабы былған, шушы сондыҡны чығарып йандырдылар, ди, абзыйны хатыны белән алып киттеләр, ди. Абзыйны бер атнадан соң тураҡланған көйө шул урманнан тапҡаннар. Шуңа күрә аңа Ҡанлы сираҡ дип исем биргәннәр.

Йалғыз ҡәбер. Тегермән артында йалғыз ҡәбер барыйы, ул ҡәбер менә шул Татарийа йағыннан килгән хәйер сорап йөрүчеләрдән берәү үлгән, аны шунда күмгәннәр. Йаңғыр былмағанда, әбиләр шул ҡәбергә су сибергә йөрөйләр иде. Хәзер бу ҡәбер беткәндер инде. Бик озаҡ йаңгыр былмаса, жәй көнө ҡәберләргә су сибергә баралар әбиләр. Бу электән килгән ғәдәт ийе бу.

Урыс базы. Урман эчендә карйер бар, анда әйбәт ҡом, тирә-йаҡта андый ҡомно жир йуҡтыр, шушы йул салырға килгәннән соң гравий кирәк бит, шунан алғаннар. Ә йул төзүчеләр бит мастерлары, прараблары руслар. Шулар ҡазытҡан бит инде аны. Шуңа күрә хәзер ул Урыс базы дип йөрөтөлә.

Ҡара тал басыуы. Йылға буйында күп итеп ҡара таллар үскән, шул урман эчендә ҡара ҡайыннар бар иде.

Мама – әни, инәкәй; папа – әткәй, бабушка, дедушка – ҡартый, ҡартәтәй (әткәй йағынан); йыраҡай, ҡартәтәй (әни йағынан); зуринәй, дәү әни, дәү әти. Күршеләргә аҡ әби, аҡ бабай, чибәр әби, чибәр бабай, йаҡын әби, йаҡын бабай (кем ничек өйрәтә). Әтинең абзыйсы – дүрәтәй, аның хатыны – дүрнәй. Әтинең энесе – төпчөк абзый, төпчөк апа.

(Саньярова Рәмилә Рәмил ҡыҙы яҙып алды).

## ИШТИРӘК АУЫЛЫ

### Мөбәшәрова Инсия Сәлимгәрәй ҡыҙы, 1950 йылғы

Мин Илеш районы Иштирәк ауылында тыудым, шунда үстем, шунда йәшәймен мең туғыз йөз илленче йылның майында тыуганмын. Сигез класны бөтергәннән соң фермаға эшкә бардым, фермада сыйыр сауыущы булып эшләдем, шуннан кищке мәктәптә унны бөттем, аннан алтмыш туғызынщы йылны тормошҡа щыктым шул ауыл йегетенә, шунан соң шул эшемне дәүәм иттем, аннан мәктәпкә эшкә кердем, аш пешереүше булып, анда сигез йыл эшләп щыктым да, аннан соң йаңадан колхозға ҡайттым, амбарда мөдир булып, шунан пенсийага щыктым, щиргә сабыштым бит инде.

Безнең ауыл бик матур. Бер Иштирәк дигән бабай булған. Шул шушында килеп, жир эшкәртеп, шуға Иштирәк дигән исем атағаннар инде безнең ауылға. Дүрт йөз йыл инде хәзер. Шуннан безнең ауыл бит инде игенщелек белән, малсылык белән шөғелләнә. Элек суғышҡа ҡәдәр ике колхозны берләштергән безнең ауылыбыз, шуны Көрпә йылғасы бүлеп торған. Бер йағын башҡортлар, бер йағын типтәрләр бүлгәннәр ауылыбызны. Көрпә йылғасы уртанан үтә инде. Шуннарын бит инде суғышҡа ҡәдәр безнең ауылда көл заводы булған, көл житештергәннәр инде анда, берсе Әндрей колхозы, берсе Йупитер, шуннан инде шушы суғышлардан соң, өщ ауылды берләштереп йаңадан бит инде Киров колхозы дип ҡалды бит инде, әле дә шул колхозларыбыз бара бит инде, малсылыҡ, басыущылык әле дә дауам итә, аллаға шөкер.

Салҡын шишмә дигән шишмә бар безнең ауылдан йыраҡ, аның суы бик салҡын иде, әле дә бар, бына безнең көтөүләр йырағыраҡ чыга бит инде, жәйге лагерь дибез бит инде, жәйләү шул тирәдә генә ул, ауылға өщ щакрым, шулай булгащ ауыл халҡы ул шишмәдән файдалана алмады. Ә башҡа таулар, Тарлау тауы дибез инде, анда иген үстерәбез, шуннан Ташлы дигән тау бар, анда тагын иген үстерәбез, безнең бит инде менә шушы Иштирәк ауылы урманды карчавать итеп жирләр ойошторған.

Бабушканы ҡартый, йыраҡ әбей диләр. Инәй йағынан йыраҡ әбей диләр бит инде, ә ир йағыныҡын ҡартый диләр, ҡартый, ҡартәтәй, ә тегесе инде йыраҡ бабай, йыраҡ әбей була әңкә йағыныҡы. Папа, мама әткәй, әңкәй була. Ә менә без бит инде, например, *без* дип сөйләшәбез бит инде, ә безнең менә телдең көтөклөгө микән, без менә *бодай* дибез, бодау дибез, *з* дип сөйләшмәйбез, безнең *кыдыл бодау* дип сөйләшәбез. Көтөк йетешсезлек инде ул. Сестренка сеңлекәш, энем малай кешегә. Киленнәр ҡәйнеш, балдыз диләр. Апа дип өндәшәләр, менә хәзер былай да әби дийеү йуҡ инде, апа, абый дибез.

Ҡайын, шыршы, имән, усаҡ бар. Шыршы, ҡарағайлар бездә үсә. Миләш тә бар урманда, жиләк тә бар бит инде. Ҡара бөрлөгән дә бар безнең йаҡта. Ҡара бөрлөгән дә бар, ҡамырлыҡ та бар. Боярышник – ҡамырлыҡ, гөлжимеш – шиповник, малина – ҡура жиләге, земляника – урман жиләге, ҡайын жиләге; черемуха – шоморт, лягушка – баҡа, божья коровка – тәтәй тауыҡ, угол – бощмаҡ, хлеб – эпий, ведро – биҙрә, воробей – турғай, шерстяные носки – ойоҡ баш, шапка-ушанка – бүрек, слякоть – ләпек, боҙ өҫтөнә яҙ көнө ҡалҡып сыҡҡан һыу – шәр, остров – утрау, сарай – лапас, сад – ындыр, чашка – йомро дибез, асты бәлүдә; ложка – бал ҡашығы, аш ҡашығы, шунан половникты ужау дибез.

(Бәхтийәрова Әлфирә Нурислам ҡыҙы яҙып алды).

## ЙӨННӨ АУЫЛЫ

### Музипова Әлфинә Ғәзизйән ҡыҙы, 1972 йылғы

Без йылан ырыуына керәбез.

Базы йылғасының бер урыныннан халыҡ төзөлөштә ҡулланыр өщөн ҡызыл балщыҡ алган. Бу жир “Ҡызыл йар” атамасын алган. Шунан Ҡыйыш тау басыуы, Пистолет басыуы бар. Бур тауы дигәннән, безнең Бур тауынан шул бур (аҡбур) щығарып, шуны йандырып, сатып элегерәк аҡща эшләгәндәр.

Жир бүлгәндә Йонно ауылы кешеләре Рсай ауылы кешеләре белән жир бүлеп суғышҡаннар икән. Йонно ауылы йауыз атамасы Зәйнетдинов Мөхәммәтдин исемле кеше, ә Рсай ауылынан Әхмәтдин исемле кеше бермә-бер көрәшкә щыҡҡандар. Жиңеүще йағына жир ҡалдырылырға тейеш була. Көрәштә Йонно атаманы Әхмәтдинде туҡмап үлтергән һәм халыҡ та бер-берсе белән суғыша башлаған. Йонно халҡы Рсайларны ауылларына хәтлем ҡыуып алып барған. Ололар бу урынны “Суғыш щоҡоро” дип атағаннар. Тағы ла Хөрмәт щийәлеге, Сәлли посадкасы, Левен (Людвик) тегермәне, Аркашка ҡарт тегермәне дигән атамалар бар ийе.

(Йомағужин Айҙар Ғариф улы яҙып алды).

**Ғабдулхаҡова Ғәлиә Ғәзизйән ҡыҙы, 1958 йылғы**

Йаңғыр йаумағанда "Әүлиә ҡәбере"нә барып, шунда ҡырҡ бер бидрә су сибеп, мулла укып тороп, шулайтып теләк теләйбез инде. Ул безнең ауыл уртасында, әнкәйләр йәшәгән йерләрендә бер тыҡрыҡта, безгә күрсәтеп ҡалдырдылар инде. Уның әз генә бер ҡалҡыулығы бар, безнең эткәй урыны онотолмасын дип ағащ ултыртып ҡуйған инде.

Бездә ҡайын күп, имән, нарат, шыршы үсә. Сосна – нарат, смородина – ҡарағат, малина – ҡура жиләге, муйыл – шоморт, боярышник – ҡамырлыҡ. Паук – үрмәкещ, червяк – селәү, божья коровка – тәтәй ҡош, муха – щебен, оса – сағызаҡ. Тарелка – тәрлинкә, половник – ужау, кастрюля – мис, чашка – шәшке, блюдце – бәлүдә, ковшик – щүмещ. Ит, картуф белән бәлеш, тош, ул сәк-сәк була, тәйикмәк, ҡоймаҡ, гөбәдиә, бәрәнге төрмәсе эшләйбез. Бабушка со стороны отца – ҡартый, бабушка со стороны матери – нәнәй, дедушка – ҡартәтәй, мама – әнкәй, папа – эткәй, сестра – апа, брат – абый, братишка – энекәщ, сестренка – сеңлекәщ, брат родителей – дүрәтәй, сестра родителей – дүрнәй, свекровь – быйанай, свекор – быйатай.

(Йомағужин Айҙар Ғариф улы яҙып алды).

## ҠАРАБАШ АУЫЛЫ

**Сәлимгәрәева Рәзифә Мөхәммәтзаһит ҡыҙы, 1954 йылғы**

Без йылан ырыуы. Тамға чүмечкә ошаған. Мин тормошҡа сыҡтым да, без бу йаҡта йәшәмәдек, Ташкентта йәшәп ҡайттым. Ташкентский государственный институт дошкольного воспитания укып чыҡтым. Дошкольный тәрбиәсе һәм психолог булып чыҡтым. Жигерме биш йыл балалар баҡчасында эшләдем. Мында ҡайтҡас, ауылда ике мең беренче йылны ҡайттыҡ, унда балалар баҡчасында эш булмады, социаль хезмәткәр эше килеп чыҡты да, мин ун йыл социаль хезмәткәр булып эшләп, пенсийаға чыҡтым. Әбейләр ҡарадым ике ауылда безнең, Ҡарабаш һәм Йаңа Күктау тигән ауылларға йөрөп эшләдем. Ун ике әбей, бабай булды. Барлыҡ үзем ҡараған әбейләремде быйыл сунғы йулға озатып бөтөрдөм, тәрбиәләп. Хәзер мин ҡараған бөтөн әбейләрем дә теге донйаға күсеп киттеләр.

Балаларыбыз бар. Бер улым бар, ләкин ул ҡайтмады, ул ҡалды шунда. Ике улы бар, йәшәп йаталар килен белән, бу йаҡҡа ҡайтмады.

Безнең риүәйәтләргә ҡарағанда, бик күп йыллар элек Ҡарабаш тигән бер ҡарт үзенең ғайләсе белән урманны, ике йаҡтан су аҡкан күлле безнең йаҡҡа килеп чыҡҡан. Уң йаҡлап, сул йаҡлап йылға аҡкан, бер йаҡтан Иштирәк тигән йылға аға. Астараҡ күл булған, шул йылға аша урманнарны кисеп, күлне уртаға йарып, йылға ағызып жибәреп, шунан басма салып, корчовать итеп, балалары, уллары белән, шунан өй салып, анан инде шул Йамаҡтауҙа ла шундай бер ғайлә барып утырған булған. Шунан йомошҡа килгәнен күреп, унда кешеләр бар икән, әҙәмнәр бар икән тип, улар килеп очрачып, күбәйеп, улларын-ҡызларын бирешеп күбәйеп киткәннәр. Безнең ауыл бик зур, зур жиде урам, өйләре бик матур, әле йаңыдан-йаңы сигезенче урам төзөләп килә. Былтыр ғына мәдәнийәт многофункциональный тиләр, күп ҡырлы төзөдөләр, анда балалар баҡчасы, библиотека, спортивный комплекс төзөдөләр бик матур итеп, шуның ҡырынан ике урам төзөләп килә хәзер матур. Безнең ауылда йәшләр бик китмәй, үзләре йорт салалар, ауыл зур, йәшийләр. Фельдер-акушерлыҡ нийе бар, эшләп килә, мәктәп ике ҡатлы бик матур эшләп килә, фермалар эшләй. Басударда иген чәчелә, жыйыла, быйыл уңыш бик зур булды. Халыҡ бик бай йәший хәзер, татыу. Мәчетебез бик әйбәт эшләп килә, мәдрәсә эшләп килә. Мәдрәсәдә өч йыл ун жиде кеше укыйдыр ийе, беренче йылны жиде кеше, икенче йылны ун кеше килгән ийеләр.

Килен әнийем, этийем, әнкәй, эткәй, ә кейәү әбей, бабай тийә. Кем ничек үрәнә. Улы ничек әйтә, килен дә шулай әйтә. Мин биатай белән бианайға ла эткәй, әнкәй тийеп әйттем. Биатай ҡайнатай була, бездә бианай ҡайнана була.

Безнең урманда күп хайуаннар. Пошой бар, ҡабан дунғызлары бик күп, рысь бар – урман мәчесе, төлкө бик күп. Төлкөдөң хәзер урман төлкөсө лә бар. Урман төлкөсө бит ул озон ҡойроҡло, сүрәлеп йөрөй торған, ә бар ҡорсаҡ. Ул бүре төслө, озон айаҡлы, төлкөгә ошаған ҡорсаҡ төлкөләре. Анан безнең буаға өч йылдан бирле аҡкошлар төшә. Әлеге ваҡытта сигез аҡкош йөрөй. Дүртесе дә ҡоба төстә. Ҡыр үрдәкләре тула. Ҡоба коричневый була. И чөлән бар. Бездә табан балығы бар, анан ҡызыл ҡанатлы балыҡ, камбала.

Әле аҡ гөмбә жыйдылар, мына быйыл опята бик булмады ҡоро булғачтан. Төрлө грузди, этәч гөмбәсе – лисички. Өтәч кикрегенә ошаған, этәч гөмбәсе тиләр бездә. Халыҡ күп жыйа.

(Ҡотлоәхмәтова Эльнара Рафиҡ ҡыҙы яҙып алды).

## ЛАЯШТЫ АУЫЛЫ

**Зарипова Йәмилә Зәкәриә ҡыҙы, 1956 йылғы**

Мин Лайашты ауылында туғанмын. Жиде йәшем тулғач, Шуғайыштың башланғыч мәктәбенә уҡырға кердем, анда дүрт класты тамамладым. Мин шушы Ишҡарға сигез йыллыҡ мәктәп ине ул ваҡытта шунда

укырға килдем. Шушында укып тамамланғачтан житмеш беренче йылда Бәләбәй педагогийа училищесына укырға кердем. Шунан башлап мин житмеш бишенче йылда аны тамамлап ҡайтҡач, шушы туған ауылыма ҡайттым Лайаштыға, башланғыс класлар укытыусысы булып утыз алты йыл эшләдем. Хәзер лайыҡлы йалдамын. Соңғы йылдарда директор булып эшләдем. Хезмәтемне дәүләт нык йуғары баһалады: Рәсәй мәктәпләренең мәғәриф отличнигы исеме белән бүләкләндем. Шул зур ғорурлык булып тора. Шунан әлеге көнгә тиклем шушы туған ауылда. Мына беренче укыучым утыра ҡырымда. Хәзер инде ул клубта эшләй, без "Әхирәтләр" клубы үзебезнең ауылда, ул ойоштордо, без шунда бергәләшеп ауылыбыззы әзерәк йәмләргә тырышып, матурларға тырышып, бәйрәмнәр үткәрергә тырышып шулай йатабыз инде, ауылды сундермәскә тырышып.

Безнең тарихи мәғлүмәтләргә ҡарағанда, өлкән кешеләрдең сөйләүе буйынса, бер мең туғыз йөз сиксән дүртенче йылда уже искә алынған диләр инде. Екатерина икенче ваҡытында тимер бығауның сыңлаулары безнең ауылдар аша үткән дип шундай урыннар булған, арестантлары алып китә торған булған дигән сүзләр бар. Шушы ваҡытта электән үк риваятларға ҡарағанда Лайашты дигән бабай килеп урынлашҡан булған безнең ауылға. Безнең ауыл шунан башланғыч алған дигән мәғлүмәтләр бар. Без уйлайбыз, безнең ауылға Лайашты бабай нигез салған дигән уй белән йөрөйбөз, үзебез йәшәдек шулай. Ауыл бик зур ҡара урман уртасында утырған булған дип әйтәләр бит инде. Безнең ауылдын бер чаты бар, Пушинкә урамы дип атала. Шул Пушинкәдән өстәрәк Исәкәй дигән урын бар, мына шунда марыйлар йәшәгәннәр. Марыйлар безнең ауыл кешеләре белән дус йәшәгәннәр диләр инде. Марыйлар йанғын чыкҡан да күчеп киткәннәр ди инде. Ағидел арйағында ниндәйдер ауыллар бар икән шулар үзләре безнең туған йағыбыз Лайашты ауылы дип әйтәләр ди инде. Шунда барып эшләгән жигетләр ауылның исемен хәтерләрендә ҡалдырмағаннар нишләптер, мына минең шуны беләсе килә. Безнең Лайаштыны алар да үзләренең туған йағы дип йөрөтәләр икән инде. Шунан тағы бер Ташкисеү мәктәбендә директор булып эшләйдер ине ул Салауат Хәбрахманов дигән иптәш, без бер ваҡытта эшләдек тә. "Син беләсеңме, Венгрийада үтеп киткән чаҡта Лайашты дигән остановка ҡала, поезд белән үткән чағында?" – ди. Мин шуны эзләп ҡарадым интернетларда, шундай әйберне тапманым. Бәлки йуғарыраҡ йердән эзләсәң табып буладыр. Әллә теге Лайашты дигән әйбер шул безнең йаҡка ла килеп чыктымы икән дигән уй да тыуа. Әле эшләнеп бөтмәгән, уйҙырма ғына кебек булып торған әйберләр.

Безнең ауыл уртасынан ғына Шишмәбаш йылғасы аға. Без бәләкәй чаҡта аны Йылғабаш дип йөрөтәләр ине. Суы нык тәмле буладыр ийе, ҡыш көнө дә туңмайдыр ийе. Шунан килеп беҙдә буалар күп. Ороҡло буасы. Ороҡло дигән бабай үлеп ҡуйған булған шул йылғада, балалар шунда су керә торғандар ийе. Шишмәбаш башланған шунда тағын Теләк буасы дигән. Теләк дигән кеше йәшәгән, шул башлап буған була инде аны. Ферма буасы дальшераҡ китә түбәгә барған сайын. Анда ферма урынлашҡан ийе безнең, малларын суғаралар ийе, шундый урын бар ийе. Анан Тегермән буасы, анда 2 тегермән булған Гәрәй тегермәне, Максим тегермәне. Ҡараурман уртасында күл бар Табанай дип атала ул, буа дибез инде без аны. Без белгәне биш буа. Ҡуйан буасы дигән жир бар. Гәбекәй дигән урман бар безнең, шул урман ҡырында ғына Ҡуйан буасы бар, анда ла аҡкошлар килә.

Табан балығы бар. Без бәләкәй чаҡта гел ташты диләр ине. Аны мичтә ҡыздырып, ашата торғайнылар әнкәйләр, пирогын салалар ийе.

Ҡызыл эремчек, эремчекле майлар йасайбыз. Ҡызыл эремчекне эретәсен дә, писугын салып, майны эретеп, май йасап, шуны болғатсаң кәнфиттән дә тәмле әйбер килеп чыға.

Бәлүдә дибез блюдце. Бәлдә дип тә жибәрәбез ҡай чағында. Ҡашыҡ, ҡалаҡ, чәнчке, табаҡ. Аш табағы, ит табағы. Гөмбә дибез, күберәк мәшкә бездә. Әтәч мәшкәсе, гөрөждә, грузди дибез, опята.

Боярышник – ҡамырлыҡ, обувь бар бит инде, айаҡ сауты дип йөрөтәбез. Ауылдан сығып киткәстән генә айаҡ кейеме дип әйтә башладыҡ. Дедушка – ҡартәтәй, бабушка – ҡартый була.

Мөтләк – чабрец жыйабыз. Чәйгә салып эчәсең, нервыларны тынычландыра торған. Баш ауыртҡанда без аны салып эчәбез. Миллеккә лә ҡушабыз шушы бөтөн мәтрүшкәләрне, чабрец, эремнәр.

(Ҡотлоәхмәтова Эльнара Рафиҡ ҡыҙы яҙып алды).

**Ильясова Зөһрә Рәшит ҡыҙы, 1957 йылғы**

Мин Ашман тигән ауылныҡы, ғомер шушы Ишҡар ауылында үтте тисәң дә була инде. Лайашты мәктәпте тамамлағачтан, Йуматовоҙа укыдым бухалтерлыкҡа. Шунан суң, житмеш алтынчы йылда укып ҡайтканнан суң, шушы Ишҡарға эшкә килгән ийем, шунан Ишҡарда бер аз эшләгәннән суң, Лайаштыға кейәүгә сыктым сиксән икенче йылда. Өс бала үстердек.

Уйнаныҡ, скакалка бер туҡтаусыз, аннараҡ ҡуйан атыу буламы, үрдәк атыш. Айаҡлар чебешләнеп бөтәр ийе, ҡуллар чебешләнеп бөтәр ийе, ҡаранғы төчкәнче. Ат чанасында шуып төшәр ийек. Пыймаларны салып булмас ийе, ул ҡулларның әрнеүе кергәч, илап ултырадыр ийек.

Тәйикмәк, ҡыстыбый, бәлеш, бәрәнге төрмәсе бешерәбез. Мәтрүшкә жыйабыз, ҡарағат йапрағы, сарысын, көрәнен мәтрүшкәнең жыйабыз.

Малина – ҡурай жиләге, земляника – жир жиләге, черемуха – шоморт, угол – почмаҡ, божья коровка – тәтәйҡош, хлеб – әпи, дедушка, бабушка – эти йағынан ҡартый, ҡартәтәй; йыраҡ бабай, йыраҡ әбей инәй йағынан. Инәй бит инде ситтән килгән, йыраҡтан килгән, шуға йыраҡ әбей, йыраҡ бабай тип йөрөйбез без. Йаҡын бабай, чибәр бабай, аҡ бабай, бал бабай. Умарта тотҡач, бал бабай. Ҡаршыда ғына тора йаҡын әбей,

йаҡын бабай. Чибәр әбей, тәтәй әбей. Сеңлем, апайым. Малай булса да, ҡыз булса да минең апайым. Бәләкәйе апай беҙҙә, олосо апа.

(Ҡотлоәхмәтова Эльнара Рафиҡ ҡыҙы яҙып алды).

**Әсәҙуллина Зинфира Фәнил ҡыҙы, 1967 йылғы**

Лайашты аулында тыуғанмын. Жәмилә апай әйткәнчә, аның беренче уҡыучысы. Жәмилә апай педагогийа училищесын бөтөреп ҡайтҡач, беренче тапҡыр безне уҡырға алды. Шушы аулда сигез йыллыҡ мәктәпне бөтөрдем, анан Ишҡар мәктәбенә килдем. Шунан суң сиксән жиденче жылда мин БГУ-ның химфағына кергән ийем, эти чирләп китеү сәбәпле академический алдым, аны тамамлай алмадым. Шунан суң мин читтән тороп мәдәнийәт техникумын бөтөрдем Стәрлетамаҡта. Бөгөнге көндә шушы аулда мәҙәнийәт йортонда эшләйем.

Аул эргәсендә буа бар. Без бәләкәй чаҡта ла шушы буада кер чайҡайлар ийе. Ҡулны ла өшөтмәй торған суы дип әйтәләр ийе безнең аул суун. Минең дәүәней Бишҡурай дигән аулға кийәүгә киткән, анда су ҡаты, ә Лайашты суы белән сағыштырғанда анда ныҡ салҡын су. Лайаштыныҡында ҡыш көнө дә эчәк йуабыз бит инде мал суйсаҡ, перчаткасыз да, бер нийсез дә йуып була, йомшаҡ жылы суы.

Мына Жәмилә апа – минең беренче уҡытучым. Минең бәләкәй чаҡта ҡалған ин бәхетле мизгелләрнең берсе – ул безне мандолинада уйнарға өйрәтте. Аның үзендә генә мандолина бар ийе. Ул безгә һәр беребезгә сиратлап мандолина бирә, биреп жибәрә бит инде минәргә, мин иртәнгә хәтле Жәмилә апа өйрәткән “Ҡарабай”ны уйнап ултырам, ә иртән мәктәпкә китергә кирәк. Шулай иттереп, тырышып-тырмашып Жәмилә апаның мандолинасында уйнарға өйрәндек.

Чашка – чәшке, йоморо; половник – ужау, шерстяные носки – сарыҡ жөнөнән бәйләнгән ойоҡбаш; дедушка, бабушка – безне ҡартыҡай дип өйрәттеләр. Туған апа, тәтәй апа, төпчөк апа. Әтиләрнең, әниләр апаларына абзинәй (тетя), дәүәний, зуринәй (тетя), абзәтәй (дядя).

“Әхирәтләр” клубы ойошторолған бит инде безнең клубта, ике мең беренче йылдан бирле эшләй ул. Шушы әхирәтләр белән туй йолаларын да үзебезнең балалар өйләнешкәндә үзебезсә йәмләргә тырышабыз.

Безнең Баймаҡ, Илеш дуслығы инде ул. Сабантуйға Баймаҡ районынан киләләр. Без инде бер ничә йыл рәттән гел Баймаҡ ҡунаҡларын ҡаршылайбыз “Әхирәтләр” белән. Ансы ла бик матур йолаға әйләнде ул безнең. Улар үзләренең теләкләрен әйтеп, бүләкләрен бәйләп, ҡулғаға ҡалдырып китәләр.

(Ҡотлоәхмәтова Эльнара Рафиҡ ҡыҙы яҙып алды).

## РСАЙ АУЫЛЫ

**Йәмғәлиев Мәсғүт Шәйехзаман улы, 1944 йылғы**

Минең биографийам ул ҡәдәре зур түгел, балам. Мин йеде класс образование белән. Ул вахытта мында сигез класс та йуҡ ийе. Мин илле сигезенче йылны мәктәпне бөтөрдөм. Шунан колхозда эшләй башладым, анан тракторға уҡыным, тракторист булып эшләдем армийаға киткәнче. Армийада өч йыл да дүрт ай хезмәт иттем Германийада. Армийадан ҡайтҡачтан колхозда шофер булып эшләдем пенсийаға чыҡҡанчы. Ике мең дүртенче йылны пенсийаға чыҡтым. Тормош иптәшем тоже шушы ауылда эшләде главный бухалтер булып, мәрхүм хәзер, мәрхүм булғанына йыл йарым. Балалар биш бала, бишесе дә йуғары образование белән, хөкүмәткә хезмәт итәләр барсы да үзләренең уҡып чыҡҡан нейләре белән. Ҡайсысы уҡытучы, ҡайсысы нефтяник. Оныҡларның оныҡлары бар инде хәзер, двойной ҡартәтәй булдым. Шул минең тарихым. Әле булса бер үзем йәшәп йатам.

Әмир тигән ырыу безден. Мин туғыз быуынға ҡәдәре беләм ырыуларны. Безденң ауылда алты төрлө ырыу бар: Әмир, Йаҡуп, Ниғман, Үрмәт шундай нәселдәр бар. Беҙдә ырыу тимәйзәр инде, нәсел тип йөрөтәбез инде без.

Ырсай – ул кеше исеме булырға тийеш. Шунан безденң Ырсай Минзәлә йағынан килгән. Элек бит инде Минзәлә өйәзе безденң Башҡортостанға ҡараған, шунан Минзәлә йағынан килеп утырған халыҡ мында. Шунан халыҡ мында басучылыҡ белән, игенчелек белән шөғелләнгән инде, әле дә булса бик матур уңыш алалар. Әле дә булса шул игенчелек, малчылыҡ белән шөғөлләнә. Былай төп сығышы белән Ырсай Минзәлә өйәзенән килгән тийеп йөрөтелә.

Мин шушы йылғаға илле метр ғына торам. Вахытым йетәрлек, шунда төшөп ултырам. Вахытны да уздырырға кирәк. Йетеш хужалыҡ белән торам. Әллә ни эш йуҡ. Балыҡ та үзем ашар өчөн түгел, тауыҡларым бар минен. Шундай хәлдәр, ҡызым.

Тау чишмәбез аға инде матур ғына, төзөкләндерелгән. Рәхмәт ауыл советына, бик ҡарайлар ауылны. Ауылыбыз бик төзөк безденң районда. Район центрынан ҡала икенче урында безден Ырсай ауылы тора численность населенийа, численность дворов. Шунан урманнарыбыз йаҡын, тауларыбыз бар, мына күреп торасығыз, безденң географически бик матур жирдә урынлашҡан жиребез. Мынан да су аға, мынан да бик матур Базы тигән йылға аға, Ағиделгә ҡушыла. Мынан ҡырҡ километр китә. Ауылыбыз чиста, матур ауыллардан санала инде, Башҡортостаннын чиста ауыллар рәтенә лә керетелде инде ул. Ауылда эш бар инде эшләгән кешегә. Колхоз исемен йөрөтмәсә дә, әле былай халыҡҡа эшләр өчөн фермаларыбыз бар, техника колхозда житәрлек, ООО тип йөрөтөлә инде хәзер, Ибрагимов бик күп йыллар эшләй инде мында, житәкчелек итә.

Халыҡ мул йәшәй тип әйтер идем инде, эшләгән кеше. Хәзер бик эшләйем тип барған йәшләр дә йуҡ инде, но эш бар ауылда эшләгән кешегә.

Мал тоталар. Ауыл жирендә мал тотмасаң, йәме дә булмай бит инде ауыл ерендә йәшәгән. Жигерме биш-утыз соты жир иметь итеп, әйме, мал да тотмасан, аны нәрсә эшләтәсең? Мал тотабыз, ҡызым. Но мин хәзер үзем мал тотмайым, тауыҡларым бар. Бер үземә генә нәрсә генә кирәк инде. Балаларым читтә. Бер ҡызым бар инде мында, семйасы белән тора.

Хәзер, ҡызым, печән эшләү – ул бик жиңел. Аны техника чаба, белорус белән чабалар, белорус белән рулонға төрәләр, шунан ҡайтарып бирәләр. Йалҡау булмасаң, хәзер ныҡ жиңел. Бездең дәүергә ауырыраҡ чағы тура килде инде. Без суғыш очоро балалары. Без үскәндә аның техникасы да йуҡ ийе, тормош көткәндә лә ул ҡәдәре техника йуҡ ийе. Техника эшләй бит. Печән эшләнек вахытында, хәзер китереп бирәләр ауыл буйына, песән кирәкме, давай фәлән рулон китер тисән, хәзер сиңә йарты сәғәттән китереп житәләр.

Аттар хәзер бик сирәк тоталар. Бер вахытны колхозлар таралғачтан тотоп алдылар, өй рәтенән булмаса да, күп тоталар ийе. Тотоучылар бар. Бийәләр күберәк тоталар. Анын ҡолоно була. Колхозның ике йөз башҡа йаҡын аты бар. Атны бик күп тоталар, колхоз асырай. Техникасы да күп.

Без өйләнешкәндә, балам, ул ҡәдәр әлеге кебек роскошный вахыт түгел ийе. Ул вахытта халыҡ бер төрлө тийергә кирәк инде, байы ла йуҡ, хәйерсесе лә йуҡ ийе. Хәзер бит Совет власы таралғаннан соң ул айырылды, халыҡ икегә бүленде тип әйтсән дә була, байлар байларса үткәрә, роскошно иттереп, урта хәллеләр шулай итеп тоже итә инде. Үзебез өйләнешкәндә безгә комсомол туйлары үткәреп, дәүеренә килә ансы ла почет тигән кебек. Комсомол туйы үткәрделәр инде безгә. Йолалар, хәзерге йолалар ул күберәк ресторannарза үткәрәләр, но әле лә саҡланып килә: килен төшөреү, су йулына барыу. Элек калым тийеп итәләр бит инде, хәзер андай әйберләр йуҡ. Хәзер барлыҡ белән бит инде, магазиннарда барсы ла бар, балам. Хәзер эшләгән кешегә хөкүмәт аҡсасын биреп тора. Һәр замандың үзенең бер нийе була красотасы, матурлығы була. Бик матур итеп үткәрәләр әле лә. Ул йәшлек йәшлек инде, ҡайда ғына, нисек кенә әйттереп әйтсән дә.

Элек аулаҡ өйдәр күп ийе. Әйтәләр инде бер-берсенә: “Бөгөн фәлән кешедә, фәлән йортта аулаҡ өй икән. Аулаҡ өйгә барабызмы?”. Аулаҡ өйгә бара торғайныҡ, ҡызлар, жигетләр жыйыла торған идек. Йәшлек йәшлек инде ул. Сәхнәләрдә жырланым, үзем ғүмер буйы шофер булып эшләдем.

Шиповник – гөлжимеш, малина – ҡурай жиләге, балан – калина красная, божья коровка – тәтәйҡашыҡ, черемуха – шоморт, лопух – тигәнәк була. Гриб – гөмбә тиләр. Мында бит урман күп бит безден, ҡызым. Иптәшем исән булғанда йөреп, шунда пешерә торған ийе.

(Ҡотлоәхмәтова Эльнара Рафиҡ ҡызы яҙып алды).

### Камалов Әғләм Мөғәлим улы, 1943 йылғы

Бер мең туғыз йөз кырк өщөнщө йылның егерме икенче декаберендә шушы ауылда, Ырсай ауылы Илеш районында тыуғанмын, шушы ауылда жиде класс бөтергәннән соң, Баҡалы ауыл хужалығы училищесында бер йыл белем алып тракторда эшләдем, шуннан тракторда эшләп инде, бер мең туғыз йөз дә алтмыщ өщөнщө йылны армийага киттем, алтмыш алтынщы йылны армийанан ҡайтып, шушы ауылда тракторда эшләдем, анан соң бригадир булып эшләдем, шул бригадир булып эшләгәннән соң, ауыл советында эшләргә туры килде инде, дүрт йыл ауыл советы председателе булып, шуннан соң инде пенсийәгә сыктым, пенсийәгә сыккащ, ауыл советы имам итеп сайлап куйды. Миңа кәдәр эшләгән имам Сакаев Хәнәфи абзыйым, участник войны, бик хөрмәтле кеше, ул вазифасын үтәй алмый башлауын белдереп, миңа тәкдим йасадылар инде, әле дә мин шул эштә эшләп йөрим, әле дә Тимербай улы Хәнәфи абзыйымды хәр уакыт хөрмәт белән, хәр вакытта без аны йаратҡан ауылыбызның кешесе итеп искә алып йәшәйбез.

Безнең Кызлар тауы дигән тау бар, ул бөтен ауылда бар инде бугай. Ике төрлө фикер йөрий инде. Безнең бында йырак түгел Иш тауы бар, Иш тауында аклар ғәскәрләре булган, Кызлар тауында бийеклек бит инде, анда кызыллар булган, шуга да әйтелә кызыллар тауын Кызлар тауына әйләндергәннәр дип, дөрөскә лә туры килә инде, чөнки шул тауда уйнап йөрөгән чакта, бәләкий чакта, теге атылмаган, шартламаган иске патронлар чыга торган ийе, патша вакытынан калган, шулар табыла торганнар ийе. Икенче варийанты ла бар инде, анда кызлар беренче мөхәбәтләрен тапканнар, шуга Кызлар тауы дип атаганнар. Без инде күберәк тайанабыз беренчесенә, аклар белән кызыллар вакытында ауыл бер ничә тапкыр күщкән аклардан кызылларга.

Мына бында безнең төп йылга Ырсай арасынан аға Базы йылгасы. Аның башы, кайда Чакмагыш районында йыракта, шушы койа бит инде Изелгә. Эйе үзебезнең вак-төйәк йылгаларыбыз бик күп бит инде. Нажы, Сарйаз, Нәжәде йылгасы, ана шул табылдыҡ малайыбыз Нәжәде йылғасының әрәмәлегенән табылған инде. Тауларыбыз ана шул Кызлар тауы, аның кырында Карағол тауы. Шул Кызлар тауы белән рядом инде анда кемдер күмелгән булырга тийеш. Шунан ауыл кырында Кырын тауы, шуның кырында Әпес тауы бар бәләкий генә, Бизәр, Касим таулары, алар кеше исеме белән аталганнар инде элек.

Әпес тауында гражданнар сугышы вакытында бер кеше кащып йаткан, ул әсирлектән кащканмы, төрмәнән кащканмы, аны безнең халык күреп калганнар инде. Әпес тауында кыуыш короп йаткан. Шуннан аны саклау органнарына хәбәр итеп кулга алганнар инде. Ул дезертир сымагырак кеше була, шунан кала бу атама Әпес тауы. Шул кешенең исеме Әпес булган, безнең милләт кеше булмаган ул.

Шуннан Кәгелек тауы бар бит әле, онотоп торам. Бында бик властлы ҡортҡа булган, Кәгелек исемле әбий булган бик властлы, ул кайан килгән, белмиләр аны. Шул әбийне күмгәннәр шул тауга, ул бик бейик, Базы йылгасы йанында гына ул. Без үскәндә еләккә барадырийек, шунда бер йаңгыз ағащ үсеп ултырадырийе, кайын

идеме икән ул, исләмәйем, хәзер ул короган, ана шул әбинең ҡәберенә ултыртылган булган шул агащ. Шуннан Кәгелек тауы дип атала инде, шул әбий хөрмәтенә.

Боярышник – ҡамырлыҡ, черемуха – шоморт, шиповник – гөлжимеш, малина – ҡура жиләге, лягушка – бака, мочалка – мунчала, червяк – селәүщән, чашка – бәлүдәсе бар инде астында, йомро була. Бәләкий щакта көлкәй, аннан тай була бит инде, көлкәйдән соң кыркмыш дибез инде, ат инде жигелә торган була инде. Кечеләргә апай дибез, ир баланы энекәш дибез, ололарын апа, абый.

(Бәхтийәрова Әлфирә Нурислам ҡыҙы яҙып алды).

**Шәрәфетдинов Әнүәр Шәрәфетдин улы, 1931 йылғы**

Үзебезнең нәсел Әмир нәселе, анын барсын да белеп булмай инде. Безгә китабын да йасап бирделәр инде.

Ырсай бабай килгән инде. Безнең элек председатель булып эшлийдер иде Ғаббасов, үлде инде, шул йазып щыгара иде Ырсай бабайның нищәнще йылларда барлыҡка килгәнен, алай точно ғына әйтә алмайым.

Без үскән щакта суғыш щыкты, анда суғыш щыккащтан, анда бөтен әйбер дә суғыщҡа, фронт өщөн, шулай йәшәдек. Булған ашлыҡны сепереп алып фронтҡа, ә безгә ашарға йуҡ хөмөндә ҡалабыз. Тамаҡ ашауы да бик йайсыз иде. Ащ, кещерткәнде ашаныҡ, алабота, балтырған, кәжә саҡалы ашайсы килгәщ. Менә хәзер бала-щаға сөйләй бит ауызығызды кещерткән щакмадымы дип, аны шул ущта бер- бересенә ыщкыйщың да тегенең ағыуы бетә, щаҡмый. Менә колхозда эшәгәндә колхозның ауыр эшләре малай кешеләргә бигерәк төштө инде ул, сабанын сөрдөк, тырматтыҡ, ашлығын суҡтыҡ, бөтен булған эш шушы хатыннар, фронтовик хатыннары бар бит инде, шулар иң первый йөрийләр, алар оло бит инде, ә без малайларны эшкә өйрәтәләр иде. Шунан бездә эш ҡаты булды ул, эшкә бармай ҡалыу йуҡ, ул тәртип шулай. Бармас идең, әсәйең нейә Гитлерға йарзам итәсең меней, дип үзенән-үзең торасың. Шуннан безнең бер бригадир бар ийе Зиннәтуллин, үлде инде, суғыш ветераны инде ул. Бәй, бармасҡа әйтәсең бит инде ул, нәмә против советский власмы? ди. Менә барырға туры килә инде. Менә шулайтып йөрөнек. Ну урлашып тотолсаң, ауыр инде, төрмә сиңә. Өйдә инәй ҡарщыҡ бит инде, аның ире үлде суғышта. Ҡызы бар ийе жигерме дүртенче йылғы, Ленинградҡа эшкә дийеп киткән ийе, мылтыҡ биргәннәр аларға, окоп ҡарарға, шунда үлде. Оло абыйым бар иде Зөфәр исемле, ансы Белорусийа жирендә суғышта үлде, шунан Ғәмбәр, Тәскирә, Өлфәт, алары безнекеләр, тоже ҡырыҡ дүртенче йылны ангинанан үлде. Бездә ашлыҡ ауылы булды, ашлыҡ ҡала бит инде ул, шул ашлыҡ ҡар астынан щыҡҡащтан соң ағыулы булған, шуны ашадыҡ без. Ана шул инәйебез без нәмәкәй алыпҡайта алабыз, шуны өмөт итеп йата инде ул, анда аны эшкә йегәләр иде әле, эшсе күп кирәк, кул эше белән эшләргә кирәк. Менә шулай иттереп без. Менә хәзер йәшәйбез, аллаға шөкөр, әпий бар.

(Бәхтийәрова Әлфирә Нурислам ҡыҙы яҙып алды).

## СӘЙЕТҠОЛ АУЫЛЫ

**Асраров Вил Әхийәр улы, 1938 йылғы**

Бу ауылда туғандан бирле торам.

Мына Сарыйазы йылғасы. Ул ана Ырсай ҡырында, Ырсай астындараҡ Сарыйазы тигән ауыл бар, башын шунан алған, шунан сазлыҡлардан инде, шан Ҡызыл байраҡ аша, шан бына Ишҡарға килә, шунан төшә безгә Сәйетҡулға и барып Балтащҡа ҡойа. Сарыйаз йылғасы. Мына сез сыҡҡан күпер – ул Сарыйаз күпере.

Сарыйазы ул вообще урус ауылы ул. Русса Крещенка тип атала, халыҡ телендә Крещенка тип кергән ул. Значит крестить ителгән урустар йәшәй, без белгәндән Крещенка. Халыҡлар телендә Сарыйаз. Ә унысын мин белмәйем. Ул Балтащта Күәшкә ҡойа, ә Күәш Ҡаризелгә ҡойа.

Боярышник – ҡамырлыҡ, шиповник – гөлжимеш, малина – ҡура жиләге, земляника – жир жиләге, черемуха – шоморт, лягушка – баҡа баҡа инде ул, гөбөрлө баҡа тип тә әйтәләр; самец – ата, ат булһа – айғыр; божья коровка – тәтәйғош, угол – пошмаҡ, мешок – ҡапщыҡ, бабушка – ҡайсысы нәнәй тей, күверәге ҡартый тей; дедушканы – ҡартәтәй була.

(Хөснөтдинова Илүзә Илһам ҡыҙы яҙып алды).

**Асрарова Фәнисә Шәрифулла ҡыҙы, 1937 йылғы**

Сәйетҡулда йәшәйем. Шунда тыуҙым, шунда йәшәҙем, иксән биш йәштәмен хәзер.

Безнең ауыл ике партийаҙан тораҙыр инде ул. Берсе – әсрәй пароты, берсе – әҙиәт пароты. Әҙиәтуллиндар алар,шуңа әҙиәтләр пароты. Әҙиәтләрне иштей тип мысҡыл итәләр ийе. Әсрәйләрне әсрәй тип мысҡыл итәләр ийе. Былар бына әле Асраров тип ниткән. Ансы Әсрәй ҡарттың нейләре инде. Әҙиәтләр инде ул безнең әле менә берсиҙәтел дә булып эшләҙе, әсрәйләр тағы ходлы халыҡ, усал халыҡлар ийе, мин шуларның килене булып йәшәҙем. Хәзер аларның берсе дә ҡалмаҙы инде, үлеп бөттөләр.

Килен булып төшкәндә ат белән төштөм инде. Атҡа шунда бер чимаҙанны да салдылар. Атҡа ултыртып алып төштөләр ҙә, су йулы башлаттылар. Аннан әйберҙәрне ҡорҙолар ҙа, шуннан никах уҡыттылар инде мулла апкилеп. Менә шул булды. Элек бит инде эчемлек-маҙар йуҡ инде. Бочка белән бал ҡойалар ийе. Аны ҙа әле ул никах уаҡытында бирмәйләр ийе.

Жилайлар. Жилау була инде, әйе. Бойоғоп. Оҙатҡанда ней, тәүфиҡлы бул, түҙеп йәшәргә тырыш, тиҙеләр әнкәйләр. Иреңнән баш тартма, тип күңеле тулып нитте инде. Ул читкә, чит ауылға киткәч, күңеле тулаҙыр инде. Мин бит түбән очта ғына ийем. Мин ауылға чыҡтым кейәүгә. Жиламаҙым.

Әнкәй ходлы парот икәнен белде инде ул. Балам, түҙәргә тырыш, йәшәргә тырыш, тиҙе. Әнкәйнең сүзе шул. Әнкәй ике йәшеннән инәсенән ҡалған, жиҙе йәшеннән әтәсенән ҡалған. Үзе жәтим булған ул. Шуның өчөн, түзеп йәшәргә тырыш, балам, көчле пароҭка барасың, тиҙе. Илле йылдан артыҡ йәшәйбеҙ бит инде. Илле биш. Үзем виксән биштә. Әнә бабайым утыра сөйләп. Рәүфә белән. Асраров Вил.

Бергә уҡыҙыҡ. Класташбыз. Армийаға китте, аннан шунан хат алыштыҡ инде. Ҡайтҡас, өйләнештек. Бына шул булды. Арыу ғына йәшәҙек. Ике малай, бер ҡыз. Өч балам бар. Өчөсө дә Уфадалар. Торорға йерләре бар. Эшләре бар. Ҡайтып йөрөргә машиналары бар. Семьялары бар. Аллаға шөкөр. Сөйөнөп кенә торам да фатихамды теләйем, менә шул. Тигез йәшәсеннәр, тип. Бала ҡайғылары күрмәйем, тип. Төннә ҙә уйанған сайын теләйем. Нимә кирәк сезгә, түзегез, йәшәгеҙ генә, тийем. Бына шулай, бала ҡайғылары күрергә йазмасын, тип теләйем.

Мин медпункытта санитарка булып эшләҙем, утыз биш сум аҡчаға эшләҙем. Ун дүрт йыл. Утыз биш сум аҡча аҡчамы инде ул менә бер уйласаң? Кеше саны житмәй, безнең ауыл бәләкәй булғач, ҡайтып-китеп йөргөн кешеләр белән өч йөз иллегә дә тулмай. Полная ставка алыр өчөн, ти, жиде йөз халыҡ, жиде йөз кеше кирәк, ти. Йәркәйдә шулай тип аңлаттылар. Менә ун дүрт йыл шунда эшләҙем инде утыз биш сумға. Сөт жыйдым аннан. Аннан бәрәңге, чөгөндөр эшләү бар ийе. Исемен йазып бағана беркетәләр дә, үз ваҡытың белән эшләйсең инде ҡасан житечәсең шунда. Колхозда эшләгән кешеләргә бер гектар бирәләр ийе. Безгә шул, мин эштә эшләгәч, йартыны бирәләр ийе. Хәзер алар ҙа йуҡ бит. Йәшләргә Алла йарҙам бирсен. Әрибә инде повар ҙа булды, эшләмәгән эше ҡалмаҙы. Механизаторлар ашатты.

Бына ҡолмаҡ Рәйхананың баҡчасынан алмашҡа мин жыйып әпкердем әле. Мин нәмәкәй жыйалар микән тигән ийем. Күрҙем дә, бер ҡуш уч йыйып алдым. Шул ҡолмаҡ икән аның. Ҡоймаға үрләп үскән.

Чәчкәсен жыйасың да, шуны ҡабартып соңынан апра нитәсең дә, шул ачып шунан, элек шулай итәҙер ийек инде. Ҡолмаҡ ҡайда да үсмәй әле ул. Тегермән ҡырында бар ийе. Шунда бараҙыр ийек. Мынауының буйыраҡ була уның чәчкәсе.

(Хөснөтдинова Рәмилә Янсаф ҡыҙы яҙып алды).

### Шәмсетдинова Әрибә Йәүәр ҡыҙы, 1954 йылғы

Сәйетҡол ауылыныҡы, чығышым белән дә, керешем белән дә.

Мәғнәсе исемемнең... Әллә тағы. Жүнле исем түгелдер ул. Бер рәхәт тә күрсәтмәде бит ул. Әлкәштә, минем әнкәй Әлкәшнеке ийе, шушы Сәйетҡолға терәлеп тора инде ул Әлкәш, өч километр, шунда бер уҡытучы булған, шул Әрибә исемле. Имеш, миңә шуға уҡытучы булсын дип ҡушҡаннарҙыр ҙа инде...

Фәнисәнең мәғнәсе "йаҡты майаҡ" дип әйттең бит. Ул үзе шулай, йаҡты кеше. Кешегә изгелек итә гел. Үлгән кеше булса, мәйет йыуыша. Кәфен кисәргә бара. Ҡулынан килгән чаҡлы йарҙам итә. Тәртибен белгәч. Тәртибе дә кирәк бит әле. Төрлө жирдә төрлөчә бит. Әле өчөсөн, житесен үткәрәләр ийе, аны да "Өмөт" гәзитенә йазғаннар, үткәрсәң була, үткәрмәсәң була, дип. Бездә илле берне үткәрәләр. Ансы иттән сөйәк айырылған, сөйәктән ит айырылған көн, ди. Ныҡ ауыр көн, ди. Аны ҡайан беләсең инде, анда кем барып ҡайтҡан, тәүбә, тәүбә. Бер мулла әйтә бит, онотмас өчөн генә, береңне берең онотмас өчөн генә, былай китаптарда йуҡ, дип әйтә ул мулла да. Үткәрсәң, үзеңә рәхәт, бер душаңа рәхәт булып ҡала Ҡөрән уҡытсаң. Йә бер эш эшләгәндә әйтәсең инде, әйбәт итеп эшләп бетерсәм, бына Ҡөрән уҡытыр ийем, дип. Нийәт була инде ансы, ҡызыҡайым.

Бездә ҡызым, диләр. Мин ҡызым дип сүләшмәйем, чибәркәйем, дийем. Телевизорым ватылды да, звонить иттем "Майаҡ" гәзитеннән рекламаға. Шунан: "Чибәр улым, – димен, – минем телевизорым ватылған ийе, килеп китәлмәссез микән", – димен. Бер ыздарауай ир килде, оло ҡорсаҡлы, айаҡлары бычраҡ, йаланайаҡ, футболка кигән, ул футболка да бычраҡ ҡына, аның өстөнә рабочий костюм кигән. Саҡаллары житкән, ҡырынмаған. Өйгә килеп керҙе ҙә: "Минең чибәр икәнне ҡайан белдең", – ди. Минем бөтөн сөйләшеүем, туғанҡайым, шулай, дийем. Шулай иттереп, хәзер әйткән сүзеңә дә ҡурҡыныч әле, аны әйтеү белән, уйламайыраҡ әйтсәң, йауабын да тотачаҡсың, алла саҡласын.

Бындай чибәр ҡызларны күргәчтән, аның бит онтола. Уҡыған ҡызларны күргәч. Безнеке авиационныйда уҡый. Дүртенчедә уҡый ҡызымның ҡызы. Берсе икенче курста уҡый. Бер ҡызымныҡы Ижевскиды бетерҙе. Алты йыл уҡыҙы. Хәҙер уҡыу – энә белән ҡойо ҡаҙыу инде.

Билдәле кешеләр... Безнең ауылда үскәннәр ийе, анә Халиттең әле малайы үлгән, Айнур. Алар безнең ауылда үскәннәр ийе менә, безнең күршеләр генә булып йәшәҙеләр. Ҡартыйларына килделәр, ҡартыйларында йәшәҙеләр. Утыз ничә генә йәш, нимә булғандыр, трагедийа диләр бит.

Бездә бит теге уҡымышлы кеше ҙә йуҡ бик андый. Алай теге элекке йазучылар йуҡ бит инде. Шағирләр... Жырчы Фәнүнә Сиражетдинова бар Ишҡарныҡы. Роберт Миңнуллин вафат булды инде. Үзебезнең Сәйетҡолда бер ҙә андый ней йуҡ.

Без инде ней башҡортча әйбәт белмәйбез. Ней татарча белмәйбез. Башҡорт дип йазылған метрикәләргә. Метрикә дейләр ийеме элек? Башҡорт дип йаҙылған паспорттарға. Шәжәрә... Йуууҡ андый әйбер, йуҡ бездә бер

андый әйбер белән булышкан кеше йуҡ. Ундыйлар йуҡ ул. Йылан ырыуы дип йөрөйбөз. Бездә андый дәртле халыҡ, ней халыҡ йуҡ бездә.

Ҡырғыҙ ауылында дәртле бит халыҡ. Мин ул йаҡҡа ана завклуб белән концертҡа барам. Бездә ней мәктәп йуҡ, ней магазин йуҡ. Ишҡарҙа мәктәп бар, мынсы – ҡартлар йорто. Мында һаман бар әле ул. Быйағында медпункт бар, анан детсады бар. Бездә андый бер нәмә йуҡ. Менә клуб бар ийе инде, бикле тора инде. Ачылған ийе инде лә, тағы йабырлар инде. Ремонт йасадылар, матур. Эшләйдер ийе, менә әле теге чиргә була бикле булды. Менә әле ачылған ийе, тағы йабырлар микән инде? Бар ийе ФАП, хәзер сезнеңчә ФАП инде, ул да йуҡ. Ул үзе, эшләй торған кешесе, операцийа йасатты да. Бездә бит йәшләр дә йуҡ. Өйләр дә кәсаралаш ҡына. Бер өйдә бар, ике өйдә йуҡ. Үзебезнең ауыл бик матур, йылғалары аға, Сарыйаз йылғасы, чибәр ауыл, матур ауыл. Бездә бер ҡойо ҡазучы йуҡ, чишмәләр дә йуҡ. Су колонкаҙан, Ишҡарҙан килә. Ишҡар суы эчәбез. Бер фермер-фәлән, андый йуҡ. Бездә бер төрлә эш тә йуҡ. Менә Манышты белән ике араҙа бер ферма бар, аңа бер кеше, ике кеше йөрөй, бүтәнсә эш йуҡ бездә. Бер көнгө эшкә чығайым әле дигән кешегә дә йуҡ. Эшең булса, тәнең сәләмәт булса, бай буласың.

Безне ҡартайтып бетерделәр дә. Мәктәп тә бар ийе, хәҙер берсе дә ҡалмаҙы инде. Медпункыты булғанда да рәхәт ийе әле.

Ағымға ҡаршы йөзөп булмай, шул су йулына барасың. Пенсийәне генә бетермәсеннәр. Атнасына ике мәртәбә менә безнең ауылға әпий килә, әпий генә, бүтәнчә магазин-фәлән йуҡ. Вторник, субботаға. Ҡайсы бер ауылны бик зурлайлар да соң, бездә йуҡ. Әпийҙе үҙебеҙ ҙә салабыз ул, ҡышҡа. Бәй, менә мин үҙем генә йәшәйем, бер әпий алдисәм, миңә әллә ничә көнгә житә. Балалар ҡайтса-нитсә генә...

Ҡолмаҡ йуҡ. Драже файдасыҙ, диләр. Шулай ҙа соң инде, зарарлыҙыр инде. Элек әпий ачысы ғына ҡалдыраҙыр ийек... Әпий чиләге булаҙыр ийе, шунда әпий ачысы ҡалдыраҙыр ийек. Шуның өстөнә изеп нитәҙер ийек. Бына минем апа Уфадан ҡайта, Ҡырмысҡалы әпийе апҡайта, аларҙа ҡолмаҡ белән салалар.

Элек бар ийе инде ул туй. Өйләнгән кешегә туй эшләү бар ийе. Башта ҡызны барып сорау, анан туй көне билгеләү, бүләкләр бирешеү бар ийе элек, ҡыз йағынан да, йегет йағынан да бүләк өләшеү бар ийе. Мулланы щаҡырып, ниҡах уҡытыу буладыр ийе. Су йулын киленнең жиңгәсеме күрсәтә. Без башта Нефтяник йағында тордоҡ эткәйләр йортонда. Шунан туй булды. Мәктәп ҡойосона килеү бар ийе. Мәктәптә бик әйбәт су бар ийе, ул щағында мәктәп тә бар ийе, шул мәктәпкә суға килдек, урам буйлап әйләнеп. Сиртмәгә йаулыҡлар

ҡалдырып киттек. Шунан суны алып ҡайтып сатадыр ийек, суны сатыу бар ийе. Суны сатадыр ийе аны свидетелдар. Сондоҡ бар ийе.

Килен иренең ата-инәсенә өндәшә – әткей, әнкей. Хатынның энесе – ҡайныш, сеңлесе – балдыз. Туғаннарға – апа, абый. Бабушка, дедушка – ҡартәтәй, ҡартый, ҡартинәй, дәүәней. Йыраҡ әбей, йыраҡ бабай була әни йағыныҡы.

(Ҡотлоәхмәтова Эльнара Рафиҡ ҡыҙы яҙып алды).

## САУЫҘБАШ АУЫЛЫ

### Вәлиева Мәрүә Фәйзелғаян ҡыҙы, 1961 йылғы

Мин үзем Дүртөйле районыннан, Йүкәлекүл ауылынан. Бәләбәй педучилищесын бөтергәннән суң, шушы йаҡҡа мине жибәрделәр. Элек йуллама белән киләдер ийек бит инде. Мине дә шушы Краснокама районына йуллама белән жибәрделәр. Мин иң беренще килдем Сауз ауылына, ул сиксәненще йыл ийе. Шуңа хәзер мин ҡырҡ йыл инде бу йаҡта, үземнең йағымда мин ун алты йәшемә хәтлек кенә йәшәгән кеше. Сауз ауылында эшләй башланым да тормошҡа щығып, мына шул Саузбашта йәшәдек инде. Ике улым бар, хәзер икесе дә семйалылар, башлы-күзле булғаннар. Оноҡларым бар, шулай итеп йәшәп йатабыз.

Һәр бер жирдә барыбер шундай сүзләр бар бит инде ул, без белмәгән сүзләр. Иң беренще мин Сауз ауылына килдем дә мине квартираға керттеләр Сәлихә апаларға. Иң беренще көн бу, шунан хәзер апа эшләп йөрейдер ийе, мин дә әйберләремде кертеп ҡуйдым да, щыҡтым да апа ҡырына: “Апа, нәрсә эшләргә кирәк, йардам итәргә?” тинем. “Бар әле, бүкән апщығып бир әле миңә”, тине. Шунан мин кереп киттем өйгә бүкән эзләргә, бүкән йуҡ. “Ҡайда ул?” тип щығып сораным кире. “Нийә шунда өстәл астында инде”, ти. Шунан өстәл астынан да ҡараймын, теге бүкән йуҡ. “Мин тапмадым”, тип щыҡтым. Ул да әйтә белмәй утыра торған әйбер апщыҡ тип, мин дә уйлай белмәйем ниндәйрәк әйбер ул тип. Ләкин мин бүкән эзләйем, элек без бәләкәй щаҡта күмер чүлмәге бар ийе, баклажка тигән, утын ағащына утыртып ҡуйалар ийе, мин шуны эзләйем бит, ә ул утырғыщ булған. Шунан йаңадан Сәлихә апа белән сөйләшәбез: “Ә сездә бу нищек була?”, тип. Шунан ул шәнгә пешерәм тине, безнең йаҡта шәнгә түгел, пәрәмәщ бездә. “Эремщек шәнгәсе пешерәм әле”, – тине. Мәйтәм, нищек була ул. Шулай пешерде, ул бездәге пәрәмәщ булды инде, бездә ул пәрәмәщте эремщектән пешермәйләр, бәрәнге измәсенән пешерәләр. Төплөкәй тигәнен күберәк аны пешерәләр уғыздан. Сыйыр бозаулағащ, уғыздан. Ул минең әнкәйнең, бийанайның була инде, коронный блюдосы ул. Ҡыстыбыйға жәйгән сымаҡ жәйәсең ҡамыр, шуның өстенә мына шул уғыз массасын саласың да, уғызны йомшартасың да уасың да, жайлайсың да сөтләр белән, йоморткалар белән ҡушып, шуны тығасың мищкә. Шул мищтә ҡабарып ҡына пешә, аны әйләндерәсе дә йуҡ. Чий ҡамырны табаға саласың да, шуның өстенә саласың да, шуны мищкә тығып ҡуйасың. Төплөкәйне Дүртөйледә пешермәйләр, төплөкәй был йаҡ блюдосы ғына. Мында ул төплөкәйне пешерәләр дә бөтен үзенең күршеләрен, туған-тумащаларын щаҡыралар, оло сыйырның бызаулауы зур бәйрәм булған ул бөтен өйгә, бөтен туған-тумащаға. Мында төплөкәй пешерәләр инде, ә безнең йаҡта уғыз ашы ул. Сыйыр бозаулағащ, сөйөнещ бит инде. Сиңә муллыҡ килә өйеңә, сыйлы көнең сыйырда тип йуҡҡа әйтмәгәннәр бит аны.Иң беренще сөттән ҡаймаҡ эшлийбез, эремщек, ҡатыҡ ойотабыз, әйрән йасайбыз.

Тағы шундый сүз бар: имәнещ. Әйбәт кенә тигәнде аңлатадыр ийе ул. Имәнещ эшләнгән – күп кенә эшләнгән. Аптыраҭкан сүз бар – жамыйаҡ. Бездә аны ит табағы тиләр, ит тәлинкәсе тиләр. Чашканың тәлинкәсен бәлүдә тибез без. Дүртөйледә йоморо, асты – бәлүдә.Анан бу диалектта ҡата, без кийез итек тибез, пыйма тибез, бында кийез ҡата. Носки – ойоҡбаш, варежки – бийәләй.

Иң беренще бала ҡайтҡащ, исем ҡушасың, мулладан ҡуштырабыз. Анан суң ҡырҡ көнө тулғанцы баланы мунща йыуындырабыз көн аралаш. Пиннек белән, Дүртөйледә минлек тиләр. Сауызбаш халҡы йүкә мунщаласы йасай.

Элек-электән үк шушы балыҡщылыҡ инде мында, хәзер бу Саузбаш ауылында, Сауз ауылында балыҡщы булмаған кеше бик сирәк. Үзем йаратып ашай торған балыҡ – ҡорбан балығы (лещ), табан балығы (карась). Шөгә – стерлядка, ҡара балыҡ (линь) бар мында. Мин Саузға килгәщ, ишеттем, желтуха щиренән, сары щир була торғайны бит, шуңа шушы ҡара балыҡны ашатырға кирәк, тиләр ийе. Шунан щуртан, щүкә.

(Ҡотлоәхмәтова Эльнара Рафиҡ ҡыҙы яҙып алды).

## ЯҢЫ АҠТАНЫШБАШ АУЫЛЫ

### Бәхтиев Индус Мәғәфүр улы, 1937 йылғы

Йаңы Аҡтанышбаш ауылында тудым. Мында жидене, Ҡайынлыҡта унны бөттем, ауыл хужалығы институтында техникка уҡыдым. Әткәй беренще тракторист, Сәләхетдин ағай белән икесенә бер трактор биргәннәр. Йыраҡ әби алты баласы белән беренще колхозға кергән. Ун ике семйа арасында алар беренще булып кергәннәр. Дүрәтәйләр киредән колхозға кергәндә, Пермь йағына барып эшләп, ат алып, ат биреп кергәннәр. Башҡорт атлары бездә, суғыштан соң племенной атлар ҡайттылар, суғыштан ҡайттылар алар. Ул атлар бөтен кормушкаларны, бағаналарны ашап бетерделәр. Суғыш атлары бит.

Йегерме сигез йылдан ашыу председатель булып эшләдем. Йыраҡ әби беренще колхозцы булғащ, туғандан башлап шушы колхозда. Медалләрем бар: Йубилейный, Орден дружбы народов, За трудолюбийе и отличийе, Ветеран труда.

Әле мин исәпләгәне генә жиде йылға ағып щыға: Шушнур, Тауарты йылғасы, Уралы, Тирәгәй, Такийа йылғасы, анан Ҡара йылға төшеп китә Шапай ҡырынан, Кәлтә йылғасы, Нуғай йылғасы. Бергә алар Көн йылғасы тип аталалар.

Иң әйбәт дарыу үләне – клевер. Шунан ҡандала үләне, кещерткән. Баҡа йапрағы (подорожник), үгий ана йапрағы (мать и мачеха) үсә бездә.

Әсәй "әнкәй" бездә, әни, инәкәй. Йыраҡ әби – бу әнкәйнең инәсе. Йыраҡ бабай, әти йағыннан булса. Әти тимәйбез, әткәй тибез. Ҡартый тибез. Сеңлекәш тиләр, апай, энекәш. Уҡытыущыдан башлап апа. Бийанай, бийатай. Дүрәтәй (дядя).

Мына без үскәндә бер-ике кеше генә ҡорт тота ине. Без үскәндә алма ағащы йуҡ иде, ике кешедә бар иде. Мал электән тотҡаннар. Ауылға аҡлар, ҡызыллар килгән. Аҡларны ауыл йаратмаған бик, шунан былар килгәщ, сөт күтеп ултыралар бит инде. Йыраҡ әби сауа, пыщрағитеп, жыуып тормища. Грязь, грязь тип эщмәгәннәр. Ҡызыллар килгәщ, айырым сауып биргән.

Нәмә тип сөйләшәбез, нәрсә түгел. Тип әйтәбез, дип түгел. Бармайым, китмәйем.

(Зөбәйерова Ҡәҙриә Хөрмәт ҡызы яҙып алды).

**Ҡәйүмова Рәйсә Ғабдраҡип ҡыҙы, 1939 йылғы**

Татарстанның Иске Аҡтанышбаш тип аталған ауылынан дүрт кеше күщеп килә: Мерәс, Мәскәү, Балтас, Ғилаҡай. Иделне щығыу белән был йаҡта урман, шушы урманны былар ҡарайлар. Ағащларға тамға салып-салып киләләр, кире щығып китергә кирәк семйаларын алырға.Бик зур, суы сай бер йылғаға тап булалар. Аларның йулларында әллә нищә йылға ощрай, әммә мынсы аларға оҡшай. Ни өщен? Ул ҡиблаға ҡарап аға. Шуннан алар кире щығып китәләр, семйаларын алып киләләр, атлар, балалар белән киләләр. Атны житәкләп киләләр, щөнки ат йулы йуҡ бит, ат йалғышмасын өщен. Ҡарасалар, арбаларында бер бала йуҡ, ул дүрт айлыҡ, имезеп салынған. Тиз генә артҡа китәләр, күрәләр, ағащ ботағы эләктереп алған да баланы, бала бишектә селкенгән кебек йоҡлап йата.

Ауылыбызда Гәбдрәхим бабай бар ийе, ауылда уның белмәгәне йуҡ. Суғыш йылларында ул ауылны тереклек иттергән, щүмеще сынса, саплаған, тимер мищенә торба йасаған, мищләр эшләгән. Шулай иттереп, ире суғышта үлеп ҡалған семйаларды туңдырмайынща ҡышны исән щығарырға йардам иткән бабай.

Менә шушы бабайға мин кердем, шушыларды йазып алдым. Йазып алған дәфтәрем, балалар ҡулы белән йазылған дәфтәр исән, әле менә шуның истәлеген сөйлимен. Ауыл үрщей, аннан соң тағы киләләр. Житмешенще йылларда Татарстанның Аҡтаныш районының житәкщелегендә ҡунаҡҡа щыҡтыҡ татар теле уҡытущылары. Шуннан мин шушы тарихны искә төшөрдем. Иске Аҡтаныш ауылы минем жарщыҡларымның туған жирләре. Мәктәп директоры сөйлий: безнекеләр анда күщкән кешеләрне "жырткыщлар" тип әйткән ти. Ни өщен? Шул ҡәдәр урманны эшкәртергә, эщәр суларның шишмәсен эщәрлек хәлгә килтерергә, йуллар салырға. Шунан көлештек бу сүздән. Жыртҡыщ ҡына түгел, эщщән, ҡыйу.

Аҡтанышбаш ауылында мин сигез класс бөтердем, илле дүртенще йылны жиде класс бөтердем, сиксән бердә сигез класс ащылды. Ҡулымда ал тышлы китап, кеше һәр йаҡтан да гүзәл булырға тийеш, тигән китап. Парта артына утырып уҡыр вахытым үткән инде минем,тип уйлап, кеше йаңгылыша тигән. Утырғанмын ҡапщыҡлар өстөнә, шуып төштем, тәрәзәдән ҡарыймын, быйыл бездә Аҡтанышбашта сигез класс ащылған. Октябрь айы, килдем мәктәпкә. Озын тәнәфес вахыты, уҡытущылар бүлмәсенә индем, исәннәштем, шунан "мине сигезенще класҡа алмассызмы?" – тим. Мәктәп директоры: "Йуҡ, математиканан бик алға киттек, ҡыуа алмассыз"ти. Ә ул безнең ауылныҡы түгел, түрдә ултырған кеше, безнең директорһәр вахыт шунда ултырадыр ийе, аға мөрәжәғәт иттем. Мында бүтән уҡытущылар да бар: "Алайыҡ, уҡығанда бик тырыш ийе, бәлки, ҡуалыр"тиләр. "Йарый, килсен" тине. Аннан сигездә генә уҡысам, ике генә йыл ҡала бит туғыз белән унға тим, Ҡайынлыҡҡа киттем, унда унны бөтөрдем. Аннан соң шушы мәктәптә утыз жиде йыл хезмәт иттем. Гәрәйищ тырышҡанны күргәндер инде, мине эшкә щаҡырды. Йуғары белемне Башҡорт дәүләт университетында, татар теле факультетында алдым.

Ауылымны урап алған Йылға башы бар безнең. Суы бик әйбәт, хәзер инде анда шишмә булдырдыҡ. Районның бүтән ауыллары мында киләләр. Имам ҡортлоғо тип атала: Имам бабай анда умарта асраған, шунан шулай тип аталған. Шунан безнең эргәлә Бейек тауыбыз, колхоз ойошҡанда беренще колхозның исемен Бейек тау тип ҡуйғаннар. Артынан ҡойаш щыға. Шунан алтышынщы йылларда төзөлде Нефтекамск-Уфа йулы, аның теге йағында сазлыҡ. Ғомороҡ щоҡоробоз бар, бер ир белән хатын шул щоҡорда үзләренең мунщасына таш ташығаннар, аның төбөндә таш бар. Быларны эшләгәндә йәшен суҡҡан, үлгәннәр. Ғөмөрлөтә ғөмөрлө тип жылаған халыҡ, менә Ғомороҡ. Рәйес щоҡоро бар, ҡырҡ икенще йылны, ат арбасы ауып, малай ат астында ҡалып үлгән. Шунан щоҡор аталған Рәйес тип. Шушы Рәйес щоҡоро, аның төбөндә суы ла бар, ул ҡойа Мәтешкин щоҡорына. Ул күрше марий ауылы Щурмаҡҡа ҡәдәр төшә. Мында Матушкин тигән рус кешесе кирпищ суҡҡан. Безнең ауылыбызда кирпищ суға торған осталар да барлыҡҡа килгән. Күптән түгел мәщет ащтыҡ.

Күмерле йылғасы бар. Латип әрәмәсе бар, ул шунда мал асраған. Йылға башының теге йағындаЙалай щоҡоро бар, Йалалетдин исеменән. Ул ауылны хезмәтләндергән, тегәрмәне булған, су урғышы булған. Бағаналары әле дә исән.

Бездә йолалар онотолмаған, хайран быға сөйөнеүем. Туй йолаларын саҡлап ҡалғанбыз, суға барыу, май, бал ҡаптырыу. Элеккеләрдән киндер суғыу бәйрәме, мал суйыу, ҡаз өмәләре, ҡарға бутҡасы. Мәдәнийәт хезмәткәрләре зыйаратны жыйыштырырға өмә әйттеләр, ағащлыҡларда ҡазан астылар, бутҡа пешерделәр, жыйыштырып щыҡкан кешеләрне шунда щәй эщергә, бутҡа ашарға щаҡыралар. Колхозда эшләр башланып китсә, “Буразна бәйрәме” үткәрәбез. Трактарислар жыйылып басҡаннар, тракторлар аҡкош кебек тезелгәннәр басуға щығып китәргә. Тегеләргә, беренще буразна сызущыларға хәйерле йул теләп, изге сәфәр теләп озатабыз.

Тағын менә, кеше үлсә, ҡәбер ҡазырға ат белән ҡыщҡырып йөрийләр, ауыл буйлап, бармаған кеше ҡалмай ийе. Тыйулардан, ҡойаш байығащ,тырнаҡ кисергә йарамай. Бу эшне кещазна көн эшләргә кирәк. Бу жомғаға әзерләнеү була. Мәйет булған көнне идән, кер йумасҡа. Жыйназа (кәртә) ағащларын атларға йарамай. Ҡәберне үзен генә ҡалдырмайлар, тимер әйбер белән арҡылыға салып ҡуйалар.

Әзер өстәлебездә тош, чәк-чәк тора. Сыйыр бызаулағащтын, уғыз ашына жыйылыу, ул пешә сөттә, ҡызыл эремщеге эретелгән, уғыз майы да бар. Ҡабаҡ белән пешерелгән бәлеш. Туҡмащлы ащ, тәрилкәлә ит, бәрәнге, кәбестә, кишер. Төплөкәй пешерәләр (уғыздан пешерелгән). Талҡандан аш эшләйбез. Ҡаҡланған ҡаз, ҡаҡ эшләйбез. Элек ағащ ҡашыҡ тотток. Жамыйаҡ (күбәтә) – зур тарелкә. Миннекте пиннек тибез. Берсекөнгә тиләр бездә (иртәнән соң).

(Зөбәйерова Ҡәҙриә Хөрмәт ҡыҙы яҙып алды).

## ЯҢЫ ЙӘНИЕГЕТ АУЫЛЫ

### Ниғмәтова Сәхибә Зәкирйән ҡыҙы, 1932 йылғы

Шушы Краснокама районы Йаңа Татыш ауылында тыуғанмын, шунда башланғыщ класты уҡыдым, анан житенще класҡа тиклем Иске Мошты мәктәбендә уҡыдым. Аннан Татарстанға щығып, сигезенсе кластан башлап урта мәктәпне Аҡтаныш мәктәбендә бөтердем.

Йаңа Йәнийегет ауылында илле житенще йылдан бирле йәшибез. Нищә йылға тула торғандыр, илле житенще йылдан башлап шушында килеп урыннаштыҡ та шуннан бирле эшләйбез. Иптәшем шушында үлде инде. Иптәшем был ауылныҡы түгел, Свердловск өлкәсенең Нижний Сергей районы Ракай ауылында тыуған, мине институт бөтергәщ, Алабуга институтынан шунда жибәрделәр эшләргә. Анда мин бер алты йыл эшләп алдым, шушы иптәшемде ощраттым. Ул студент ийе ул щағында. Агроном исемен алып щыҡты. Эшләргә мында ҡайттыҡ.

Ауыл исеменә бәйле төрлө риүәйәтләр булды инде, дөрөсен генә бик әйталмайым. Мында Йегет исемле кеше урыннашҡан, ул башта шушында торғащтан, шул йегет исемен ауылға биргәннәр тип сөйләштерәләр.

Асау исемендәге йылға бар. Ағидел йырағыраҡ инде, Иске Йәнийегеткә йаҡын ул. Безгә йаҡыны Асау йылғасы. Нәрсәдән килеп щыҡканын әйталмайым. Татыш йағында Кәлтәй тигән йылға бар ийе. Унан йыраҡ түгел, ике щаҡырымда ғына марий ауыллары бар, берсе Ҡырғыз, икенщесе Бөрнөш исемле. Мына алар шул Кәлтәй буйына утырғаннар. Аннан йыраҡ та түгел Ашайыш йылғасы бар. Йәнәсе лә бу йылға буйына ике кеше килеп утырғаннар, тамаҡ йалғап утыралар, берсе рус милләтенән була, берсе татар милләтенән була. Шуннан татар әйтә инде: “Аша, аша”, тип, ә рус: “Ешь, ешь”тигән. Мына шуннан исем ҡушҡаннар йылғаға Ашайыш тип.

Бу йаҡлар шишмәләргә бай түгел. Басыулар берсе лә исемсез түгел инде ул, мин үзем йалан-йапанда йөрмәгәщ, минең ҡарт гел Жәмигә барам әле тип гел исеме белән сөйләй торғайны, агроном булғащ,бөтен басыуларның исемдәрен белә. Мин үзем ҡызыҡсынғаным йуҡ. Жәмидә бещән щабалар, Жәмигә бещәнгә төштөләр инде, тип ул сөйләй торғайны, шул ғына хәтердә ҡалған.

Ауыл тирәсендә йаҡында ғына щын урманнар йуҡ, йыраҡкараҡ барырға кирәк, Саҡлау йағына. Саҡлау ауыл исеме. Рус ауылы, шул тирәләр урманға бай. Таулар йуҡ. Тигез, таулыҡлар йуҡ.

Милләтебез паспортта башҡорт булып йазылған. Шәжәрәләр булып тора. Бер-ике кешенең шәжәрәсен матурлап, бик зурлап үткәрделәр. Ҡаһиров Хәнифтең шәжәрәсен үткәрделәр. Анан соң Хайретдиновлардың шәжәрәсен үткәрделәр.

Донйала ниндәй йола бар, һәммәселә үткәрелә инде. Мәсәлән, туй мәжлесләре үткәрелә. Элек суғыш вахытындә хәйерще булдыҡ, туй йасарға мөмкинщелек тә булмады. Туй булған икән тип китаплардан уҡып ҡына белә торған ийек. Илле алтынщы йылда өйләнештек, бөтөнләй туй йасаманыҡ. Хәйерще булдыҡ. Аҡщабыз да йуҡ, бер нәрсәбез дә йуҡ, ирем йағыннанда йуҡ, минеңйаҡтан да йуҡ. Туйсыз ғына бергә йәший башлайыҡ тинек тә, февралнең икесендә загсҡа бардыҡ. Эпийгә тамаҡлар туйғащ, хәзер туйны зурлап йасайлар.

Инәкәй, әткәй тиләр, әткәй йағынан ҡартый, ҡарт этей, инәкәй йағынан жыраҡай, жыраҡ бабай була.

Сөт ризыҡларынан ҡатыҡ, эремщек, ҡаймаҡ, май, ҡызыл эремщек йасайбыз. Ҡортто мин ишеткәнем дә йуҡ ине, йасағаным йуҡ.

Ауыл халҡында ҡушаматтар сирәк-сайаҡ бар. Ҡартым йағынан ҡушаматты беләм. Ниғмәтовтарны Онҡотлар тиләр. Күп ашап, күп эщкәнгә микән онҡотлар. Иске Моштыда уҡығанда Хәсәннәр бик күп ийе. Аларны айырыр өщен ҡушаматтары бар. Урам Хәсән, уның әти-әнисе булмаған, кешеләрдә ҡунып йөрегән. Себер Хәсән, раскулачиванийе вахытында Себергә жибәрәләр, ул исән-сау әйләнеп ҡайта. Ни щурта Хәсән, ул

әйткән сүз сайын “ни щурта”тип сөйләгән. Писарь Хәсән бар, ул укый да, йаза ла белмәй. Матур костюмдар кейеп, түшенә авторучка салып йөрегәнгә шулай тип атағаннардыр.

(Бәхтейәрова Әлфирә Нурислам ҡыҙы яҙып алды).

## ЯҢЫ ҠАБАН АУЫЛЫ

### Шөғәйепов Нәсим Ғүмәр улы, 1928 йылғы

Йаңа Ҡабан ауылында тудым, үстем һәм мына шушы йәшемә ҡәдәр шунда йәшәймен. Ҡабан турында хәтсез беләм мин, шуның өщен сезне дә аның белән таныштырырға исәбем бар. Йаңа Ҡабан ауылы – Краснокама районында иң зур, иң тарихлы ауылларның берсе. Аның матурлығы турында, аның тарихы турында бер нищә сүз әйтмәй мөмкин түгел. Беренще, Ҡабан ауылы районда өщ кенә урта мәктәбе булған ауылларның берсе. Районда шушы нефтчеләр килеп, киң экономик һәм культура төзелешендә үзләренең өлөшен кереткәнгә ҡәдәр районда ике генә больница бариде, шуның берсеЙаңа Ҡабанда. Краснокама районында унлап почта бүлеге бар иде, шул унлап почта бүлегенең берсеЙаңа Ҡабанда иде. Урта мәктәпкә уҡытущылар ҡайдан ғына килмәйләр, Башҡортостан Республикасынан ғына түгел, башҡа республикалардан, башҡа өлкәләрдән дә уҡытущылар киләләр иде. Больница булғащ, врачлар, фельдшерлар һәм башҡалар, шулай уҡ төрлө жирләрдән килеп эшләйләр иде. Почта бүлегенә әле утызынщы йылларға ҡәдәр рус кешесе житәкщелек итте. Суғыш бөткәнгә ҡәдәр икенще кешеләр, икенще өлкәләрдән килгән кешеләр, мына шунлыҡтан Ҡабан ауылының халҡы да бер төрле генә түгел, төрле жирдән килгән халыҡ. Мына шунлыҡтан бәхәсләшеп киткән вахытта: “Син кем суң? Татармы суң син? Син башҡортмо?” тиләр минең үземә. Мин аларға шулай тимен: “Мин башҡорт, ләкин мин татар башҡорт. Ни өщен татар башҡорт? Щөнки башҡортща мин матур итеп сөйләй белмиймен, мин татарща сөйләймен. Мына шунлыҡтан мин башҡорт, ләкин татарща сөйләймен”,тимен. Мына шундый ҡызыҡлы һәм мауҡтырғыщ Ҡабан ауылы ул.

Йаңа Ҡабан ауылы бер мең сигез йөз ҡырығынщы йылдан төзелә башлай, аңа ҡәдәр мең дә жиде йөз дә житмещ бишенще йылларны Пугачев восстанийесын бастырғащ, андағы кешеләрне эзәрлеклей башлағащ, күрше Татарстаннан шушы безнең йаҡҡа Ағидел йылғасының уң йаҡ йарына, бик матур жирдә жәйрәп йатҡан Йаланлыкүл тигән жиргә, эзәрлекләүдән ҡащып кешеләр килә башлай, бер ун биш-ун жиде семйа килә. Бу урын бик уңайлы, мал йөретергә, пещән щабырға, иген игәргә жире, балыҡ тотарға күле бар. Ләкин бер оло ләкине бар. Беренщесе, Кама йылғасы белән Ағидел йылғасы ҡушылған жирдәрәк бу. Кама йылғасы буйлап, Ағидел йылғасы буйлап мында йәшәгән кешеләргә тынғылыҡ бирмәйләр. Икенщесе, су булған йылларны бөтен жирде су басып китә. Йыллар буйы интегеп төзегән, эшләгән эшләрне йуҡҡа щығара, хатта йортларны узып киткән щаҡлар да була. Ул вахыттағы йортларны күз алдына китерергә кирәк, хәзерге кеүек мөһабәт йортлар түгел бит инде, унан-мынан салынған йортлар. Бына шунлыҡтан мындағы халыҡ бу урынны ташлап китергә мәжбүр була, ә бу урынны Ҡабан тип исемләйләр. Ни өщен Ҡабан? Щөнки мында ҡабан дунғызлары бик ныҡ үрщегән була, ә ул щордо ҡабан дунғызлары халыҡ арасында шундый мөхәббәт ҡазанған була. Икенще версийа була, фарсы телендә уйылып төшкән жирне ҡабу тип йөреткәннәр, ә шушы ҡабудан Ҡабан килеп щыҡҡан. Былар версийалар инде икесе дә. Шулай иттереп, Ҡабан кешеләре бу бик әйбәт жир булса да, мыны ташлап китергә мәжбүр булалар һәм өщ-дүрт километр көнщығышҡа табараҡ Сирай тауы тигән жиргә күтәреләләр. Аның ҡырынан ғына су аға, бик матур, үзе матур жирдә урынлашҡан. Теге талап йөрүщеләрдән уже ҡурҡыныщйуҡ, су басыу ҡурҡыныщы йуҡ, рәхәтләнеп йәшә дә йәшә. Ләкин тағы бер ләкине бар, жир йуҡ. Мында урынлашҡан анан-мынан жыйылған халыҡны типтәрләр тип йөреткәннәр, ә урындағы халыҡ – башҡорт. Башҡорт халҡының жире булған, ә типтәрләрнең жире йуҡ.Интеккәннең суңында бер мең сигез йөз утыз туғызынщы йылны ҡыйыу, эшкәбатыр, башҡа нәрсәләргә ашҡынып торған бер нищә кеше Ырымбур ҡазна палатасына йөрей башлайлар һәм утыз туғызынщы йылны, былар үзләрен башҡорт тийеп, үзләренщә документларын да шулай әзерләйләр, жигерме сигез кешегә Ырымбур ҡазна палатасы жир бирергә ризалаша. Нийә Ырымбур ҡазна палатасы? Щөнки әле ул вахытта бу йаҡлар Ырымбур өлкәсенә кергән булғаннар. Бу жигерме сигез кеше Сирай тауынан километр йарым, ике километр йыраҡлыҡтараҡ төнйаҡҡа таба бара Таубаҡты йылғасының ике йарына урынлашырға рөхсәт алалар. Таубаҡты йылғасы көнщығыштан алып көнбатышҡа таба ағып китә, шушы йылғаның ике йарына урынлашырға мөмкинлек бирә. Ошо жигерме сигез кеше арасынан берсе Шәйәхмәт тигәне безнеңбабаларыбызның берсе була. Шулай иттереп, утыз туғызынщы йылны рөхсәт алалар, шушы жигерме сигез кеше барып, ҡарап сөйләшәләр, килешәләр һәм ҡырығынщы йылны йортлар төзей башлайлар. Мына шулай иттереп бу жирне Йаңа Ҡабан тиләр, тегесе Йаланкүл буйындағысы Ҡабан иде, Сирай тауына күтәрелгәне Ҡабан булып күтәрелде инде, ә жигерме сигез кеше күщеп ултырғаны – Йаңа Ҡабан. Мына шулай иттереп, Йаңа Ҡабан ауылының төзелеп китеүен, нигез салыуын бер мең сигез йөз ҡырығынщы йыл тип мин үзем әйтәм.

Мына минең күршем, дустым, класташым Сафи Шакирйанов бар иде. Без аның белән йыш ҡына ул турыда бәхәсләштек. Ул әйтә торғайны инде: “Ҡабан ауылының тарихы мынан башланмай ул, Нәсим. Ҡырым йаҡларынан булған икән ул Ҡабан ауылы. Мына аңа хәзер ике мең дә унынщы йылларны өщ йөз сиксән йыл”, тий иде. Ә ул вахытта безнең Йаңа Ҡабан ауылына йөз илле йыл иде.

(Ҡотлоәхмәтова Эльнара Рафиҡ ҡыҙы яҙып алды).

## ЯҢЫ ҠАЙЫНЛЫҠ АУЫЛЫ

**Рамазанов Рәфит Мөхәмәтйән улы, 1950 йылғы**

Безнең ауыл боронғо ауыл инде, ныҡлап мына шушы безнең Үле Танып буйына килеп урыннашҡанына йөз йылдан артыҡ була инде. Шул ауылыбызда, мин бәләкәй щаҡта истә, зур көймә бар ийе, шуңа ике ишкәкще утырадырийе, ул көймә щабып эшләнгән ул, Таныпта балыҡ күп ийе, тоталар ийе, без төшәдерийек балыҡщылар ҡырына, безгә бидрәләп биреп жибәрәләр ийе, кеше шул ҡәдәр бер-бересенә доброжелательный булған. Ащлыҡтан алып ҡалған шушы Танып. Шунан суң үлән, үсенте күп булған. Үләннәрҙән мына инде ҡаҡы, ирен йарғыщ, “мына мыны ашама, ирен йарыла” тиләр ийе, витамин булған инде. Аны безнең тирә-йаҡтан килеп ҡапщыҡлап ташығаннар, ащтан үлмәскә, ҡырғый суған, аны щаҡ ҡына салып болғатсалар, мына тигән шурпа булған. Халыҡ эшщән ийе, ауылда төрлө мал, ферма ҡарадылар, даже теге дунғыз да ҡарап алдылар инде бер уахытны, коммунислар ҡушыуы буйынща, тауыҡ фермалары бар ийе, ат бригады бар ийе. Атлар күберәк ҡызғылт төстә, йерән бейә тигәне истә ҡалған, алалы-колалы атлар йуҡ ийе. Шул теге башҡорт нейенән ҡалған тип уйлайым мин аны, мына башҡортларның шул ҡызғылт төстә булған атлары, йерән төстә инде.

Изге кешенең үлгәщтән дә изгелеге ҡала тиләр, анда әүлийә, әледә әүлийәмен тип йөрегән кешеләр бар инде, баралар аңа өшкөртергә, мына шунда Әүлийә исемле кешене күмгәннәр. Ул изге эшләр эшләп йөрегән, бөтен тарихын белмәймен, ана шул Әүлийә шунда жирләнгән, шунан анда ағаслар үсеп щыҡҡан, наратлар инде.

Бер ике йөз илле йыл бар ауылға, әүлиәгә дә ағаслары буйынща ике йөз илле йыл. Суңғы уахытны кешеләр бәләкәйләнә, зур булғаннар, шушыннан Илеш районы тип теге Андрейевка йағына уҡ белән атышҡан тип сөйләйләр инде. Таныпта мына балыҡ бөтте инде, Иделдән су кермәй, шул Иделнең кермәүе бик ныҡ ауылға зыйан йасай, ул болонлоҡлар сазлыҡҡа әйләнеп бөтте, дүнгәкләр. Зато ҡошлар, аҡҡошлар килеп шунда ойа ҡорып, бала щығарып йаталар инде. Мында шул щелән килә инде, йаратты инде, мында безнең быйаҡта Танып, теге йаҡта саз тибез, анда йыланнар, баҡалар күп. Йаз көнө шығырлап тора инде алар, туй сымаҡ, шунда бала щығарып ҡайтып китәләр инде. Танып арйағында, Таныпта инде, аҡҡошлар йөзләгән генә булмағандыр, бик күп килделәр инде аҡҡошлар быйыл. Ҡыр ҡазлары безнең тирәлә бик күренгәне йуҡ. Шул торналар килә, сазда инде алар йылан, баҡа ашай. Щәүкә йазға табан килә ҡарға белән, ҡарғалар, сайысҡаннар. Сыйырщыҡ әзәйә бара.

Элек су кергәндә, безнең Танып буйыннан-буйына ҡомайаҡ ийе, күмелеп йатадырийыҡ. Шул щағында ун метрлы бредин белән кереп сөзөп щығалар, ҡапщыҡ тутырып ҡайтып китәләр ийе. Бер сәғәт үтте, алар артыннан икенще кеше сөзәдерийе. Шунан теге зур көймәлә йөрегән кешеләр ташлап тартып щығаралар гел эреләрен генә, алар мына опто тигән балыҡ, бик шәп ийе инде ул, симез балыҡ инде, ҡорбаннар, щүкәләр. Ау саласың, анысы керә генә, ә жылым белән сөзәсең, шунан мурда электән килгән инде.

Мал торған урын – абзар; ашарға салған урын – утлыҡ; йәйге ащыҡ урын – утар; ишек алды – ихата; балта, көрәк һ.б нәмәләр саҡланған урын – ҡаралты-кура; мейес – мищ; мейес башы – өнәк; мейес арты – кәберткә; мейес болғай торған ҡорал – кисәү ағащы; көл сеперә торған ҡорал – пумала, икмәк щығара торған ҡорал – эпи көрәге.

(Йомағужин Айҙар Ғариф улы яҙып алды).

**Мусина Әлфирә Тимерйән ҡыҙы, 1938 йылғы**

Ауылның тарихын мин төптән үк белмим инде. Бабайлар, әбейләр сөйләүе буйынща, Иске Ҡайынлыҡ ауылыннан күщкәннәр, тип әйтәләр. Минең әнинең ҡартәнисе сөйләүе буйынща. Башта ауылда әз генә халыҡ булған инде, йөз утыз ғына кеше булған безнең ауылда, шунан артып киткән. Башта оло урам ғына булған, оло урам, урта урам, арт урам тип йөреттек инде без үскән щағында, безнең урамларның исемләре йуҡ ийе. Мин үзем йәшәгән урамның тарихын төптән үк беләм, щөнки хәлле генә крестйан булып йәшәгән ҡартәтәйнең әтәләре. Алар күп мал асрап, жирләре булған, хезмәтщеләр тотҡаннар. Шунан ҡурҡып, колхозлашыу вахытында малайын, безнең әтәйне, сигезенще йылғы әтәй, әтәйне башҡа щығарған. Безнең урам шунан башланған. Безнең әтәй күщкәнще, дүрт кенә йорт булған, шуңа Дүртөйле урамы тип йөреткәннәр безнең урамны. Шунан күщә башлағаннар, был урамда бит инде хәзер ирләр үскәннәр. Безнең урамнан ун алты кеше йәшләр булғаннар бит инде. Бәләкәй генә урамнан ун алты кеше суғышҡа киткән, шуның алтысы ғына ҡайтты. Ҡартәтәй әтәйне ашыҡ-пошоҡ ҡына башҡа щығарған, өй иске булған. Суғышҡа киткәндә без дүртәү ҡалғанбыз инде, әтәй өй салырға тип бүрәнә китергән, өй артында бүрәнә щерегән, без шул иске өйдә ҡалғанбыз, әни белән дүрт бала. Минең кеүекләр күп ийе, һәр бер йорттан өщәр-дүртәр балалар ҡалды теге ун алты суғышҡа киткән кешеләрнең. Безнең ҡартәтәйләрне, әтәйләрне бик маҡтағаннар инде, бик эшщән булғаннар. Алар ураҡҡа барғанда, пещән щабарға барғанда арбала щабата йасап йөрегәннәр, шундай эшщән булғанлыҡларын әйтәм инде. Шуңа аларны талмас тип атағаннар, талмас тип йөреткәннәр аларны. Ауылда шул ашлыҡ щәщеү, мал асрау, анан Редькино белән ике арада смола ҡайнатыу базы булған.

Безнең ауыл бик матур, бик әйбәт жирдә урынлашҡан, бу йаҡта Танып, теге башта Идел. Идел белән ике арада болон. Танып белән ике арада тағы бер күл бар. Йазғы ташыу вахытларында су бик шәп киләдерийе, безнең Әүлийә зыйараты тигән бик изге урыныбыз бар. Шул Әүлийә зыйараты тау башында урыннашҡан, әллә ҡайан күренеп тора ул, Нефтекамскинан щыҡҡащта күренә, ҡарасаң. Кем утыртҡанын әйтәлмәйем анысын, ул

бик изге урын булған. Анда бер ҡәбер бар ийе мин бәләкәй щаҡта. Элек бит инде бүрәнәдән бура йасап эшләгәннәр, тимер ҡуймағаннар, шул бура бар ийе, хәтерләймен шул бураны. Аны инде кешеләр, моғайын,йаңартып торғаннардыр. Анан мин күргәнем булмады, аның ҡырыннан бер бәләкәй генә шишмә аға тип сөйләйләр ийе, ул булдымы икән, анысын әйтәлмәймен, ә теге бураны мин беләм, бик изге кеше анда күмелгән. Әүлийә тауынан Андрейевка тауы күренеп тора, Щәке тауы, Андрейевка тауы тип сөйләйләрийе инде. Гражданнар суғышы вахытында аҡлар да китә икән, ҡызыллар да китәләр икән безнең ауыл арҡылы, шунан тауда тороп суғышҡаннар, кешеләр үлгән бит инде, кешеләр күмелгән анда, сөйәкләр щығадырийе йар буйына. Су ташҡан вахытта ҡырт кискән кеүек жар жимереләдерийе, жимерелгән сайын кеше сөйәге күренәдерийе. Шул кеше сөйәге күренгәщ, йамғыр йаумағандыр инде. Ҡартлар жыйылышып, шул сөйәкләрне жыйып, су сибеп, доғаларын уҡып күмә торған булғаннар, әле мин үскән щағында да, әбейләр жыйылышып барып су сибеп ҡайттыҡ әле тип сөйләйләр ийе. Шул су сипкәннән суң йамғыр йауадырийе, шуңа ныҡ изге урын булған ул. Тәбиғәт әфәттәре булып ҡына тора безнең тирәдә, Ҡайынныҡ ауылында андай тәбиғәт әфәттәре булғаны йуҡ, боз да суҡмай безне, жил-дауыл да жимермәй, әле Дүртөйле йағында урман ҡырылды, урман бик ныҡ ҡырылып китте, безнең ауылға тимәде, безне Әүлийә саҡлай тибез. Анан суң ауылның теге башында, безнең ауыл өщ километр озонлоғо, теге башында боз йауды бер йылны, бөтен баҡщаларны тигезләп китте, безнең зыйарат ощонда боз йаумады, без исән ҡалдыҡ. Әүлийәнең ағащын кисмәделәр, йарамай, изге кеше күмелгәнгә күрә. Бер йылны браконйерлар килеп бер нищә ағащын кискәннәр ийе, без бер әбей белән бардыҡ ҡарарға шул ағащны кискәннән суң, мына шундай наратлар кискәннәр, аның берәр щерегән жире булса, ул бер ике йөз, өщ йөз йыллыҡ булғандыр инде. Бер-ике быуынын ғына алғаннар браконйерлар, өске быуыннары ҡалған, даже өске быуынынан өй салырлыҡ бүрәнәләр щыгырлыҡ ийе. Теге әбей утырып жылады жәлләп. Ауылны сағынып ҡайтсаң, башта Әүлийә күренә, Нефтекамски йағынан ҡайтасың, Әүлийә күренә.

Әүлийәне төшкәщтендә анда иң беренще Убырлыкүл тип йөретәләр, безнең инәкәйләр анда тал төшерәләр ийе, тал үсәдерийе. Убырлыкүл тип шуңа аталған, анда бер кеше төшөп үлгән, инәкәй сөйләүе буйынща. Анан китә Кендеклекүл, Ҡыуалыкүл, Имәнле күл, ә күлләр арасында болонноҡ. Без үскәндә болонноҡлар ныҡ жәмне ийе, калхоз пещәнне шунан әзерләйдерийе, ныҡ әйвәт булып үсәдерийе, йаз көнө су басадырийе, Әүлийәнең итәгенә щаҡлы киләдерийе. Шунан су китәдерийе, су киткәщ, матур булып үлән үсеп, калхоз шунан пещән әзерләйдерие.

Танып йылғасы белән Щәщеле арасында бер түгәрәк күл бар, Түгәрәккүл тип йөретәләр, аның бер жиренән дә су кермәгән, су щыҡмаған, ҡоромай да ул. Шуның суының әйвәтлеге, без табаҡка керләребезне тутырадырийыҡ та уҡығанда, шунда күл буйына су кереп, аның ҡырыйында бер үлән булмас ийе. Шунда су кереп, баш йыуып ҡайтадырийыҡ, суы ныҡ әйвәт ийе. Щикәшкүле, тағын Шүкәлекүл, Үргелде, Байыш, күлләр күп безнең.

Саҡла урманы мына, быйаҡта уже сазлыҡ, ауыл бит инде тау башында булғащ, ҡырында болон, бер километр ары сазлыҡ, сазлыҡта Саҡла урманы. Анда жирек үсәдерийе, жиректән өй салдыҡ инде без йәш щағында. Ағасларның барысы да бар, бөтен жимеш бар,шоморто, баланы, гөлжимеше, бөтен ағас та бар бездә. Шул наратныӘүлийә белән сазлыҡ арасында Нуртдин бабай утыртҡан, ныҡ әйвәт булып үсте инде хәзер наратлыҡ.

Атай – әтәй, әсәй – инәкәй, өләсәй – ҡартый, олатай – ҡартәтәй (атай йағынан), өләсәй – йыраҡай, олатай – йыраҡбабай, һеңле – сеңле, апай; ҡусты – энем, апай; түткәй (әткәйнең сеңлесе), дүрнәй, дүрәтәй (инәкәйнең сеңлеләре, энеләре); ҡайны – әткәй, ҡәйнә – әнкәй; ҡайын сеңле (ирнең сеңлесе), ҡәйнеш (ирнең ҡустысы).

Боярышник – ҡамырлыҡ; шиповник – гөлжимеш; малина – ҡура жиләге; земляника – жир жиләге; клубника – баҡща жиләге; черемуха – шоморт; лягушка – баҡа; божья коровка – тәтәй ҡош; угол – пощмаҡ; хлеб – эпи; мешок – ҡапщыҡ; ведро – бидрә; шерстяные носки – ойоҡбаш; валенки – кейезитек.Щынайаҡ, щынайаҡ асты, щәйнүк.

(Йомағужин Айҙар Ғариф улы яҙып алды).

## ЯҢЫ МОШТО АУЫЛЫ

### Шәйәхмәтова Наисә Әбүзәр ҡыҙы, 1950 йылғы

Йанауыл ауылында тыудым. Йаңа Мошто ауылында үстем.

Ауылның тарихы башҡорт ауыллары тарихы турындағы китапта ике генә жөмлә, йегерменще ғасыр башында барлыҡҡа килгән мөйөштә йазылган, бүтән нәрсә йуҡ. Безнең үзебезнең ауылда шушы ауылға күщкән кешеләр вахытынан уҡ йазып алынған. Безнең бик грамотный директорыбыз бар ийе, шуның тарафынан йазылған үзебезнең тарихыбыз бар. Бер мең туғыз йөз икенще йылларда ике ғәйлә Татарстаннан күщеп килергә жыйынғаннар бу йаҡтарға. Иске Мошто ауылы бездән ун ике, ун дүрт километр. Алар алданыраҡ килеп урыннашҡаннар. Шушы ике семйа килгән вахытта, быларның артынан килеп Иске Моштолар бик ныҡ ҡыйнап, алар кире ҡайтып киткәннәр. Фәтхейә исемле әбей ул вахытта ун биш йәштәге ҡыз булған, бер мең сигез йөз сиксән жиденще йылғы әбей ул, Кама тигән жирдә үлгән ул, йөз дә ун бер йәшкә житеп. Шул әбей сөйләгәне хәтеремдә ҡалған. Арттан килеп ҡыйнап, айағын сындырып, шунан бирле айағы аҡсаҡ ҡалған. Шунан соң, бер мең туғыз йөз сигезенще йылда, Татарстаннан Шәгәлей һәм Митшан тигән байлар ойоштороущылар булғаннар һәм мында беренще партийа халыҡ килгән, күпмелер кеше, былар арасында Зәйнетдин тигән кеше дә булған, ул зажиточный крестйан булған, урманщы булған. Икенще партийада миненжыраҡ әбейнең әтәсе, Шәйхәйдәр

ҡартлар килгән. Мына шулай ауыл ойошҡан. Ауылны ойошторған вахытта урман эше булған. Урманнар хәзерге кеүек булмаған. Бер мең туғыз йөз сигезенще йылдан ун жиденще йылға ҡәдәрурыннашып, өйләр төзеп, участокларын барлап, бер ниндәй эш белән шөғөлләнмәгәннәр. Соңынан мында ағащ төпләренән смола йасағаннар, анан соң ағащ күмере йасағаннар һәм күрше ауылның базарларына илтеп сатҡаннар. Күмер йамы мин белгәндә дә мәктәпнең спортзал урынында бар ийе. Ул землянка кеүек, астан йандырып күмер йасайлар ийе. Мин бәләкәй вахытта минең әбейдең өйө ийе бында, бу мәктәп урынында тәгәрмән ийе ул вахытта. Мына шулай халыҡ йәшәп киткән. Артыҡ ныҡ байлар булмаған. Миннеғәле тигән мулла булған. Өщ мәсет төзөгәннәр, ике мәщет эшләгән. Иң беренще ун алтынщы йылда мәдрәсә ащҡаннар, шәхси йортта. Ә мәктәп булараҡ ун сигезенще йылда ащылган, башта ике класс ащҡаннар, шунан тағы ике класс ащҡаннар. Ун сигезенще, йегерменще йылларда революцийа вахыты һәм граждалар суғышы ощоронда, мында өс йөз алтмыш хужалыҡ булған, меңдә жиде йөз кеше йәшәгән. Митшан белән Шәгәлей исемле байлар өщ кибет (лареклар) асҡаннар, шунда Василий тигән бер генә урыс кешесе эшләгән.

Утызынщы йыллар ахырында мәщетләрне кискәннәр. Бер мәщеттән правленийе, сельсавет һәм клуп эшләгәннәр. Икенще мәщетнең сүткәннәре – мин уҡыған мәктәп. Пристройлар белән төзеп-төзеп эшләнгән. Ул мәктәп утыз жиденще йылда төзелгән. Утыз сигезенще, утыз туғызынщы уҡыу йылларны мында жиде йыллыҡ мәктәп булған, ә алтмыш беренще йылдан сигез йыллыҡ мәктәп булды. Ә соңынан инде житмещ дүртенще йылда салынды бу мәктәп. Минязов Рим Кирам улы тигән директорыбыз йөреп бына шушы мәктәпне салдыртты. Анан тугыз йыллыкҡа әйләнде. Минең педагогик стажым бу мәктәптә утыз биш йыл. Шушы мәктәптә уҡыдым, шушы мәктәптә эшләдем мин. Минең балаларым да шушы мәктәптә уҡып щыҡтылар инде. Мин ун биш йыл йарым пенсийада. Мин пенсийаға киткәннән соң башланғыщҡа ғына ҡалдырдылар, анан бөтенләй йаптылар.

Бездә Камаш тип аталған йылға бар. Камалетдин тигән ҡарт шушы йылғала йәшәгән, хатын-ҡызлар кер щайҡау өщен басма салып биргән. Шул басманы салған өщен ул ҡартны халыҡ дошманы тип атҡаннар. Ул бик тура сүзле кеше булған ул. Зәйне кардоны тигән урын бар. Үзе урманны кисеп, өй салған. Әхмәт йаланы тигән йалан бар. Әхмәтдин тигән бер кеше йорт салып йәшәгән. Хәйдәр ҡойосы тигән ҡойо бар ийе, ул хәзер бөтте инде. Кешеләр малларына, атларына сыу эщереп китсен өщен Хәйдәр ҡарт ҡазыған, улйаңадан күмелде. Ҡараущы кеше булмады.

Безнең Бирге зыйарат һәм Арғы зыйарат бар. Бер кардон булған. Кардонда бабай ун жиде йәшлек Венера исемле ҡызы белән генә йәшәгән. Шуның ҡызы ун жиде йәштә генә үлгән. Иң беренще Арғы зыйаратына шуның ҡызы күмелгән, икенще безнең жыраҡайның әтәсе күмелгән. Ә нищәнще йыл икәнен әйтә алмайым.

Ике шишмә бар. Бер кем исем белән атамаған, уны Тау шишмәсе тип генә йөрөтәләр. Китә торган йулдан, әзерәк барғащтан, урман-таулар эщендә ул шишмә. Йөрейләр аңа, әле дә йөрейләр, машиналы кешеләр барып ала.

Дини бәйрәмләр үткәрелә инде. Мәсәлән, Ҡорбан бәйрәме, ғәйет уҡыулар була инде. Кищ утырулар элек, мине жырағәбей эйәртеп алып бара ийе, анда элек китап уҡыйлар ийе, “Йософ һәм Зөләйхә“,мин үзем әдәбийәт уҡыта башлағащ ҡына белдем аның әдәби әсәр икәнен. Ҡул эшләре эшләйләр ийе, шунда китап уҡыйлар, алай кеше сөйләү бер ниндәййуҡийе элек.

Безнең, ҡунаҡ килсә, иң зур бүләк, туйда лә шулай, иң зур бүләк – чәк-чәк, баурсакны бездә бик пешермәйләр, икенще районнарда пешерәләр, әнкәй пешерә ийе. Бөтен әйбер пешерә алам, чәк-чәк генә минең әйбәт щыҡмай. Тағын бәлеш бар. Бәлешне ит белән дә, ҡабак белән дә, төрлещә эшләйләр ийе. Гөбәдийә эшләйбез инде, ҡатлы гөбәдийә эшләп ҡуйам. Гөбәдийәне зур табаға эшләймен. Бик тәмле була.

Щынайаҡ әйтмиләр, жомро тиләр. Ҡалаҡны ҡашыҡ тиләр, безнең ауылда ҡашыҡ тиләр инде. Мищ арасын кәбәрткә тиләр, ә ҡайбер урында аны гөлбәш тиләр. Мендәр тибез. Йастыҡлар йуҡ хәзер, элек йастыҡтиләр ийе, ул минеңжыраҡәбейнеке дә бар ийе. Йастығы менә озон ийе ул, оло ийе. Хәзер бит йевропейский мендәрләргә күщтек бит.

Менә безнең элегерәк бар ийещибәр әбей, щибәр апа тип атайдырыйыҡ. Белмәйем, щибәр булды микән ул, әнкәй үрәткән инде. Аннан соң, бал әбей. Бал әбей бар ийе безнең, ул туған ийе, ул умарта тотҡандыр инде, күрәсең. Алма апа, аҡ әбей. Аҡәбей, бу дини, гел шундай чиста йөрей торған, йомшаҡ, тәртипле, тәрбийәле кеше, уҡымышлы дини йаҡтан аҡ әбей бар ийе. Дүртүткәй, бу минең, мәсәлән, эткәйнең апасы ийе. Элек шулай бар ийе, ә хәзер гел исем белән генә. Ҡода, ҡодағый. Бийанай тибез – свекровь. Бийатай, бийанай. Әткәй, әнкәй тип әйтәбез инде. Зуртүтәй бар. Дәү эти, зур эткәй, зур әнкәй. Төрлөщә, нищек үрәтәләр. Ә хәзер... Апа йуҡ, исеме белән әйтәбез инде. Сеңлем, энекәш бар инде. Безнең менә әдәби телдә уҡытыущылар, уҡыущылар сөйләшәләр инде.

Ҡортлоҡтип йөрөтәбез. Урман эщендә ҡортлоҡ. Ул колхоз умартасы булды. Аннан соң Сабанща ауылында бар ийе ҡортлоҡ. Анда Нурғәли тигән бабай эшләде. Анда йүкәлек буйдан буйға. Анда сарыҡ фермасы да бар ийе. Бөтөнесе бөтте бит алар. Бөтен нәрсә бар ийе. Менә бәләкәй генә Йанаулда да ҡуйан фермасы бар ийе, ат фермасы, сыйыр фермасы, амбар, ындыр табағы бар ийе. Бөтен нәрсә бар ийе. Пещәнлекләр бар ийе, һәр кемнең айырым пещәнлекләре дә бар ийе. Әммә элек ул пещән мәсәләсендә авыр ийе. Ҡул белән щабалар ийе. Ат белән тарттыралар ийе. Машиналар белән йөрөтәләр ийе. Моштола да амбар бар ийе, ферма да бар ийе. Бөтен гаражлар, бөтен нәрсә бар ийе мында. Хәзер йуҡ, берсе дә йуҡ. Онотолоп бөтте.

(Зөбәйерова Ҡәҙриә Хөрмәт ҡыҙы яҙып алды)

## ЯҢЫ НУҒАЙ АУЫЛЫ

**Айытов Винарет Шамил улы, 1960 йылғы**

Алтын туй йоласы ул кертелде бер тистә йыл ғына түгел. Бының изюминкасы нәрсәдә? Башта барып туған йылдары, тормош йулы, бөтен ауылдың тарихы, башҡа нәрсәләре йазыла. Шунан соң мәдәниәт йортына сәхнәгә щаҡырыла һәм торжественный рәүештә уларның тормыш йылларын сөйләп, бүләкләр биреп, шундай бер тамаша, соңыннан фотокарточкаға төшөү,мынә шундай бик матур йола бездә йәшәп килә, алтын туй йоласы.

Безнең клупта үрнәкле бийү ансамбле "Бәйрәм" бар. Алар республика смотрында, район смотрында һәр вахыт щығыщ йасайлар. Бездә фальклор коллектифы бар – "Умырзайа". Бик күптән йәшәп килә, ауылда ғына түгел, район, республика күләмендә щығыщ йасағаныбыз бар.

Сабантуйлар үткәрелә. Сөлге жыйыу үзе бер бәйрәм булып тора. Анда милли кейемнәргә кейенгән балалар, бизәлгән ат һәм ололар инде – гармунщылар. Безнең сабантуй һәр вахыт икегә бүленә – беренщесе балалар сабантуйы була. Аннан кире ололар сабантуйы. Һәм, әлбәттә, сабантуйның бизәге бына ошо бийү коллектифлары, жырщылар, фольклор ансамблләре инде. Мынә күп йыллар ат щабышын үткәрәбез.

Мәщетебез дә бар. Мәщетебез азаҡкы йылларда бик актифлашып килә. Ауылыбызда шәжәрә бәйрәмләре узғарабыз. Даими рәүештә узып тора, ул ауыл кимәлендә, район кимәлендә зур бер ваҡиға.

Ҡаз өмәсен йыш ойошторабыз.

"Ғайнан" ҡурайщылар ансамбле – район музыкаль мәктәбенең филиалы эшләп килә уңышлы ғына. Өщенще поколение ҡурайщылар. Алар республика конкурстарында гел призлы урыннар алалар.

Ҡул эшләре остасыларына йөрөү экскурсийаларын ойошторабыз.

(Бәхтейәрова Әлфирә Нурислам ҡыҙы яҙып алды).

**Зәкиева Флүсә Ғәни ҡыҙы, 1938 йылғы**

Ҡабаҡ тәкәсе ул ҡабаҡ белән дөгө йармасын ботайсың да, бына болай итеп кенә бөкләйсең. Безнең телдә ҡабаҡ тәкәсе, культурный пирожки инде.

Иптәшемнең сеңлесен мин ҡайынсеңлем тип йөрөттем. Атасы йуҡ ийе, суғышта йуғалған.Ҡайнанамны әнкәй тип йөрөттем. Иптәшем әнкәй тигәщ, мин дә әнкәй тинем. Электән ҡалған бит ул, хатынны алсаң, су теге йағыннан ал тип, шуға хатынның әнкәсе – жыраҡ әбей, ә әткәсе – жыраҡ бабай. Иремнең энесе йанағай була. Балалар өлкәнен дүрәтәй (ирнең өлкән ағасы) тиләр ийе, дүрнәй (өлкән хатын туғаны) тинеләр. Кещесен йәшәнәй, йәшәтәй тиләр. Оло ир кешегә абзый тиләр, әбей – ҡортҡа.

Суғым суйыуға бер атна-ун көн әзерләнәсең, эщәген жыуырға кеше щаҡырабыз, суғым суйыущы айырым кеше килә, бик жәмле була. Аш пещерәсең кищ. Мәжлес йасайсың.

Безнең ауылның халҡы ныҡ усал ийе. Татарийалар мыннан йөриләр ийе элек, алар исән-имен ҡайтып китмәнеләр инде, аларны дөмбәсләп жибәрделәр. Ауылда ун өщ атама бар. Суғыш вахытында хатын-ҡызлар тракторда йөрегән. Бер Тәһирә исемле ҡыз трактор белән китеп барғанда үлә. Шуға Тәһирә баҡсащы тигән урын бар. Бабай сады, Әзекәй урманы, Мансур йаланы, Йаҡуп сады, Ғәбдрәшит сады бар. Аҡ ҡына тигән жир бар. Аҡ төстә булғанға шулай аталған.

(Бәхтейәрова Әлфирә Нурислам ҡыҙы яҙып алды)

**Сөләймәнов Вәғиз Һәүбән улы, 1940 йылғы**

Йаҡында Ағидел йылғасы бар, Ағиделнең бы йағында Нуғай ауылы булған. Ул ауыл сыу килгәщтән күщенә башлаған. Ҡартларның әйтеп йаздырыуы буйынща, бер мең дә сигез йөз дә ҡырыҡ дүртенще йылны дүрт охотник мында килеп щығалар, мында өщ шишмә ағып йата, урманныҡ, матур урын. Төн ҡунып китәләр мында, ҡайталар да сөйләйләр: Шул Нуғай ауылына шундай матур жир таптыҡ, тип. Мында электән урманныҡ булған. Шуннан был дүрт ғайлә, семйа килеп мында төпләнәләр, маллар үстереп, жир эшкәртеп, иген басыуы итеп, ағащыннан өй-ҡуралар салып, ауыл зурайғаннан зурайыуын дауам итә. Минем уҡыған буйынща, бер мең дә өщ йөзенще йылға ҡәдәре Нуғай тигән батыр булған. Ул – өндәүще, Ҡазағстан, Үзбәкстән йаҡларыннан килеп башҡортларның көтөүләрен апкитә башлағащтан, был Нуғай тигән кеше әйткән: "Сез безгә әйтегез, без бергәләп тормыш көтәйек, башҡортларға әгәр дә алар һөжем йасасалар, сез йардәм итәрсез. Сезгә һөжүм йасасалар, патшаға ебәрегез атны хәбәр итәргә, без сезгә йардәм итәрбез". Безгә бер кем дә йардам итмәс тийеп, безгә нащарлыҡ китермәс тип ризалашалар. Ә ул Нуғай тигән кеше бер мең дә өщенще йылны үлгән була инде, шуға ҡәдәре йәшәгән кеше ул. Бу ауылда ырыулар бик күп, аталмыш ыруҡлар бар, мына мин үзем щарлаҡ ыруғынан. Шәмси ыруғы бар, тәтәй ыруғы бар, мынна без үзебез Гәрәй ырыуыннан щыҡҡан кешеләрбез.

Шишмәләр бишәү булған, Күпер йылғасында ике шишмә бар. Байа әйтеп киткән өщ шишмәнең икесе исән, шул сыу белән әле без бөгөнге көнгә ҡәдәре ҡулланып киләбез, тәрбийәләп тоталар бөгөнге көнгә ҡәдәре. Аларны без үзебезсә генә атайбыз: Урта йылға, Хәтирә йылғасы тибез. Анның шишмәләрен тәрбийәләп тоталар. Уның йушҡыны бар, минераль тозлары булмаса, ул шишмә дә булмай. Маҡтап эщәләр инде ул сыуны. Шул сыулар белән без туҡланып үстек тә инде.

Халыҡ электән малщылыҡ белән шөғөлләнгән, жирләрне эшкәртеп, ашлыҡ үстергән. Умартащылыҡ белән шөғөлләнгәннәр, урман йаҡын булгащ, башта килгән кешеләр шишмә буйына өй салғаннар.

Йаңынан безнең йаҡка Татарстан йағынан бер нищә милләттәр килгәнлеген беләм, Мостафиндар, Ғатауллиннар бар. Алар Татарстандан тегеүщеләр булып килеп урынлашып, аларның ыруғлары таралды мында. Шулай итеп, Ҡазан йағыннан килгән татарларның ыруғлары ла бар. Улар малщылыҡ белән шөғөлләнгәннәр, суғыш бөткәннән соң колхоз жиренә әллә нищәмә йыллар трактор белән бер кешенең тиресләрен тейәп басыуларга түктеләр. Бик күп мал асраганнар, малщылыҡ белән шөғөлләнгәннәр.

Урманда безнең ҡатнаш ағащлар – жирек, ҡайын, ыршы ағашлары, наратбар, ә инде халыҡка йал итәргә ауылға йаҡын ғына, бер щаҡырым да йуҡ, әрәмәлек бар. Халыҡ унда жиләк, щитләүек жыйып ҡайта. Безнең ауыл тирәсендә Башҡортстанның көнйағындағы кебек шуа торған таулар йуҡ, шулай булыуға ҡарамастан, өщ шишмә булгащтын, шишмәнең йары булмай ҡалмай, текә-текә йарлары бар ийе. Шул йарларда без щангы шыуып үстек.

Шиповникты бездә гөлжимеш тиләр, бойарышник бездә ҡамырлыҡ ул, ул гөлжимеш кебек ауылыбызға терәлеп үсмәй, бер ун километрлар алыслыҡта үсә.

Безнең йаҡта электән боланнар, пошый тип әйтелә, без болан тип өйрәнгән инде, ул пошый бит инде. Шуннанхәзерге вахытта ҡабан дунгызлары күренә. Төлке, ҡуйан бар. Шуннан инде төлке, ҡуйан булған жирдә тәбиғәтне тазартыр өщен санитар бүре була бит инде. Ҡырғый жәнлектәрдән рыслар бар.Селәүщен тиләр микән, ҡырғый песәй микән. Ҡыр кәзәсе (косуля) бар. Хәзерге вахытта айыу күренә башланы. Аҡҡошлар күп безнең йаҡта. Сыйырщыҡ, ҡара ҡарға бар, сандуғащ, сабан турғайлары бар. Щәпщекне әйтеп торасы ла йуҡ, жәйнең ащҡыщы кәккүк бар.

(Бәхтейәрова Әлфирә Нурислам ҡыҙы яҙып алды).

## ЯҢЫ ХАЖИ АУЫЛЫ

**Әмиров Фирҙәүес Вара улы, 1952 йылғы**

Мин Хажи ауылыннан, ул Ҡуйан сельсоветына керә. Мынан сигез километр. Шушы ауылда сигезне бөтердем, йаңадан Ҡайынлыҡ мәктәбен бөтердем. Татар теле һәм әдәбиәте уҡутущысы. БДУ-ны бөтердем.

Безнең ауыл урман эщендә булған, Илеш районының Хажи ауылыннан сигез семйа килеп безнең ауылға мең дә сигез йөз дә йегерме жиденще йылда нигез салғаннар. Бу Хажи ауылы Илеш районында хәзер йуҡ, ул Йаңа Айыу сельсоветына керә иде. Шушы сигез семйа бөтен мөлкәтләрен тейәп, бер километр йарым саз аша кергәннәр, шуннан кире урман эщендә өй сала башлағаннар. Тырыш халыҡ булған. Минем әткәй дә, әний дә Хажи кешеләре, аларның иске өйләре бар иде, ул иске өйне мең дә туғыз йөз алтмыш беренще йылда сүткәннәр, бу өйгә йөз йегерме йыл булған. Бағаналары ныҡ булған, шуны әткәй белән әний сатып алғаннар. Сәлим исемле ҡарт булған, ул Щумарға күщкән. Менә шушылай итеп Хажиға нигез салғаннар. Алтмыш туғыз йыл йәшим унда. Элекке клубын да беләм, мәщет зданийесы ине. Мең дә туғыз йөз илле алтынщы йылны булса кирәк,йаңа клуп салдылар. Ғөмер буйына ауылда фельдшерский пункт булды. Библийотека булды, китапхана.

Илеш йағында, без ҡыр йағы тибез, анда ныҡ ауыр булды йәшәүе. Анда утын булмады, анда ағащ булмады, бер нәрсә дә булмады. Алар безнең районнан ғөмер буйына ағащ ташыды. Щәғәт иртәнге жиделә тракторлары киләләр иде.

Ауыл халҡы колхозларда эшләде, иң беренще колхозлар мең дә туғыз йөз утыз икенще йылда эшләгән, ләкин колхозға керүще булмаған. Гражданнар суғышы вахытында ауылны аҡлар басып ала. Ауылда хужа булғаннар, мында Борхан мулла булған, уның малайы аҡлар белән китә һәм бер нищә кеше дә алар белән китә. Ҡызыллар килгәщ, ҡащырға мәжбүр булалар. Гражданнар суғышы тамамланғащ, ауылда Шафиҡ бай белән Вәли бай була. Уларның үзләренең магазиннары була, лафкалары була.

Ауылда башта уҡыған кешеләр йуҡ иде, бер Сәмиуә апа бар иде уҡутущы. Рус теленән ныҡ әйбәт уҡытты. Икенщесе – Салахов Сәғәсетдин, ул МГУ-га кергән булған. Ул районның госконтролнең председателе булып эшләде. Безнең район ғөмер буйы Ҡалтасы районына ҡарады. Мең дә туғыз йөз йетмеш икенще йылда ғына Краснокама районына күщте. Әйтергә кирәк, Ҡалтасы ауылы безнең ауылға ун сигез километр, ә Березовкаға щаҡлы житмеш бер километр. Ауылда колхоз төзейләр, Кәлтәйдә МТС була. Минем әткәй ғөмер буйына тракторщы булды, ике тракторист, ике плугар эшләде. Әтинең беләм НАТИ тракторында, илле дүрт тракторында эшләгәнен. Бөтөнесе дә күз алдымда, бүгенгедәй. Әтий дә сүйләйиде, безнең ауыл йағында нефтселәр суғышға щаҡлы да булған. Көз көне киләләр, ҡыш буйы эшләйләр, анан йаз көне ҡайтып китәләр иде. Безнең өйнең икенще йағында ғөмер буйы нефтяниклар йәшәделәр.

Ғәлмекәй тегәрмәне тигән атама бар, Теккәм йылғасы аға ауыл ҡырыннан, аның балыҡларының күплеге, ныҡ күп иде. Бик йыраҡта тегәрмән булған, аннан ҡалған. Көйек – урманның бер жире. Төкеш басыуы бар. Тегәрмән сырты да бар. Мәкше – кешеләрнең пещән щаба торған жирләре шулай аталған. Әри сазы бар, йылға аға,ғөмергә щыға алмаслыҡ. Озон күпер тигән жир бар, ул да сазлыҡ. Ҡорт баҡщасы тигән жир бар, ҡортка ловушка элгәннәр, күщ керсен өщен.

Ревалюцийаға щаҡлы күп кешенең өщ-дүрт атлары булған. Ҡалтасы районының Гәрәй басуында йөрөгәннәр. Басуны зурайттылар ғөмер буйы.

Тәтиҡош тибез бөжәкне, ҡойаш апай. Алла тауығы тиләр тағы. Кәтмән (тәпке) тибез. Йышҡыны ышҡы тибез. Ҡадаҡ – ҡазаҡты. Ҡайсы бер кешеләр апаны щәтәй тиләр көлеп, бер жирдә лә йуҡ. Тары йармасы күзләү тип атала. Щабрец үләнен күз үләне тиләр безнең йаҡта.

(Зөбәйерова Ҡәҙриә Хөрмәт ҡыҙы яҙып алды).

**Краснокама районы йәнле һөйләү теленең лингвистик үҙенсәлектәре**

Телселәр билдәләүенсә, Краснокама районы ерле һөйләше тел билдәләре яғынан төньяҡ-көнбайыш диалекттың түбәнге ағиҙел-ыҡ һөйләшенә ҡарай. Был һөйләш төньяҡ-көнбайыш башҡорттарының – йәнәй, гәрәй, уран, йәлдәк, ҡаршын, ҡырғыҙ, ҡаңны, шәмшәҙе, юрмый, байлар, бүләр – ырыу һәм ҡәбиләләренең йәнле һөйләү теле булып тора. Түбәнге ағиҙел-ыҡ һөйләше зонаһында шулай уҡ меңлеләрҙең – ҫарайлы-мең, ҡобау-мең, табындарҙың ирәкте ырыуҙары, балыҡсылар, ҡатайҙар һәм әйлеләр йәшәгән ауылдар бар.

*Район һөйләшенең фонетик һәм морфологик үҙенсәлектәрен билдәләп үтәйек.*

Вокализм системаһындағы диалект билдәләренән түбәндәгеләрҙе күрһәтеп үтергә мөмкин. Был өлкәлә киң таралған фонетик күренеш – сингармонизмдың боҙолоуы. Әҙәби телдә ө өнө буйынса күҙәтелгән ирен гармонияһы был һөйләштә боҙола, тик нәҙеклек гармонияһы ғына һаҡлана: *төлке – төлкө, төсле – төҫлө, өщен – өсөн, көтеү – көтөү.* Был күренеш эйәлек аффиксы ҡушылыу осраҡтарына ла хас: *көне – көнө, бөтөнөсе – бөтөнөһө, төрлесе – төрлөһө, өлөше – өлөшө.* Төрлө һүҙ төркөмдәренең һүҙ формалары яһалышында ирен гармонияһы боҙола*: бөтөрде – бөтөрҙө, йөрет – йөрөт, өщенще – өсөнсө, бөтеп – бөтөп.*

Ө – Ү. Айырым һүҙҙәрҙә әҙәби телдәге *ү* өнө һөйләштә *ө* өнөнә күсә: *гөмер – ғүмер.*

Е – Ү. Һөйләштә әҙәби ү өнөнөң е фонемаһы менән сиратлашыу осраҡтарына миҫалдар бар: *һөжем – һөжүм.*

Тартынҡы өндәр системаһында, ғәҙәттә, диалект үҙенсәлектәре киң урын ала, шуларға туҡталып үтәйек.

Был район ерлеге телендә *щ – с* өндәр күсеше продуктив фонетик күренештәрҙән һанала. Башҡа райондарҙа был сиратлашыу айырым информаторҙарҙың телендә генә сағылыш тапһа, бында һәр бер информаторҙың телмәрендә осрай, һәм әҙәби телдәге һүҙҙәрҙә *с* өнө килгән позицияларҙа һөйләштә *щ* фонемаһы килә:

– һүҙ башында: *щөнки – сөнки, щатлы – сатлы, щыҡҡан – сыҡҡан, щит – сит, щөнки – сөнки, щабынныҡ – сабынлыҡ.*

– һүҙ уртаһында: *акща – акса, бещән – бесән, кещазна – касаҙна, эщәк – эсәк, кещерткән – кесерткән,нищә – нисә, өщен – өсөн;*

– һүҙ аҙағында: *ағащ – ағас, өщ – өс, пәрәмәщ – бәрәмәс.*

Һүҙ формалары яһалышы һәм һүҙ үҙгәреү процесында *щ – с* сиратлашыуы һаҡлана: *алтынщы – алтынсы, бишенще – бишенсе, килгәщ – килгәс, төшкәщ – төшкәс.*

Билдәләнгән өндәр сиратлашыуы һүҙьяһалыш өлкәһендә лә сағылыш таба: *башҡортща – башҡортса, жырткыщ – йырткыс, мауктырғыщ – мауыктырғыс, мөмкинщелек – мөмкинселек, колхозщы – колхозсы, хәйерще – хәйерсе.*

Бездә Фазыл заты тиләр инде, зат именно. Фазыл бабай булған, шуның балалары иң беренще күщеп килгән ауылға йегерме беренще йыл. Батшанан бүләккә бирелгән жирләр булған ул, шул бабай бай ғына знаменитый кеше булған, Фазыл ҡарт. Балаларын күщереп утыртҡан, Ғаббас, Ғаффас башта икесе күщеп утырған, шунан ауыл үсеп киткән.

Шишмәләр күп безнең ауылда. Хөрмәт шишмәсе тиләр ийе, Хөрмәт абый ҡараған инде. Салҡын шишмә.

Торна болон тип йөрөтәләр торналар төшә торған урын, шунан Ҡара зирек баш, болон исеме. Бодомбаш – Бодом йылғасының башы. Бодом йылғасы бар безнең, Щоҡор ауылына бара ул, Әригә ҡушыла, ул Бодом как раз Ауыҡта башланған.

Пошой, төлкө, ҡуйан, бүре, айыу да килеп щыҡҡылай, ҡабан дунғызлары, көртлөк, йыланнар бер нищә төрлө. Ҡара йылан, баҡыр йылан.

Бездә щабата йасайлар ийе суғыштан суңғы йылларда, щабата сатып көн күрәләр ийе, аҡща эшләйләр ийе шуның белән. Урман арасы булғащ, йүкә бар. Ҡап суғалар ийе, лента, аны ҡап тиләр. Лентаны щанаға салалар, шул лента өстөнә утырып йөрөйләр ийе. Шуларны саталар ийе. Шунан туғын бөгәләр ийе, тәгәрмәщ, арба тәгәрмәщләре. Ҡарамадан бөгәләр ийе аны. Щана башлары. Урманда ниндәй эш эшләйләр, шундай эшләр белән шөғөлләнгәннәр. Иң беренще пилорама кебек циркульный бездә барлыҡҡа килде, әле ул утызынщы йылларда.

Атай – әтәй, әсәй – инәй, өләсәй – ҡарт инәй, олатай – ҡарт әтәй, ағай – абый, ҡусты – энекәщ, кәләштең ҡустыһы – ҡәйнеш, кәләштең сеңлесе – ҡәйнегәщ, кәләштең ағасы – ҡайнаға. Ҡышҡы баш кейеме – бүрек, ҡышҡы айаҡ кейеме – кейездек (кейез итек), боз өстөндә ҡалҡҡан су – туш. Ат йәше – көлөкәй (йаңы тыуған), ҡолон, тай, ат, бейә, айғыр. Ат төсө: тимеркүк (ала), жирән, туры. Умартасылыҡҡа бәйле сүзләр: өрдөргөщ, стамеска, күзлек, күщ. Табан, щабаҡ, шүкә, шамбы, ҡара балыҡ, аҡ амур. Боярышник – ҡамыр жимеше, шиповник – гөлжимеш, малина – ҡура жиләге, земляника – жир жиләге, черемуха – шомырт, божья коровка – ҡызыл ҡорт, угол – пощмаҡ, мешок – ҡапщыҡ, хлеб – эпей, ведро – бидрә.

(Йомағужин Айҙар Ғариф улы яҙып алды).

## БҮЛ-ҠАЙПАН АУЫЛЫ

**Ғарифуллина Лифүзә Ғәндәлиф ҡыҙы, 1953 йылғы**

Ҡайпаннар арасында иң йәш ауыл безнеке, аңа бер мең жиде йөз житмеш өщенще – житмеш бишенще, сиксәненще йылларда нигез салынған булырға тейеш, щөнки Әсфәндийәров китабында бишенще ревизийада ғына аның исеме барлыҡҡа килә, ә аңа хәттек исеме булмаған. Безнең ауыл ике өлөштән тора: бер йаҡта башҡортлар йәшәй, икенще йаҡта мишәрләр йәшәй. Мишәрләр ҡайдандыр килгән кешеләр, килмешәкләр. Башҡортлар аларға жиргә рөхсәт биреп кереткәннәр дә, шулайттырып ауылда йәшәп киткәннәр. Ауылда ике зыйарат, бересендә башҡортлар, бөгөнге көнгә хәттек шулай, башҡортларны айырым күмәләр, мишәрләрне айырым күмәләр, ике зыйарат ауылда. Вахытында ике мәщет булған, бересе башҡорт мәщете, икенщесе мишәр мәщете булған. Дингә ҡаршы политика башланғащ, утызынщы йылларда башҡорт мәщетеннән мәктәп йасағаннар, ә мишәр мәщетенең манарасын кисеп, клуб йасағаннар.

Мишәрләр белән башҡортлар суғышып йәшәгәннәр. Хәзер андый суғышыу йуҡ инде, ну заманында суғышып йәшәгәннәр, ауыл уртасында ҡапҡа булған. Ауыл щитендә ике йаҡта да ҡапҡа булған, ауыл ҡапҡалары, ауыл уртасында ҡапҡа булған. Мишәрләрне үз йаҡларына щығармағаннар, ә башҡортлар хужа булып, мишәр йаҡҡа щығып йөрөгәннәр, даже ҡызларын да үзләренә ала алғаннар, но үзләренең ҡызларын мишәр йегетләренә кейәүгә бирмәгәннәр. Мына шулай йәшәгәннәр ун туғызынщы ғасырларда. Йегерменще ғасырларда андый нәрсәләр бөтә, но барыбер мына шул ғөрөф-ғәдәт заманынан килгән ғәдәт әле дә бар. Мишәрләрне мишәр зыйаратына күмәләр, башҡортларны башҡорт зыйаратына күмәләр, атамалар да: Мишәр басыуы тигән басыу бар, Салҡын шишмә, мишәр зыйараты, Мишәр ҡулы, мишәр ҡорт баҡщасы. Мишәрләр йәшәгән жирдәге исемнәргә шул мишәр сүзен ҡушҡаннар.

Минең үземнең әтәй башҡорт, ә инәй мишәр ҡызы. Инәйнең сөйләүе буйынща, мишәрләрнең килеше, Уразмәт тигән кеше килгән, уҡытыущы, мөғәллим булып, шунан безнең ауылға килгәщ, мәщеттә мөғәллим, мулла булып эшкә урыннашҡан инде. Шунан нәрсәгәдер шушы жирле халыҡ белән ызғыш килеп щыҡҡан да Уразмәтне ауылдан ҡуғаннар, Тәтешле районцентр безгә биш километр, шул Тәтешленең теге йағында, икеме-өщмө генә километр йыраҡлыҡта ул барып урыннашып, шунда балалары белән йортлар салып йәшәй башлаған. Шундағы жирле халыҡ Уразай килде тигәннәр, ә анда удмуртлар йәшәй, бөгөнге көндә дә. Шунан шушы ауылға исем бирелгән Уразгилде, Уразай килде, бөгөн дә ул ауыл бар. Зур матур удмурт ауылы, Уразгилде.

Ауылға йаҡын ғына Бәрмеш тигән урман бар. Шул Бәрмештән Бәрмеш тигән йылға башланып китә, ул Тәтешлегә таба аға. Ә мына быйаҡҡа Бодомбаш тигән урын бар безнеке. Бодомбашта жиләк жыйабыз, гөмбәләр күп, имәнлек, ҡайынлыҡ, бик матур урман инде. Шул Бодомбаштан Бодом йылғасы быйаҡҡа таба аға. Шунан

Әрибаш тигән урын бар, Әри йылғасы шунан башланып китә. Бүл-Ҡайпанның ауыл эщеннән аҡкан йылға Суйырым тип атала, сыу йырымы. Райондағы иң зур билдәле йылғалар безнең ауылдан башланып киткән: Әрибаш, Бодомбаш, Бәрмеш, ә ауылдағы Суйырым.

Шунан бездә урман күп булған бит инде, шул урманны тазартып сөрөнте жирләр йасағаннар иген игеү өщен, шуның өщен кем тазарткан, шул жирне күпщелек йандырып эшләгәннәр, ағащны төпләп йандырып эшләгәннәр, шуның өщен ул жирләрне көйөклек тип атайлар. Фәтҡулла көйөк, Әмерхан көйөк, Йосоп көйөк. Шул Фәтҡулла көйөк тигәне минең прадедушканың жире, бөгөнге көндә жиде-сигез гектарлы жир, бик матур ғына түгәрәк аланлы жирдә.

Шунан ащыу тип атайбыз, әрәмәле ащыу, әрәмә йуҡ жирдә, йылға, йә шишмә буйы, күпщелек ул туғайлар, анда көтөү йөрөй. Көтөүне ҡайда ҡыуабыз, ащыуға ҡыуабыз. Ул ауыл сайын бар. Щийәлетау бар, Щийәтау шишмәсе тигән жир бар. Шунан Батҡаҡсаз шишмәсе бар, анысы ауыл уртасында, мәктәп ҡырында. Жәй көнө әз генә йамғыр йауды исә, сазлыҡҡа әйләнә инде, шунда шишмә лә аға. Шунан Әсләмҡул, Ҡарағатлыҡул. Шунан Песоктау тигән тауыбыз бар, аннан песок щығаралар, бөгөнге көндә уже карйер, тауның ощлары бөткән инде. Бик матур, ҡыш көне бала-щағалар щана шыуарға баралар, ауылға жиде йөз-сигез йөз метр йыраҡлыҡта, ауылның иң зур точкасы. Ауылның эщендә Мәщеттау тигән тау бар, шул ауылны икегә бүлеп торған ҡапҡа Мәщеттау турысында булған. Башҡорт мәщете шул тау өстөндә утыра. Бөгөнге көндә дә йаңы мәщет Мәщеттау башында утыра.

Шунан ике ауыл йаҡын ғына, Йаңы Ҡайпан белән Бүл-Ҡайпан арасы ике генә километр. Ике арада Бүләктау йата инде. Безнеке ауыл Йаңы Ҡайпаннан күщенгән. Элек ололар бер ҡащан да Бүл-Ҡайпан тип сөйләшмәгәннәр, Бүләгарт тип сөйләшкәннәр, Бүләк арты ауылы. Шул бүләк подарок тигән сүздән алынмаған, ә бүленгән тигән сүздән алынған, бүлеп торған. Бу ауылның кешеләре жирләр ҡысығайа башлағащ, тау артына күщенеп йәшәй башлағаннар. Ауыл шулай барлыҡҡа килгән. Анан әкрен-әкрен Бүләгарт Бүл-Ҡайпанға әйләнеп киткән. Ауыллар арасында иң йәше булса да, иң зур ауылға әйләнеп киткән суңынан. Колхоз центры бездә, иң зур мәктәп Бүл-Ҡайпанда булған, ауыл мәдәнийәт йорто тағын бездә булған.

Ҡаз, үрдәк ҡарағаннар, сарыҡларны күпләп ҡарағаннар, оло терлеклер ҡарағаннар. Шул игенщелек, малщылыҡ белән шөғөлләнгәннәр. Безнең йаҡта йүкә урманнары күп бит инде, шуның өщен йүкәнең корасын алып, сыуға салып, йүкә төшөргәннәр дә, шунан щабата да үргәннәр, баулар ишкәннәр, ҡапщыҡ кебек нәрсәләр эшләгәннәр. Урманнарда кейек атҡаннар бит инде, аущылар йәшәгәннәр, ауылда бик күп кеше аущы булған. Ҡыш көнө аущылыҡ белән шөғөлләнгәннәр, ауға айлар буйына щығып киткәннәр. Бүре ауларға Борай, Щурай йаҡларына хәттек барып житкәннәр.

Шурпа пешергәннәр, шурпаға төрлө ит салырға тырышҡаннар: ҡаз, ат ите, сыйыр ите. Сарыҡ итен жәй ашағаннар, жәй көнө суйғаннар сарыҡны, ҡыш көнө сарыҡ ашамасҡа тырышҡаннар. Шунан бәлеш ҡуйғаннар, бәлеш малның эщәкләренән эшләнгән. Эщәкне бик йаратып ашағаннардыр инде, мына Татарийада эщәк ашау йуҡ, ә бездә мына эщәк ашайлар. Балан бәлеше салғаннар, анысы сладкий бәлеш булып исәпләнгән, бал белән сыйыҡлап эшләгәннәр. Бәлештән суң ит щығарғаннар. Итне төрлө пешкән йәшелщәләр белән бизәп щығарғаннар: бәрәнге, кишер, шалҡан, тощторма, кәбестә. Анан инде щәй. Щәй ҡырына бауырсаҡ пешергәннәр, жиләкле май йасағаннар, ҡызыл эремщек йасағаннар, бал, кәрәзле бал ҡуйғаннар.

Эщәктән бәлеш салғаннар. Аны ҡунаҡ килгәнще ҡыш көнө йамап туңдырып жыйғаннар бәлешне тышта. Ҡыш көнө йасап туңдырып ҡуйғаннар, туңдырғащ тыщҡан кергән тегенең эщенә. Шунан тыщҡанны килеш керткәннәр дә, ҡунаҡлар алдына эретеп утыртҡаннар. Шунан бересенең ауызына эләккән: “Щыҡылдамаҡ ийе, барыбер ашим тигәщ, ашим!” тип ашай ти инде теге мишәр бәлешне.

Сауыт-сабалар күпщелек безнең йаҡта элек-электән йандырып эшләнгән ҡызыл балщыҡтан щүлмәкләр булған. Щүлмәк, ҡоштабаҡ. Мин бәләкий щаҡта ҡартыйлар, жәй көнө холодильник йуҡ ищ инде, ҡар тутыралар ҡарбазға. Ҡарбазға ҡар тутыралар да өстөнә ҡалын итеп салам салалар, салам өстөнә айыртылған ҡаймаҡ, ҡатыҡ, сөт, ҡоротларны шул щүлмәкләргә тутырып тегендә ҡар эщенә тығалар ийе. Жәйпеш, щынайаҡ икесе бергә – тустаҡ. Щәйнүк, самауар, бал ҡалаҡ, аш ҡалағы, аш щүмещ (половник), щүмещ (ковш), гөлмищ (мейес артындағы жир), ҡашийаҡ (йыуа торған сауыт-саба урыны), кәжүнкә (әйбер саҡлай торған жир), күтәрмас (ишек алдының асты).

Нуртдинов Раул абый, минең туғаным, өщ туғанбыз. Бик күп архивларда булған да, безнең нәселнең гәйнә башҡортлары йағынан килгәнен белгәннәр. Минән сорадылар исә син кем тип, мин туп-тулы иттереп башҡортмон тип әйтә алам. Йәһутди, Шәрифҡол, Әмир тигәнне мең сигез йөз ун икенще йылны быйаҡҡа Ҡайпан жиренә китереп утыртҡаннар, утыз биш ғайләне китереп утыртҡаннар, шунан Ғөмәр, Әхтәметдин, Фәтҡулла. Фәтҡулла тигәне, Әхтәметдинов Фәтҡулла булған, ул Тәтешле волыстеның старшинасы булып торған, аны удмуртлар ағыулап үтергәннәр мең туғыз йөз жиденще йылны. Шунан минең ҡартәтәй Ғарифулла, анан минең әтәй Ғәндәлиф. Нуртдинов Рауил абый шушы шәжәрәне бирде инде миңә.

(Йомағужин Айҙар Ғариф улы яҙып алды).

**Ситдиҡов Фиҙәрис Хөсәйен улы, 1947 йылғы**

Мин Бүл-Ҡайпан ауылында тыудым. Шунда сигез класны бөтердем, шуннан Аҡсәйет мәктәвендә ун беренще класны бөтердем. Аннан Дуван ауыл хужалығы техникумында уҡыдым, армийадан ҡайтҡащ инде, агроном буйынща. Уҡыуны бөтергәщ, алтмыш өщөнщө йылдан алтмыш алтыға тиклем завклуб булып эшләдем, шуннан армийаға киттем, анда ул вахытта өщ йыл ийе, армийаға барғащ, ике йылға әйләнде бит инде,

шуннан мин ике йыл да ике ай йарым хезмәт итеп, алтмыш туғызынщы йылның йанварь айында ҡайттым. Шуннан ҡайтҡащ, мине комсомол секретаре итеп сайлап ҡуйдылар колхозға, партийаға алдылар, завпарткабинетом итеп ҡуйдылар, шуннан партком председателе булып эшләдем, аннан соң сиксән беренще йылны фермаға завферма итеп ҡуйдылар. Бик ауыр заманнар ийе колхозда, шул вахытта мин өщ йыл эшләп алдым, шуннан сиксән дүртенще йылны партком секретаре итеп сайлап ҡуйдылар, колхоз айырылды ул вахытта безнең, икегә бүленде: Ленин колхозына, Салауат колхозына, аннан сиксән дүртенще йылдан башлап партийа бөткәнще, жиде йыл эшләдем. Ике меңенще йылда килдем мында райцентрға эщкә, коммунальное хозяйствоға. Анда эшләп, пенсийаға щыҡтым. Хәзерге вахытта әби белән икәү йәшәп йатавыз, ике бала үстерәвез, алар айырымнар.

Бул-Ҡайпан ауылының исеме аның, мин белеүемщә, безнең ике ауыл арасында, менә әле ике оло йул үтә, Куйада тигән Пермский обласҡа барабыз, шул Аҡсәйет ауылына барғанда тау бар, Бүләктау, Ҡайпан жийыны тигәннәр, ана шул йағы безнең Бүл-Ҡайпан ауылы. Шул Бүләк арты тауы тип йөрөткәннәр аны башта, хәзер ҡысҡартылып Бүл-Ҡайпанға әйләнгән. Электән Бүләк тауының бер йағы Йаңа Ҡайпан, бер йағы Бүл-Ҡайпан булып тора шул тауда.

Безнең Бодомбаш тигән жир бар, бәләкәй болоннар бар ийе, электән пещән щабалар ийе. Усаҡлыҡ тиләр ийе, усаҡлар үсә ийе анда барсаң. Майлы ҡул тигән жир бар, берәү пещән щабарға барған да, мыңа өйөннән май апкилгәннәр күпмедер өлөщ, шул нийә әз генә май апкилдегез тип шул майды бәреп тапалаған шул урында, шуннан ҡалған. Борсоҡ тау бар ийе, шунда без жиләк жийырга йөрөй торған ийек, шул зурнәйләргә ийәреп. Анда бик матур пещәнлекләр бар ийе, шунда ауыл халҡы, колхоз жийылып пещән щабалар ийе көннәп-көннәп, аш-сулар пешереп, гармуннар уйнатып, шулай тип зурлап эшләйләр ийе өмәләрне. Ауылның уртасында Мәщеттау бар, элек тә мәщет булған анда, революцийанан соң шул мәсетне кискәннәр, әле йаңадан мәщет төзеп ҡуйдылар анда, бер жигерме йыл тирәсе хәзер була. Мәщеттауда бөтен ауыл халҡы, балалар жийылып сана шыуа торған ийек электән. Шишмәтау тийдер ийек, бына үзебезнең ощта ийе, анда түбәндә шишмә бар ийе бик тәмле сулы, шишмәсе бар әле дә. Бодом тигән йылға бар, шул болоннан щыҡты микән ул.

Атлар тоталар ийе, хәр ауылда конюхлар бар ийе, хәзер бер генә ауылда бар, менә Йаңа Ҡайпан тигән ауылда ғына ҡалды атлар.

Бездә менә мийещ артын “гөлмеш” тиләр. Гөл кебек булған, менә без дә гөлмеш тибез, менә минем хатын Ҡащаҡтан, анда “щараща”тиләр, без “монща щоланы”тибез. Тағы “кәберткә” тиләр. Менә бездә “щәйнүк” элек “щурнай”тийдер ийек, мийещ алдына ҡуйғащ, ут белән ҡарайғандыр инде ул, шуға щерныйдан әйләнгәндер, ахыры. Монщала жыуына торғанны “шырамта” тибез. Суға салып, мунщала йасап, жүкәдән эшләнә бит инде. “Жәйпещ”тибез блюдцены, щоланны “кәжүнкә” тибез, “күбәтә” – аш сала торған тәрилкәләр.

Менә хәзерге вахытта иван-чай жийавыз, үзебез жийавыз, үзебез щәйен эсәбез өйдә. Мәтрүшкә жийавыз, ҡызыл клевер жийавыз дарыуға. Щалғы тибез, тырма, сәнәк. Ҡаты ҡорт бар, ҡара, бер төрлө бәләкәй тараҡан кебек. Ҡарт алаша – оло атны әйтәләр. Ҡаз пипийе, үрдәк пипийе тибез. Нәрсә тимәйбез, нәмә тибез.

(Зөбәйерова Ҡәҙриә Хөрмәт ҡыҙы яҙып алды).

## ГӘРӘБАШ АУЫЛЫ

**Ғайсин Инзәлиф Хәлил улы, 1951 йылғы**

Мин мында, Тәтешле районында Гәрәбаш исемле ауылда, тыуып үстем. Сигезенще класка хәтлем унда укыдым, ә унынщы класка Тәтешлегә килдем укырга. Әти минең башҡорт тип йазылган, Оренбург обласенән, ләкин телен татар тип йаззырткан. Гәрәбаш ауылы – Гәрә исемле йылга бар анда, йылга башлана, щоның ощен исеме лә Гәрәбаш тип аталган. Ауылга заманында удмуртлар килеп урыннашкан, мең туғыз йөз туксанынщы йылдан алып нищектер әйләнгән ул татар ауылына. Мин укыган идем анда татар теле, татарща укып бөттек без мәктәптә. Ауыл бик зур ийе ул заманында, анда бер өс йөзләп хужалыҡ бар ийе, ә хәзер әз инде, балалар да йук инде зур мәктәптә, мәктәп буш, күрше ауылга йөрийләр барсы да. Былтыр, йегерменще йылны, ун сигез кеше үлгән, бер бала тумаган, ауыл бөтеп бара. Шундый зур ауыл ийе, һәр класс йегермешәр, утызар бала укый идек. Ауыл мең туғыз йөз ете йөзөнще йыллар тирәсендә барлыкка килгән. Бер мең туғыз йөз алтмыш жиденще йылдан эшкә щыгып киткән ийем, анан суң ауылга кайтып-китеп кенә йөрөдөм инде.

Ауылда Ҡалмыйатау бар ийе, Йейәнщектау бар ийе. Шундый бер-ике генә тау ийе инде, ауыл урман ҡырында ғына тора. Йейәнщектау йәнщелгән кебек тау иде, хәзер бөтерелгән, трактор белән тигезләп куйдылар бит инде, әкренләп кенә барсын да йукка щыгаралар инде, басуларны бөтерәләр. Басулар йасаганнар ийе, хәзер алар да бөтеп бара инде, әле инде эшщеләр бар, фермалар эшли. Президент килеп йөрөгән иде, халыкны бик матур тип әйтеп йул йасаттырды, шундый халык эшщән тийеп. Ауылда умартащылар күпләр.

Сөйләшү безнең шул бер төсле инде, бөтен Тәтешле районы белән, барыбыз да берсә сөйләшәбез. Әти, әни, әнкәй, инәкәй, әткәй, абый, апа, энекәш тип әйтәбез. Уктучыларга “абый” тип өндәшә ийек. Ҡустым – дустым була. “Икмәк”не бездә “әпи” тиләр, “прокурор”ны “пракарул”.

Үзем Себердә эшләп кайттым, утыз жиде йыл Себердә, Нижневартовск йагында. Күп кешеләр белән күрештек инде, башҡортлар, татарлар без бергә йәшәйдер ийек заманында, әле лә бергә йәшәйбез инде. Татар-башҡорт ойошмалары күпләр анда. Мәсәлән, безнең бар ийе “Курай” жәмгийәте. Уральский лесотехнический институтны бөттем мин. Лесозаготовитель, нефтяникларга урман кисәдер ийек инде йулны ащар ощен.

(Зөбәйерова Ҡәҙриә Хөрмәт ҡыҙы яҙып алды).

**Ҡарабаева Резида Хәким ҡыҙы, 1966 йылғы**

Гәрәбаш ауылында туып үсеп, шунда үз ауылымда әлегә ҡәдәр йәшәп йатабыз. Мең дә туғыз йөз сиксән өщөнщө йылны урта мәктәпне бөттөм. Урта мәктәпне Шулған ауылында бөттөк, безнең сигез йыллыҡ тип атала иде ул вахытта. Анан суң Щаллы педагогийа училищесына уҡырға кердем, аннары заочно уҡып бөтерергә тура килде. Шулай итеп, мин мең дә туғыз йөз сиксән дүртенще йылны үзебезнең сигез йыллыҡ мәктәпкә эшкә урынлаштым. Анда рус теле уҡыттым, анан географийа белән төптән киттем. Башҡорт дәүләт университетында географийа факультетын тамамладым. Шулай итеп, географийа уҡыттым ауылда, ике мең ун икенще йылда английский уҡыттым, английскийға переподготовка үтеп, инглиз телен уҡыттым ауылда да. Әлеге вахытта Шулған урта мәктәбендә эшләйем. Үзебезнең мәктәп бөткәщ, бу мәктәпкә эшкә килдек, күщтек. Балалар да килде, үзебез дә эшкә килдек. Шулай итеп, бу мәктәптә әлеге көндә эшләп йөрейем. Крайны өйрәнеү бәләкәй щаҡтан уҡ булды, бәләкәй щаҡтан уҡ ҡызыҡсына ийем, әнкәй белән урманға йөрергә йаратадыр ийем. Безнең ауыл урман буйында, Гәрә буйында. Мына ауылның да исемен әйтеп китәм Гәрәбаш. Ул Гәрә йылғасының башында урынлашҡан, шуның өщен аны Гәрәбаш тип атағаннар. Ҡайан килгән суң бу гәрә тигән сүз? Бу Гәрәй тигән кешенең, ул жир биләүще булған, аның жирлекләре булған безнең йаҡта. Шулай итеп, безнең ауылға Гәрәбаш тигән исем биргәннәр инде. Башта ауыл төрле жирдә салынған, Байсит, Йансит тигән кешеләр килеп, Туҡмырзалар килгәннер инде. Алар шулай салып киткән. Шулай итеп, ауыл Гәрәй йылғасынын уң йағында, сул йағында булған, әлеге вахытта Гәрәй йылғасының сул йағында йәшәп йатабыз.

Безнең ауыл ҡатнаш ауыл тип әйтергә кирәк. Төп удмуртлар булған, башҡортлар, татарлар тибез инде, шулар ҡатнашып киткән ауылда. Мына зурнәйем, әнкәйемнең инәсе, Ҡушаш тигән ауылныҡы булған, Ҡалтасы районы. Әнкәй әйтәдер ийе, мин бәләкәйрәк инем ул вахытта, аңлап житә алмағанмын: “Без башҡортбыз”, – тип әйтәдер ийе инәй, тип әнкәй сөйләйдер ийе. Действительно, зурнәйнең щын башҡортларның национальный кийемнәре бар ийе, ул бай ҡызы булған, шундый матур национальный костюмнары бар ийе, ул бөгөнге көнгә ҡәдәр саҡланмаған. Апа үзэшщәннәргә эйәреп, концерт ҡуйып, шулай тип оло апам аны жуғалтҡан. Бөтен кийемнәре бар ийе инде. Шул удмуртлар әйтәләр инде, ололар безнең ауыл аша әбей патша йулы үткән тип, Екатеринаның йулы үткән, тиләр, аны ололар, шунан үткән, мына шулай үткән, тиләр. Ул, моғайын, шул Екатеринаның йулы үткән өщен дә салынғандыр, йул ҡараущылар булған анда, шул күперне саҡлап, күперне ремонтлап торған Гәрәй исемле кеше тигән факт та бар ул бездә. Шуның исеме белән дә алынған, тиләр инде. Шунан Шулғаннан килгән Ҡазанбайның улы безнең Гәрәбашта шушы йул саҡлау өщен малайын шунда урынлаштырған булған. Шунан суң мына аның Ҡазанбай чоҡоро тигән чоҡоро бар шушы урман эщендә, Ҡозаш тигән ауылға безгә турыдан щығарға була, анан бәләкәй щаҡта йөрейдер ийек, мин ул чоҡорно күргәнем дә бар. Әнкәйдән сораша торған ийем инде, гел жәйәү йөрейдер ийек без әнкәй белән, мин бәләкәй щаҡтан уҡ эйәреп йөрей ийем әнкәй артынан, томонимиканы шунда сорашадыр ийем, бөтә нәрсәне сөйләп торадыр ийе ул. Шулай итеп, шунда уны үтергәннәр, бу Ҡазанбайны шушы чоҡорда, әнкәй сөйләйдер ийе инде, әнкәй әйтәдер ийе, инәй сөйләй тип, әнкәйнең инәсенән тороп ҡалған бу сүзләр. Зурнәй ул мең дә сигез йөз туҡсаннар тирәсе булған, оло кеше булған инде. Мына шулай итеп ауылнын тарихында инде удмуртлар, башҡортлар, татарлармы тийәйем инде, шулай тип ҡатнашып киткәннәр инде. Телдә безнең әзрәк ҡай бер сүзләр удмурт сүзләре дә килеп щыҡҡылай, буғай, но күберәк башҡортщараҡ сөйләшәбез. Ти, бармай, ҡайтмай – алар инде безнең башҡорт сүзләре. Мәктәптә эшләгәщ, үзем кещкенә музей да барлыҡҡа килтергәйнем, шунан тарих, крайны өйрәнеү түгәрәге эшләп килде, балалар белән эшләдек, уҡыущылар белән, үзебезнең ауыл уҡыущылары белән, шунда дәресләрне дә үткәрәдер ийем, аларға бик ҡызыҡлы була торған ийе. Шунан төрлө конкурсларда, район конкурсларында балалар эзләнү эшләре алып барды, шунда ҡатнашып, тоже урыннар аладыр ийек, балаларда шулай ҡызыҡсыныу бик булды инде. Шунан бу мәктәпкә күщкәщ, туҡталып китте бу эшем, но халыҡ алдында инде әлеге вахытта, шәжәрә бәйрәмнәре булса инде, анда эшләйбез инде, анда ҡатнашам. Минең әлеге вахытта бианам (иремнең әнисе), утызынщы йылғы, унда бик күп информацийа. Әнкәйнең инәсе – зурнәй. Апа, абый – сестра, брат. Бәләкәйрәк апай, апаҡай, сеңлекәш.

Бөгөнгөсе көндә Гәрәбаш ауылы зур ауыллардан щутлана районда. Шул малщылыҡ белән шөғөлләнәләр, умартащылыҡ белән шөғөлләнәләр, без үзебез дә умартащылыҡ белән шөғөлләнәбез. Ирем бик күп йыллар умартащы булып эшләде, мына минең зурәтәйләр умартащы булғаннар төптән. Минең зурәтәй Тимербай исемле булған, атлар ҡараған. Бер бабай әйтәдер ийе инде ауылда, мына Тимербай абзыйның атларын суғышҡа алып китteләр тип, атлар күп ҡараған ул и умартащылыҡ белән, ҡорт тотҡан инде ул. Бездә умарта тотабыз тимәйбез, ҡорт тотабыз тип сөйләшәбез. Инструментларны өрдөргөщтө инде дөмәр тибез, аларны русча ҡатыш әйтәбез, умарта инде, рамнар, кәрәз барыбер, сикәсе тибез балның, перга ул.

Мына безнең ауыл күберәк шәнгә пешергән – шанежки, шунан тәйикмәк тибез, ҡалын итеп, тәмле итеп тәйикмәк пешергәннәр, бәләкәйе ҡоймаҡ, ҡыстыбый инде, талҡан, баурсаҡ, төш тиләр, төрлө пироглар, төрмә тиләр ийе, бәрәнге төрмәсе, ҡызыл щөгөлдөр төрмәсе. Сөт ризыҡларынан шул ҡатыҡлар эшләгәннәр инде электән, ҡорот бездә бик эшләү булмаған микән, ҡызыл эремщек эшләү. Гөмбә, мәшкә тиләр. Гөрөждә тибез, әтәщ гөмбәсе дә тиләр, ана шул сухие грузди, майлы гөмбә тибез, волнушки жыйалар ийе элек әнкәйләр, шунан ҡайын гөмбәсе тидер ийек без. Ауыл арасында да айырма бар. Безнең ауылда өщ төрле сөйләшәбез, интонацийа тоже айырыла. Бездә ти, ищ бар, бит урынына ищ ҡуйабыз.

(Ҡотлоәхмәтова Эльнара Рафиҡ ҡыҙы яҙып алды).

## ИҪКЕ КҮРҘЕМ АУЫЛЫ

### Атнабаев Мәғдән Ҡасим улы, 1932 йылғы

Тәтешле районының Иске Күрдем ауылында тыуып үскәнмен. Мең дә сигез йөз дә утыз өщенще йылны Иске Щокор ауылынан бабайлар ҡара урман эсендә йалан күргәндәр дә ҡайтып: “Урман эщендә йалан күрдек, шушында кущеп утырайыҡ!” – дигәннәр. Иң беренще исеме Йалан Күрдем булған, ана тора бара Күрдем булған, шунан бер Йаңы Күрдем барлыҡҡа килгән. Мынысы Иске Күрдем, тегесе Йаңы Күрдем булып киткән. Алары бергә ҡушылғащ, Иске Күрдем тороп ҡалды.

Әтийебез Атнабайев Касим суғыш вахытында вафат булды. Әтейдән сигез бала тороп ҡалдыҡ. Дәү әтийебез Дәүләтхужа беренщеләрдән булып Чокор ауылынан кущеп килгән кеше булған. Чокор ауылы бу Ғәли Чокоройдың туған ауылы. Анардан ун ике-ун өщләп ауыл кущеп щыҡҡан, элек ауыллардан кущеп щыға торған ғәдәт булған инде. Иске Чокор ауылынан кущеп щыгып, шунда килеп утырғандар. Мең дә сигез йөз дә утыз өщенще – утыз бишенще йылларда Күрдем ауылы зурайа башлаған. Әммә ләкин мең дә сигез йөз дә сиксән тугызынщы йылға щаҡлы Күрдем ауылында мәщет тә булмаған. Туған балаларны да, никахларды ла теркәргә, үлгән мосолман ҡәрзәштәребезне жирләргә, теркәргә мөмкинщелек булмаған. Бар да Чокор ауылында булған. Әтисе вафат булгащ, Ғәли Чокоройныкы кеще улы Ғәрифулла Кейеков Күрдем ауылына кущеп килә. Мең дә сигез йөз дә сиксән тугызынщы йылны шунда мәщет төзеп, үзе имам булып, Күрдем ауылында хезмәт итә. Ғәли Чокорой – Башҡортостанда, ошо тирә-йаҡҡа даны таралған данлыҡлы шәхес. Аның кеще улы әтисенең эшен дауам иттереүще, инде алып барыущы Ғарифулла Кейеков була. Ул да шағир, мәғрифәтще шағир була. Имам ахун була, зур дәрәжәлә. Әммә ләкин мең дә тугыз йөз дә ун сигезенще йылны революцийа вахытында Ғарифулла Кейековны үз йортонда щапҡылап үтерәләр. Шул вахыттан суң ауылыбызда мәщетләр ащыу тыйыла бит инде. Мәщетләрне бөтөрәләр. Әммә ләкин ауылыбызда, мең тугыз йөз туксан жиденще йылны нигез салынып, ике мең дә өщенще йылны мәщет асылды. Аның башынан азағына хәтле миңә йөрөргә насип булды. Бары, ул мәрхүм инде, Әбулкарам Ҡасим бабай белән икәүләп мәщет төзөдөк. Һәм Ғарифулла Кейековның мәщет урынында мәщет төзөдөк. Мәщетебез бөгөнгө көндә эшләп килә.

Безнең ғайлә мәсьәләсенә килгәндә, өлкән абыйым Әнғәм Атнабайев – Башҡортостандың халыҡ йазыущысы. Данлыҡлы шәхес. Без аның белән ғорурланабыз. Тәтешле районы абыйым исемендә, Атнабайев исемендә премийа булдырды. Беренщеләрдән булып сеңлемАтнабайева Зинира Касим ҡызына бу бүләк бирелде, премийа. Бик күп кенә кешегә премийа бирелде. Абыйым туксан туғызынщы йылны вафат булды. Аның Күрдем ауылында һәм районда шәхси музейы булдырылды. Ауылыбыздың уҡытыущысы Фидалийа Хабийевна бына безнең алдыбызда утыра. Бик зур рәхмәтлебез ғайлә исеменән дә, бөтен туғаннар исеменән дә, щөнки Атнабай музейын Күрдемдә булдырыуга ифрат көщ салды. Бу музейға мин дә ҡулымдан килгән щаҡта йардам иттем, эле дә йардәм итеп киләм. Шәжәрәбезне төзөп ҡуйдыҡ, аллаға шөкер. Атнабайев шәжәрәсен дә төзөп ҡуйдыҡ. Бына шулай итеп Күрдем ауылы, Тәтешле районы үзенең уллары, ҡызлары белән, данлыҡлы шәхесләре белән ғорурлана, маҡтана, маҡтала. Атнабайев премийасы хәзер Башҡортостанда түгел, тирә-йаҡҡа таралды. Бына бөгөнге көндө йылның йылында Күрдем ауылында, Атнабайевтың туған ауылында, шиғриәт фестивале була. Шунда йәшләребез, балаларыбыз шиғриәт сөйгән, йараткан кешеләр үзләре йатлаған шиғырларын сөйләп, гран-прилар йаулап, балаларыбыз урындар биреп, бик матур фестиваль үтә. Һәм шушында инде премийалар бирәләр йылның йылында. Ике мең ун беренще йылны миңә лә премийа бирелде, аллаға шөкер. Бына күкрәгемдә аның билгесе тора. Бу бына быйылғысы йылға премийаға, әле шутлап утырдыҡ, алты-жиде кеше бер урынға тәҡдим ителгән. Аны бит барсына биреп бөтөреп булмай, шулар арасына кемгәлер, бынамын дигәненә сайлап бирергә кирәк. Бәлки ике кешегә биреп ҡуйырлар.

Районыбызға килгәндә, ауылыбызға килгәндә, мин ғорурланам, ғөмер-ғөмер шушында тыуып үскәнмен, шушында эшләнем. Ауыл халҡы белән ғорурланам, мәктәбем белән ғорурланам. Шунан тыуып үсеп щыҡҡан шәхесләрем белән ғорурланам, районыбыздан щыҡҡан Хәниә Фәрхи, Салауат Фәтхетдинов, Әнғәм Атнабайев, Зинира Атнабайева кеүек шәхесләр белән маҡтанабыз.

(Саньярова Рәмилә Рәмил ҡыҙы яҙып алды).

### Мостафина Фидалиә Хәби ҡыҙы, 1947 йылғы

Мин щыгышым белән Аҡсәйет ауылынанмын, шушы уҡ районныкы. Күрдемдә бына ҡырҡ тугыз йыл йәшим. Үзем Ҡазан дәүләт педагогийа институтын тамамладым. Татар теле һәм әдәбийәте факультетын. Шушы Күрдем урта мәктәбендә гомерем буйы минең эпийем – татар теле һәм әдәбийәтен балаларға уҡытыу булды. Ҡазанда уҡыған вахытта уҡытыущыбыз әйтә торған иде: “Сез Башкирийаның төнйағынан килдегезме?”. “Әйе, без төнйаҡтан килдек”. “Ҡазанға салып ҡайнатырға кирәк әле сезне татар йасар өщен әле”. Щынлап та, без саф татарща сөйләшергә белмейбез. Мына безнең мындағы диалект. Татарларның сөйләүе белән безнең Күрдем халҡынын сөйләме арасында жир белән күк арасы. Эйе.

Мына минең кулымда Ғәли Щокоройның улы Ғәрифулла Кейеков турындагы мәғлүмәтләр. Ул “Урман башҡортлары” дип йазған мына шушы “Хәҙрәт шишмәсе йәки Күрдем шишмәсе” дигән китабында. Мына шул китап щыҡты. Эйе, щынлап та, безнең Күрдемгә Иске Щокор ауылынан килгән халыҡ. Без Гәрә башҡортларына керсәк тә, без Гәрә башҡортлары түгелбез, былай ғына әйткәндә. Без Ирәкте ырыуы башҡортлары, халҡыбыҙ ирәкте ырыуынан килгән. Ә жирләр Гәрәнеке булыу сәбәпле, без Гәрә ырыуы

башҡортларына кергәнбез. Безнең жирләр электән былай булмаған, урманнар булғаннар. Ҡара урманнар арасына килеп халыҡ урынлашып, урман кисеп, ҡортщолоҡ белән шөғөлләнеп, анан игенщелек белән шөғөлләнеп, малщылыҡ белән шөғөлләнә башлый халыҡ. Шулай итеп донйа ҡороп киткәнләр. Мына без Ҡазан педагогийа институтында уҡығанда ла тарихҡа басым йасап күп өйрәндек. Без телебезне, ғөрөф-ғәзәтләребезне, мәдәнийәтебезне белергә тейешбез. Әгәр без бына шушыны белсәк, төнйаҡ башҡортлары – Ғәли Щокорой нәселе башҡортлары – үзебезнең тарихыбызны, үзебезнең телебезне – башҡорт телен саклап ҡалыр идек. Безнең щынлап диалект бик үзенщәлекле: бармайым, ҡайтмайым, килмәйем, әйтмәйем. Без саф татарща сөйләшә белмейбез. Мин татар телен уҡытсам да, бер үк вахытта мин алып бардым өстәмә дәресләр. Факультатив дәресләр бирәләр иде башҡорт телен үзләштерергә. Шунан факультатив дәресләрдә башҡорт телен балаларға сөйләй торған идем. Шунан Башҡортостан мәдәнийәте, әдәбийәте һәм тарихы махсус уҡытылды мәктәптә. Дәрес бөтер алдынан күпмедер вахыт ҡала. Мин былай да йазыущыларның ижад йемешләрен күп белә идем, күп житкерә идем балаларға. Дәрес бөтер алдынан бына, балалар, Мостай Кәримдең бына шушындай китабы щыҡҡан. Үзенщәлекле әсәр – уҡығыз, безнең китапханага шушы ҡайтты. Дәрес бөтер алдынан кимендә биш минут ҡала мин балаларга йаңы щыҡҡан башҡорт йазыущыларының китаплары турында житкерә идем.

Мында үзенщәлекле, эшсөйәр халыҡ йәши. Ике мең алтынщы йылны “Ауылым тарихы – халҡым йазмышы” дигән китап щыгардым. Мин үзем хәбәрще дә, ауыл хәбәрщесе. Әле “Тәтешле хәбәрләре” гәзитендә житмеш биш йыллыҡҡа бағышланған конкурс ойошторолдо. Халыҡның батырлығын тасуирлап күп әсәрләр йаздыҡ, проза әсәрләре, шиғырлар да щыҡты ул. Мына шушы конкурста мин икенще урынды алдым. Халҡыбызның үткән хәл-ваҡиғаларын, тарихи фактларны тасуирлап “Без – утлы йыллар балалары” дигән темаға мин беренщесен йаздым, ә икенщесен “Йаралы салдатлар”, щөнки безнең коллективта, уҡытыущылар коллективында сугыш ветераннары ифрат та күпләр иде. Бына миңә алар белән бергә эшләргә тура килде. Хәзер безнең ветераннар бөтте. Ауыл советы территорийасында да, мәктәптә дә бер сугыш ветераны да ҡалмады. Тыл батырлары әле бар әле. Йегерме биш кеше.

Зыйарат йанында ауылның көнщығышы өлөшендә Баутдин тауы бар. Үзенең матурлығы белән ул күпләрне җәлеп итә. Бында наратлар үсә, жиләкләр ҡызарып бешә. Баутдин бабайға жирләрне шушынан бирәләр. Тау итәгендәге шишмәсе дә һаман ауылдашларны тәмле суы белән сыйлый. Бына шушы шишмәне хезмәт ветераны Фирдинант Нурмухаметов ҡарап тора бөгөнге көндә.

Бына Тегермән быуасы булған. Ул быуа хәзер йуҡ инде. Ләкин анда аҡҡошлар килә иде, ҡазлар килә иде, ҡыр ҡазлары, ҡыр урдәкләре килә иде. Быуаның суы бысрагащ, аның йанында булды ферманыкы сыйыр утары. Шунан аны быуып жибәрделәр дә, бына эшкыуар Ибатуллин Камил Тәтешленеке шушы быуаны ҡабаттан йаңартып эшләп йата бөгөнге көнне. Ҡабаттан йаңартып, йаз көнө аны әйбәтләп, тәртипләп, матур итеп эшләйәщәкләр. Шушы быуаға ҡойа инде безнең шишмә сулары. Шишмә сулары шунда жыйыла-жыйыла Әри йылғасына ҡушыла.“Әри буйы кищен-иртән томанлы була икән, бик сағынсаң, бик саргайсаң, Әри буйына кил, иркәм” – дип Фәридә Ҡудашева жырлый торған иде, безнең халыҡ артискасы. Шулай иттереп, безнең шушы Күрдем сулары Идел йылгасына барып ҡушыла. Бына без шундай төбәктә йәшәйбез. Безнең мында шишмәләр ифрат та күп. Халыҡ аларны ҡарый, саклый.

Көнкүреш атамалары: табак (ләгән), тобагащ, кәсәү, соскы, тустаган, йомыры, самауар, щәйнүк, комган, күмер щүлмәк, киле, шырамта, минлек (идән себерер өщен), бизмәк, өстәл, сике, тоба, тоштабак, тәмәке, түшәк – йастык, ашйаулык, бишек, галош, щабата.

Сугыш щагындагы аш-суга бәйле сүзләр: умащ, кещерткән ашы, щерек бәрәңге күмәще, кәлжәмә, бәрәңге, кишер щәйе, алабута күмәще, щүген йаргыщ, кузгалак, көпшә, какы, жөнлекәй, бал, тары йарма, шомырт, балан, миләш, жиләк, он, көнбагыш, бавырсак, бәлеш. Болар, үләннәр дә халыкны ащтан алып кала.

(Саньярова Рәмилә Рәмил ҡыҙы яҙып алды).

**Әхмәтйәнова Альбина Нәзиф ҡыҙы, 1970 йылғы**

Мин китапхана техникумында уҡыдым, сиксән икенще йылны мәктәпне бөттем. Шунан сиксән туғыздан башлап, шушы район китапханасында хезмәт итәм. Бер улым бар – Арыслан. Иске Күрзем ауылы. Мин ишетеүемщә, безнең мында урман булған, шул урманда килеп, берсе урын тапҡан да ҡыщҡырған, ти: “Менә күрдем, буш урын күрдем”. Ана шунан.

Күрдемдә Жидекүзле чишмә бар. Ул данлыҡлы Әтнабай чишмәсе тиләр инде. Хәзрәт чишмәсе тип ҡулланалар. Суы аға торбадан, Жиде күзле торбадан, һәр берсе исемле, Мөхәббәт берсе.

Без пешерәбез баурсаҡ, шәнгә. Шәнгәгә салабыз бәрәнге, безнең Тәтешле шунын белән данлана, Тәтешле шәнгәсе тиләр бездә, өстөнә шуның йоморҡа йағалар. Беренще ҡамыр, ҡамыр өстөнә пешкән бәрәнге боламығы, өстөнә йоморҡа йағалар, пешкәщ, шәнгә дип атала инде ул. Тош – ул шул баурсаҡ инде, чәк-чәк тә тиләр, аның компоненты шул уҡ инде ул: йоморҡа, он, сода. Сөттән без эремщек, безнең йаҡларда ҡорот-фәлән йуҡ инде ул. Шунан сыр эшләй башладыҡ хәзерге заманда, йогурт-фәлән эшлийбез, май, ҡатыҡ, ҡаймаҡ, асы ҡаймаҡтан сгущенка эшләйләр ҡайсы бер хужабикәләр.

Ваҡ бәлеш пешерәбез мына, өщпощмаҡ, зур бәлеш, ҡабаҡ бәлеше. Шунан безнең йаҡларға хас ҡарабодай белән эщәк бәлеше. Ҡарабодай, эщәк, ливер инде ул, суған салып, приправа салып, бик тәмле килеп щыға. Ҡай бер йаҡларда ит белән итәләр, дөгө белән бирәләр, ә безнең йаҡта ҡарабодай белән пешерәбез, ҡабаҡ бәлешләре. Чашка – йоморо, блюдце – щынайаҡ, ложка – ҡалаҡ, щәй ҡалағы, зурысы – ҡашыҡ. Тарелка –

ҡоштабаҡ та тибез без зур әйберләрне салғанда. Ул эмаль посуда ла булырға может. Без гөмбә тип сөйләшәбез. Төрләрен русча ғына әйтәбез.

Төлкө бар, бүре бар, рысь сирәк, хәзер бездә пошой бар, айулар күбәйде бездә хәзер, айу басты Тәтешле йағын, ойа ҡордолар бөтенләй. Электән андый айулар булмаған, айулар килеп щыҡҡаннар, бына аларны атырға-фәлән, тийергә йарамай, шуңа бөтен кеше жиләккә лә барырға ла бик хәзер атлығып бармый, гөмбәгә барырға да бик атлығып бармый, ҡурҡалар. Ҡабан дунғызы бар.

Миләш, ҡайын, шоморт, ҡызыл шоморт бездә бар, йүкә, нарат. Малина – ҡурай жиләк, земляника – жир жиләк, клубника – ҡайын жиләк, мешок – ҡапщыҡ, угол – мөгөш, свекла – щөгөндөр, хлеб – әпи, носки – ойоҡбаш, платье – күлмәк, брюки – щалбар, шапка – башлыҡ.

(Ҡотлоәхмәтова Эльнара Рафиҡ ҡыҙы яҙып алды).

## ИҪКЕ ҠАЙПАН АУЫЛЫ

### Зыятдинов Фәнис Фәйзелғаян улы, 1954 йылғы

Жиләк тау, Хәсән тау, Уйын тау бар. Уйын тау инде элек ҡайпан жыйыннары үткән урын безнең. Шунан Таштау бар, Щермышҡаш, Балталы имән. Балталы имән – безнең боронғо башҡортлар балта бәреп жыйын вахытында уйнағаннар, самый әйвәт уйыннары шулай булған инде. Балтаны бәреп имәнгә, ул обязательно ҡазалып ҡалырға тейеш. Шунан балталы имән хасил булған. Аның уртасында курган бар рукотворный, жыйыннар вахытында шунда комиссийа булдымы икән, үзләренең түрәләре күренеп тора торған жир. Анан суң Биклебайтау дибез. Биклебайда да рукотворный ней бар. Мына шул курганнар безнең иң боронғо башҡортларның жыйылып жыйыннар үткәрә торған жире дип исбат итәбез. Щөнки Биклебайда шул курганны алтмыш өщенще йылны ҡазыйлар, анан щыға ат скелеты, кеше скелеты, бөтен нәрсәсе белән бергә күмелгән. Әхмәтғәли бабай әйтә ийе, Кушнарен щороноҡо, щөнки ат белән бергә күмгәннәр бит инде. Мин үземнең щын башҡорт икәнемне шәжәрә үткәрә башламайынща белмәй ийем, йарай мына, алланың рәхмәте, шәжәрә нейе щыҡты безнең Башҡортостанда. Шунан инде күз салсам үзебезнең нейгә, ул вахытта әле оло туғаннар да исән ийе, оказывается, бүгенге көнне ун беренще буынны беләм, внук ун беренще буын. Күщәрбай, Эткөсөк, Латып, Лаплатып, Дәүләтбай, Хөсәйен, Тәзрийән, Фәйзелғайан, Фәнис, Динис, Алмас – мына ун бер буын. Шуңа күрә бер ниндәй щиксез рәхәтләндереп бу авзый башҡорт, йәмле башҡорт дип әйтәләсез миңә.

Өлнөш йылғасы бар безнең. Шунан суң Ура йылға, Щоманлы, Мәршәби, Ҡарауыл. Ауыл икегә бүленгән, озон урам ике километр, шунан икенще өстәгесе щаҡ ҡына кәмерәк – Йәшләр урамы дибез инде. Анысы әле мына илле-алтмыш йыл элек кенә хасил булды. Шушы ауылда өщ йылға, йылға дип инде, инешләр инде алар. Бәләкий йылғалар инде. Хәсән шишмә, Кәлми шишмә, шунан суң Зыйарат шишмә дибез, мына зыйараттың ҡырында бик тәмле су. Тегермән шишмә, тегермән дә булған бит инде бездә, хужасы урыс булған, кем икәнен белмим.

Мин әле суңғы ун биш йыл үзебезнең тарих белән ҡызыҡсына башланым. Аңа ҡәдәр нәрсә биргәннәр, шуңа риза булып йөрөдем. Ҡазый башлағанийем, оказывается, без вообще щутный халыҡ, иң беренщеләрдән халыҡ.

Арба, щана, щабата эшләйләр. Ағас эше, в основном, урман башҡорто булғас. Әлегә ҡәдәр щабата кейделәр, уңайлы дип, безнең бабайлар. Ҡасим бабай барырға булды исә берсен аса, берсен кейә, еппәрә, айаҡ табанны ауырттырмай дип. Кейездек басалар. Мин үзем туғын бөккәнем бар жәй көнө, бабайлар әйтәләр ийе: “Оландар, сез безгә булышасыз, мин сезгә иң беренще итеп матур итеп щана эшләп бирәм”. И, действительно, щанасын өстөрәп керә бабай.

Анан безнең жирләребез Пермь өлкәсендә, Көнгөргә ҡәдәр бит безнең Ҡайпан жирләре фактически. Шәрип абзый саткан, Кейековларның бересе, действительно, төрлө щаҡ булған безнең арада да, ҡызып киткән. Бересе нығыраҡ ирсәйеп китте исә, итәгенән тартҡаннар, үз-ара ҡан-ҡойошҡа әйләндермәйенщә, йетте дип. Шулай йәшәгәнбез.

Бөркөтлө ҡарағай, мына дүрт кеше ҡолащлы ҡарағай бар ийе. Мулла ҡул бар, бер мулла руслар белән связда торған, зыйаны күп булған, дип әйтергә кирәк. Урысҡа саткан инде, дөрөсөн генә әйткәндә, Шәрипләр белән бер нейдә булған. Безнең халыҡ диким халыҡ, мыны тотоп нейткәннәр инде.

Ике урын билгеле: бересе Иске Ҡайпанның өскө жирендә, Йаңы Ҡайпан басыуында, бу Алыплар зыйараты дигәннәр. Зур кәүдәле кешеләр дип әйтәләр инде. Щоҡоройның йөз алтмыш йәшен без уздырдыҡ, аны утыз жиденще йылдан тыйғаннар бит инде, халыҡ та ҡурҡа. Шәүкәт абый әллә нищә мәртәбә ғорурланып сөйләгән дә, мының башына биргәннәр. Шунан без йубилейын үткәрдек, Щоҡорға килеп. Уҡыущыларны йөрөтә башладыҡ, мына безнең бөйек шағирыбыз булған, балалар, дип, йыл да киләбез. Карточкаға төшөрәм, үзем зыйараты ҡырында бөтөнесен бастырдым. Ауыл ощонда, Фирдәүес абыйның мунщасында, Илгиз белән фото эшләп утырабыз, малайлар бар, ҡызлар йуҡ. Әле дә ул фото бар, күрсәтәм: “Абый, без анда бар инек”, – диләр ҡызлар. Аптраш, мин аны бер нищек тә аңлата алмайым.

(Йомағужин Айҙар Ғариф улы яҙып алды).

## ЙОСОП АУЫЛЫ

### Сәғиева Рәмиә Батыр ҡыҙы, 1951 йылғы

Йосоп ауылында Ғәли Щоҡоройның нәселеннән күщеп килгән кешеләр йәшәгәннәр. Бик ҡарт түгел ул, әллә ниндәй аның зур таулары, йылғалары да йуҡ. Тигезлектә генә мул уңыш үстереп ауыл хезмәткәрләре матур итеп кенә йәшәп йатҡаннар. Малщылыҡ, аущылыҡ белән шөғөлләнгәннәр. Уйсыу жирләре белән бик матур Сахалин дигән жир бар. Ул ауылдан әзерәк йырағыраҡ, бик ундырышлы булған. Басыулардан жиде-сигез центнер ашлыҡ алған вахытта, анда инде ун биш-ун жиде булған. Шунан Ҡуйан ҡул дигән урын бар инде. Анда элек ҡуйан ҡарағаннар.

Безнең ауыл урман арасында утыра, бер йаҡтан шыршылыҡ, аны мына тәбиғәт шул хәтлем оста итеп өләшкән, бер йаҡтан шыршы, икенще йаҡта ныҡ матур ҡайыннар, шундай баһадир матур ҡайыннар. Бер йаҡтан йүкәлек, усаҡлыҡ. Шушы үзенең тәбиғәте белән дан тота торған ауыл.

Шунан безнең ауылға кергәндә Пыщраҡ күпер дигән жир бар. Ул ауыл жирендә элек ат арбасы белән генә йөрөйләр ийе, әзерәк кенә уйсуыраҡ жир булғащ, үтеүе ҡыйын, пыщраҡ буладырийе, шуңарға ла Пыщраҡ күпер дип атала.

Ике шишмә бар ауылда, бересе Мәғсүм шишмәсе дип әйтәләр ийе, аның өйө ҡырында, анан соң Батыргәрәй шишмәсе, ул уҡытущы шишмәләрне тазартып йыл сайын, матурлап торадырийе.

“Киндер күлмәк” дип атала бу, минең ҡартыйым Рәйханаға бағышлана. Рәйхана ҡартый Әхүнйән хәзрәтнең ҡызы, ә Әхүнйән хәзрәт Ғәли Щоҡоройның улы. Мин аның бишенще быуыны булам.

Мына ҡартыйым дигән сүз. Без ҡартый, ҡартатый дип үстек. Шунан иске дип йөрөткәннәр, күлмәк итәген йыртҡаннар да, кискәннәр дә бала төргәннәр. Бала искегә төрөлгән дип әйтәләр ийе (пеленка). Шунан щынайаҡ сөрткөщ диләр ийе, щынайаҡ дип әйткәннәр инде. Шунан безнең заманда әткәйләрнең, әнкәйләрнең бер туған абыйларына тәтей абый, щибәр абый, дәү апа тейдерийек.

Без үскән ваҡытта иң тәмле аш-суларның бересе үрә дип аталадырийе. Ул тары йармасыннан пешерелә, ҡаз ите салына. Шунан бәлеш, эщенә ҡабаҡ салалар, йөзөм жимешләр белән, икенщесе иттән, эщәктән була.

Щынайаҡ, жәйпеш, йамайаҡ, күбәтә (тимердән бәләкәй табаҡ), аш щүмеще, щүмещ, сәй ҡашығы, бал ҡашығы, ҡазан, щүлмәк (балсыҡтан).

Борондан килгән шөғөлләр йуҡ инде. Элек без бәләки щаҡта лента суғыу бар ийе. Йүкәне алып эшкәртәләр, анан ҡайтарып ҡороталар, шунан бүлгеләйләр. Ҡапщыҡлар эшләгәннәр инде.

Шиповник – гөлжимеш; земляника – ҡайын жиләк; черемуха – муйыл, шоморт; лягушка – баҡа, тәлмәрйен; черепаха – ташбаҡа; угол – мөгөш, пощмаҡ; мешок – ҡапщыҡ; хлеб – эпей; ведро – бидрә; шерстяные носки – ойоҡбаш. Ҡышҡы кейем: тун, башлыҡ, бүрек, кейездек (валенки). Туш – боҙ өҫтөндә ҡалҡҡан су.

(Йомағужин Айҙар Ғариф улы яҙып алды).

## ҠАШҠАҠ АУЫЛЫ

**Йосопов Кларик Солтанғәли улы, 1949 йылғы**

Ҡашҡаҡ ауылында сигезенще класс бөтөрдөм, анан суң технический училищеда уҡыдым, бүтән жиргә барырға мөмкинщелегем булмады. Мин ҡартыйымда ғына үстем, әнийемнең әнисендә генә, ун айлыҡ щаҡтан тороп ҡалғанмын шул килеш. Суңыдан армийада булдым. Армийадан ҡайтҡащ, техникум бөтөрдөм, ауыл хужалығы техникумын, агроном. Шунан колхозда тракторист булып эшләй башлағайным, анан учетчик булдым, анан бригадир булып эшләдем. Шунан суң ауыл советында эшләдем. Шушы вахытта подшкола Свердловский высшей партийный школаға уҡырға кергән ийем, бармадым өщөнщө курсты. Аны, может, үзем дә дөрөс эшләмәгәнмендер, мәктәптә лә әйбәт уҡыдым, шунан ауыл хужалығы техникумын красныйға бөттөм. Тарих белән ҡызыҡсыныу минең бишенще кластан башланды уҡығанда. Суғыш ветераны Ахметов тигән уҡытущы бар ийе, тарих уҡытущысы. Тарих башланадыр ийе Египеттан, боронғо заман тарихлары, шуларны уҡыйбыз бишенще класта. Ул: “Үзегезнең тарихны да ишетеп булса да әкеренләп өйрәнегез” тине. Шул минең ҡолаҡҡа кереп ҡалды, мин шушыннан башлап бөтөн тарихны, шушы ауыл ҡайан барлыҡҡа килгән, ни өщөн гәрәй ыруы, Урмангәрәй ыруыбыз. Үземнең ауылымның хәзерге заманда шәжәрәләрен йазып бирәм кешеләрнекен. Мынау йаҡта Шулған, шунан был йаҡҡа килсәң, бөтөн нәрсә дә шушы Гәрәй исеменә бәйләнгән. Мына Йанауыл районынан йылға төшә, мына ул да Гәрәй йылғасы, Ащйылғаға ҡәдәр Гәрәй ыруы бара. Безнең атамаларда Гәрәй йаҡ, Гәрәтау, Гәрәй йылғасы, ә Ҡашҡаҡ үзе мең дә алты йөзөнщө йылдағы перепись населенийеда бар, элекке бабайларның сөйләүе буйынща. Әйтергә кирәк, мынан биш километр дальше шушы Гәрә буйында урынлашҡан Алдар тигән ауыл бар, Иске Алдар тип атала хәзерге заманда. Шушы Алдардан Бидергәй тигән кеше ике малайына, даже өщ малайынамы икән жир биргән. Шулғанға мына килсә берсе, шунан бер малайына Гәрәнең сул йағында биргән урын, тау башында, шуңа Тау ауылы бар анда. Шунан мына шушы безнең ауыл Ҡашҡаҡ. Бидергәй тигән кешенең булыуынанмы икән, шул урынның атамасы бар Бидергән.

Минең алтмыш биш атама бар, басу атамасы, мин жыйдым барысын. Шуннан инде йаңадан жыйған әйберем, ауыл зур булған, йөздән артыҡ ҡушаматы бар кешенең, ҡабатланмай торған. Шушы ҡушаматлар ҡайсысы бишенще быуынға ҡәдәр килгән, шуларның барысын да жыйып, мына теркәп барам инде мин аны. Именно нащарлыҡ өщөн түгел. Например, ҡайадыр ун зат бар ауылда, иң зурысы Хужағол заты.

Зур әнийем тидер ийе, без бит инде шуңа татарща сөйләшәбез, потому что без татарща уҡыдыҡ, бөтөн дәреслекләр Ҡазаннан ҡайтҡан безнеке. Мин илле алтынщы йылны уҡырға кердем, илле сигезенще йылны

Базийанова Асийа исемле апа килде Кушнаренко районынан, Уфада педагогический училище бөтөп килгән ийе безгә. Ул безгә беренще Уфаның нищек икәнен сөйләде, үзе Башкирийада торабыз, потому что йул йуҡ Уфаға, тимер йул белән Свердловский, Ҡазан арҡылы йөрөдө кешеләр, мына мында бөтөнләйгә йул булмағанға, ә республика безнеке бит инде. “Башҡортостан пийонеры” тигән гәзит бар ийе, мин өщөнщө класта алдырадыр ийем, “Ағизел” журналын бик күп ғүмерләр алдырдым. Үземнең дүрт балам бар, ҡызым англо-башкирскийда, Бирскийда, шушы БГУ-ның филийалына керде дә, ана шул “Ағизел” журналын тағы алдырдыҡ дүрт йыл рәттән. Хәзер Себерзә йәшийләр инде, английский уҡытты, хәзер завуч, замдиректора по воспчасти. Икесе уҡытущы, ике ҡызым. Берсе әле балалар баҡщасында эшләй Тәтешледә. Кәләшем дә уҡытущы шушы, үзебезнең мәктәптә эшләп щыҡты.

Ҡашҡаҡ Бидергәй тигән жирдә утырған, ләкин мында жил тындырмаған, тигезлектә һәр вахытта жил искән, быларның йортлары жимерелеп, ана шулай шушы ике ауыл арасында Драж тигән жиргә килеп утырғаннар, анда да озаҡ тормағаннар. Шушы сазлыҡ, ә безнең ауыл тирәсе сазлыҡ, мына бу урында сазлыҡ, шунан ҡашлыраҡ жиренә, ҡалҡыуыраҡ жиренә утырғаннар. Ҡашлаҡ тигән сүз бар. Ҡашлаҡ – бийиклек, ҡалҡыулыҡ тигән сүз, ҡалҡыу жир. Йазыла торғащ, Ҡашҡаҡҡа әйләнгән инде. Варйады йылғасының буйына утырған, Мишйады беренще исеме булған аныҡы, шушы Мишйады йылғасы буйында утыра. Бу Мишйады йылғасы шушы Гәрәй йылғасына ҡойа, безнең Гәрәгә бер километр бармы, йуҡмы ауылыбыз.

Шунан атамасы Йәрмийә тигән урын бар, Дүртөйле районында Йәрмиә тигән ауыл бар. Элек бер үткән щағында кереп ҡарағайным, мәктәпләрендә кеше булмады, ауылларының атамасы ҡайан килеп щыҡты икән тигән нәрсәне исәпкә алырға уйлаған ийем инде, бездә дә Йәрмийә тигән урын бар тип. Былай алтмыш биш атама бар ауылның жирлегендә. Тәкмәнтау, Дыражтау тибез. Дыражтауның исеме дорж тигән бер төрлө щаға торған ҡорт булған, шушы тауда ғына йәшәгән, шушында мына, шуның өщөн шуны Дыражтау тигәннәр. Һәр вахыт быларның атларын ҡорт щаҡҡан, алар щаҡса, атлар үлгән булған. Ә ул анда ла килеп утырып ҡараған, шунардан ҡурҡып киткәннәр безнекеләр шушы урыннан.

Ҡайын жиләге – земляника, жир жиләге – клубника, шоморт – черемуха, ҡурай жиләге – малина, мөгөш – угол, тустаҡ, жоморо – чашка, жәйенкә – блюдце. Әбийләр, бабайлар тарелканы таштабаҡ тиләр ийе, ҡалай тарелка ла бар ийе электән, алюминийдан.

(Ҡотлоәхмәтова Эльнара Рафиҡ ҡыҙы яҙып алды).

## САРАШТЫБАШ АУЫЛЫ

### Шарыгин Әрхәм Малик улы, 1944 йылғы

Бер мең туғыз йөз бишенще-алтынщы йылда төзөлгән. Йанауыл районы Ҡызыл Йар дигән ауылдан күщеп килгәннәр. Сораштырып килгәннәр дә урман эщендә урын алғаннар.

Безнең данлыҡлы Уара тауы бар, аның башында самолеттарға йул бирә торған майак бар ийе. Беренще май, туғызынщы май бәйрәмдәрендә бөтен ауыл халҡы шунда тауға менеп бәйрәм итәдерийе, гармуннар белән, ҡызлар-йегетләр. Үзе урман эщендә ул. Ҡырында Кеще Уара тауы, анан Жидегән тауы бездән йыраҡ түгел, жиләклеккә йөрөйбез. Жиде түбә булған өщен Жидегән диләр. Йылғалар йуҡ бездә, өщ-дүрт шишмә бар инде. Аҡ шишмә диләр, тирә-йағында аҡ балщыҡ аның.

Безнең ауыл – гармунщылар ауылы, бөтөн йегетләр дә гармунда уйнай, жырлыйлар. Уңған халыҡ йәшей бездә. Буыннан буынға килгән, минең эткәй уйнаған, минең абый уйнай, мин уйнайым.

Ауыл зур түгел, йөз йегерме йортлоҡ ҡына, инде хәзер кәмеп баралар. Безнең ауылда ике нәсел халҡы йәшәй: Шариға нәселе дә Усман нәселе. Ике нәселдән тора безнең ауыл.

Миләш, балан, усаҡ, йүкә, шоморт, ҡайын, ҡара шыршы, аҡ шыршы, имән, зирек үсә. Әсәй – әнкәй, атай – эткәй; өләсәй – зурнәй, олатай – зур этәй; ҡусты – энекәщ, һеңле – сеңлекәщ; ағай – абый; апай – апа. Гөлйемеш – гөлжимеш; ҡурай йеләге – ҡура жиләге; йер еләге – жир жиләге, ҡайын жиләге; баҡса йеләге – виктория; муйыл – шоморт. Мөйөш – пощмаҡ; тоҡ – ҡапщыҡ; икмәк – эпи, икмәк; күнәк – бидрә; турғай – щыпщыҡ.

(Йомағужин Айҙар Ғариф улы яҙып алды).

## ТАШКЕНТ АУЫЛЫ

### Кашапова Рәшиҙә Ғәлиәкбәр ҡыҙы, 1957 йылғы

Күрдемдә үстем дә, мында килен булып төштөм дә шушында йәшәдем инде. Утыз биш йыл эшләдем, стажым бар шушы мәктәптә, башланғыщ кластар уҡытыущысы. Башҡа профессийам йуҡ. Шушы йортта ҡырҡ ике йыл йәшәдек.

Бауырсаҡ тимейбез без – тош тибез. Зур бәлеш пешерәбез – ит бәлеше, ҡаз, үрзәк итләренән дә пешерәбез, тауыҡ итенән дә пешерәбез бәрәнге белән, ә был эщәк бәлеше тип әйтәбез инде, без аны ит бәлеше тип йөретәбез. Анда без йарма салабыз, дөгө йармасы йәки ҡарабойдай йармасы. Ҡабаҡ бәлеше лә пешерәбез, аш пешерәбез, туҡмащ инде күберәге. Бездә нәзек итеп кисәләр туҡмащты. Ашҡа өщпощмаҡлымы, дүртпощмаҡлымы, ромбикмы итеп ҡамыр да салабыз, балалар, оноҡлар шулай сорыйлар. Икмәк – ипи. Ипине бешергәщ, аның ҡамырын ҡалдырасын, шул ҡамырны холодильникка ҡуйып торабыз инде, ә икенще ипи салғанда башта шул ҡамырын салабыз, ащытҡы тип әйтәбез инде, шунан соң әз генә дрожжины, мин күп

салмайым, әз салам. Дүртебезгә бер ипи, шул дүрт ипигә бер аш ҡашығы тулар-тулмас ҡына салам, ә ащысын күберәк салырға тырышам. Шулай итсәң, тәмлерәк була.

Шәнгә тип әйтәбез, тош, бауырсаҡ тип тә әйтәбез, өщбощмаҡ, ҡыстыбый пешерәбез бәрәнгедән, төрлө пироглар пешерәбез инде – балан салып та пешерәбез, баланны элек әнкәйләр пешерә торғайны. Балан күп, кешенең хазер үзенең баҡщасында инде баланы. Элек Әри буйына да барып жыйып ала торған инек.

Ҡаз, үрдәк, тауыҡ – үзләрен үстермәйбез инде хазер, сатып алып ҡына ҡарайбыз да жәйгедә. Суйғанда былай өмә итеп суйабыз. Ҡаз өмәсен үткән йыл уздырдык. Быйыл үзебезгә йегерме үрдәк суйдыҡ, анда ла өмә йасап суйдыҡ, дусларны щаҡырып. Алдан әзерләнәбез инде, өщпощмаҡ, бәлешләрне алдан әзерләп ҡуйабыз да, шул көннө хужабикә үзе бик йолҡалмай инде, хужабикә өстәл әзерләй. Жыйылып ултырғанда жырлайбыз инде шунда. Таҡмағын әйтәбез, күберәк халыҡ жырларын – “Алмағащлары”, “Күбәләгем”, “Тал бөрөсе”, “Жомга”. Йылғаға төшәбез көйәнтәләп. Мал суйғанда ла шулай, ҡаз өмәсендә генә түгел, мәсәлән, үгез тибез инде, тана тибез мал суйғанда. Кешеләр әле мал ҡарайлар ауылда, ат та тоталар. Ат тотҡан кешеләр күп икән хазер, әлдә бар әле.

Әткәй-әнкәй тибез без, хазер йәшләр әти-әни тиләр инде, без әнкәй-әткәй тип үстек, ә безнең балалар безне әти-әни тиләр. Дәү әни, дәү әти тиләр оноҡлар. Зур әти тип тә әйтәләр, зур әни, зур инәй, нәнәй тип тә әйтәләр. Бер туғаннар абый тиләр олосын, апай тиләр кещерәген. Братишка – энем. Сеңлесе булса да апай тиләр, малай булса да апай тиләр. Оло әбейләргә – апа, әби. Зур абый тибез абыйны, иң олосо бездә абый. Оноҡлар зур абый тиләр. Ҡайны, ҡәйнә – килен кеше әти, әни ти. Мин килен тип әйтәм инде, кейәү тип әйтәм, миңә әни, тиләр. Ҡода, ҡодагый шул уҡ ҡала. Миңә жиңгәй тип әйтәләр, ҡайсы апа тип әйтә. Башҡа кеше килен тип әйтмәй, мин генә әйтәм, ащыуланмайлар исемләп әйтмәсәм дә. Жизнәй, ҡәйнеш, ҡайнаға, балдыз.

Урманда ылыслы ағаслар да үсә, йапраҡлы ағаслар да күп. Нарат, шыршы. Ҡурай жиләк тә бар, жир жиләк тә күп, ҡайын жиләге дә бар. Төрлесе бар. Бөрлөгәннең ҡарасы ла, ҡызылы ла бик сирәк.

Килен төшсә, ауылға көйәнтә белән, бидрә белән шишмә йулын күрсәтәбез. Щиләк тә тимәйбез, күнәк тә тимәйбез – бидрә бездә. Урыстан алғанбыздыр. Шишмәгә йул булмағанда ҡойоға алып барабыз.

Сүмес – щүмеш, ашты аш щүмеше белән алабыз. Ҡалаҡ – бал ҡащығы, щәй ҡашығы. Сынайаҡ – йомро тип әйтәбез. Сынайаҡ асты – жәйенкә тип тә, тәрилкә тип тә әйтәбез. Солан – кәжүмкә – аш-су урыны, келәт – мал азығы урыны.(Саньярова Рәмилә Рәмил ҡыҙы яҙып алды).

**Кашапов Фидаил Әхмәт улы, 1951 йылғы**

Уйындар бар. Клюк уйыны. Метр на метр сызасың. Биш-алты йегет уйнай. Бәреп уйнайың. Туп ташлап, бита бәрә инде. Кем өлгөрә, жиңә.

(Хужахмәтов Айнур Оскар улы яҙып алды).

## КЕНДЕКТАМАҠ АУЫЛЫ

### Хәлиуллин Наил Кәшмулла улы, 1958 йылғы

Беззең ауыл Туймазынан йегерме чаҡрым, Өсән йылғасы буйында урынлашҡан. Кендек белән Өсән йылғасы тоташҡан урын, шуға күрә ауылдың исеме – Кендектамаҡ. Ауылдың исеменең сығышы турында версиялар күп кенә, ләкин иң дөрөс варианты: бер мең биш йөҙ дә туҡһан алтынчы йылда безгдең ауылдан үткән татар ғәскәре. Шулар Өсән йылғасында ҡунғандар һәм үҙҙәрен Һуҡундыҡ дигәндәр. Шул сүз трансформация белән кендеккә барып эләккән. Кендектамаҡ йылғасының ҡушылған йере кендек һымаҡ. Бер мең дә жите йөз сиксән өсөнчө йылда ясачные татары дигән халыҡ килеп ултырғандар безгдең ауылға, ләкин ауылдың зыйаратында мең биш йөз туҡһан алтынчы йылдағы таштар бар, шуңа күрә быға хәтлем кешеләр йәшәгән бит инде. Документҡа тик бер мең жите йөз сиксән өсөнчө йылда ғына ауыл төзөлгән, дип йазғандар.

Безгдең ауылдан чыҡҡан полковник ауылдың тарихы белән ҡызыҡсынған, үзенең ике томлы китабын әзерләгән. Ләкин аны бастыра алмаған, үзе үлгәч, йазмалары йуғалған. Уның ҡалған туғандары сүзләре буйынча, шушы сөйләгән дәлилдәр дөрөс. Өсән йылғасының исеме бәлким рус йәки чуаштарҙан килеп чыҡҡандыр.

Бер мең туғыз йөз йегерменче йылдарҙа ауылда халыҡ һаны сигез йөз кеше булған. Барсы ла мосолман, ауылда ике мәчет булған. Улар йер эшкәртеү, малчылыҡ белән шөғөлләнгән. Революциянан суң бер мең туғыз йөз утыҙынчы йылда колхоздар төзөлә. Колхоздың исеме "Өч ҡайын" була. Беренче председателе Шәғәбутдинов, анан суң Хөсәйен абзый булған. Бер мең туғыз йөз илле икенче йылда Ғәрәфутдинов Сабир абзый председатель була. Ул ваҡытта Яңы Суҡкул ауылында "Яңы көч" дигән колхоз була, Муса ауылында "Урал" колхозы була. Ошо өч колхоз бергә ҡушылып "Өч ҡайын" исемен алалар. Азаҡ туғыз колхоз бергә ҡушылып, "Большевик" колхозы барлыҡҡа килә.

Кендектамаҡ ауылында ике мең ун икенче йыл мәсет төзөлдө. Минең этийем дә, әнийем дә намаз уҡығандар. Мәчеткә һәр халыҡ йөрөй, һәр бәйрәмдәрҙе үткәрәбез. Ҡорбан, Мәүлит, Жомға бәйрәмдәрен үткәрәбез. Балаларға исем ҡуштырабыз. Баланы айағы белән ҡиблаға ҡаратып йатҡырасың, этий-әнисен ҡотлайбыз. Әл-Фатиха сүрәһен уҡып башлайбыз. Башта баланың уң йаҡ ҡолағына азан әйтәбез, анан суң исемен әйтәбез. Сул йаҡ ҡолағына кәмәт сүзләрен әйтәбез. Кәмәтте ҡысҡа ҡына уҡыйҙар. Баланың исемен өч тапҡыр ҡабатлап әйтергә кәрәк. Баланың этий-әнисенә теләктәр әйтәбез, шулай уҡ туғандары бүләк бирә, үз теләктәрен йеткерәләр.

Ҡорбанға сарыҡ, кәжә, ҡуй, сыйыр, дөйә малы йарай. Бер кешегә бер сарыҡ ҡуйыла, ә сыйыр булса, биш кешегә, дөйә булса, жите кешегә. Сарыҡ алырға хәле булған һәр бер кеше, ир-ат булсынмы, ҡатын-ҡызмы, ҡорбан чала ала. Сарыҡ малы бер йәшлек, йаҡшы ашатылған, бөтөн йере сау булырға тейеш. Ҡорбан чалғанда Ғәйет намазы уҡыла. Ҡорбан өчкә бүленә. Бересе хужаның үзенә, икенчесе туғандарына, өсөнчө өлөшө тәхирләргә бүленә.

Никах үткәргәндә без йәштәрҙән шаһәдәт әйттерәбез. Баштан ҡыз кеше үзенең ризалығын бирә, шунан кейәү кеше. Азаҡтан туғандары даһәр бирә. Ике ир-ат, бер ҡатын-ҡыз шаһит була ала. Улар йәштәрҙең ризалығын ишетеп ултырырға тейештәр. Үзем бер мең туғыз йөз сиксән өсөнчө йылдың апрелендә кәләш алдым. Мин ҡатынымды урлап алып киттем, аның этийләре ҡыздарын миңә бирмәйем тигәйнеләр. Бер ауылға барып тора башладыҡ, анан суң ата-әсәһенең ризалығын алдым.

Кендектамаҡ ауылында "Саумыһығыҙ, ауылдаштар!" кеүек халыҡ бәйрәмдәре, осрашыуҙар ғаиләләрҙә үҙ-ара татыулыҡты, быуындар бәйләнешен нығыта, ауылдарға йәм бирә.

Ауылда Түбән оч, Арйаҡ-Кендек йылғасының арйағында Чуаш урамдары бар. Ауылыбызда элек чуаштар булған. Безгдең нәселебездә Ҡазан татарҙары диләр.

Шиповник – гөлжимеш, земляника – жир жиләге, клубника – баҡча жиләге, малина – ҡурай жиләге, черепаха – ташбаҡа, лягушка – баҡа, божья коровка – Антон бабай ҡондозо, бабочка – күбәләк, слякоть – батҡаҡ, колодец – ҡойо, угол – почмаҡ, шәп аҡҡан һыу – урғылып аҡҡан су, йырғанаҡ.

(Саникина Сулпан Рауил ҡыҙы яҙып алды).

## КӘКРЕБАШ АУЫЛЫ

### Сафуанов Әнәс Мосағит улы, 1938 йылғы

Кәкребаш – кеше исеме ул. Без бәләкәй щағында Хәмзә дигән кеше, кәкре башмаҡлы кеше килгән, дип аңлатаҙыр ийе. Кәкре башмаҡлы кеше, жәнәсе. Шунан икенщесе, безнең мына туғай, Тимер Арслан йараҡкан

туғайлар – кәкре-бөкрө. Шуңардан щығып дип оло кешеләр аңлатаҙыр ийе безгә. Соңодан бынау Әсфәндийәрофтан килеп щыкты, Кәкребаш кеше булған, дип. Ул ҡыр йылан кешесе, мында күщеп килгән, оброктан ҡащып. Шунан урманны кисә-кисә кергәннәр ҙә, шунан ағащларны төпләп, щәщеп, утыраҡ тормошно беренще тапҡыр башлаған кеше Кәкребаш мирза. Улар икәү булғаннар – Кәкребаш һәм Исмаил. Екатерина указы буйынща, башҡортланы крепостной итәргә йарамаған, аларны щуҡындырырға ла йарамаған, башҡортларға тейҙермәгән ул, аларға льгота күп булған. Кәкребаш шунда ултырған. Шунан ҡалған нәсел инде без.

Ҡызыҡсынып китеп шәжәрә мәсьәләсе, нәсел мәсьәләсенә кереп кителде инде. Шулай итеп шәжәрә төзөргә туры килде инде, башладым инде. Ул шәжәрә төҙү шул хәтлем мауыҡтырғыщ, аңардан щығып китеп булмай бер нищек тә. Шунан, шәжәрә төҙүнең ике йағы бар: шәжәрә бит инде илнең тарихы, ауылның тарихы, безнең ата-бабалар тарихы.

Икенщесе – шушы шәжәрә төзөгән ваҡытта ғөрөф-ғәҙәтләргә кереп китергә туры килде. Фольклор, ғөрөф-ғәҙәтләр жыйылды. Ғөрөф-ғәҙәтләр шул хәтлем күп, арыу ғына ғөрөф-ғәҙәтләр онотолған, жуҡҡа щыҡҡан булып щыкты. Бик ҡызыҡ булды ул.

Бында йалан щәщкәләре бик күп инде ул. Ҡоңғороу щәщкәнең төрлөсө бар, зәңгәре бар, алсу төстәгесе, алар барсы ла бар. Кәкребаш йағының данлыҡлы ландышы. Урман эщендә ап-аҡ булаҙыр ийе. Без бәләкәй щағында шуны жыйып, бәйләп, тасҡа салып, жәйәүләп жалан тәпи Туймазының базарында сатып, китаплар, дәфтәрләр алаҙыр ийек. Жаланға щыҡҡащ, ҡузғалаҡ, йуа, ҡымызлыҡ ашыйбыз. Кәзә саҡалы – бик опасный үлән. Шунан соң ҡамыш төбө ашайбыз. Йаз көнө умырып ала, шуларзың тамырлары өлгөрә, өлгөргәщ, ул крахмалға әйләнә, барабыз да шуны кисеп алып, әрщеп, шуның крахмалын суырып, уртасы ҡаты аның. Ҡамыш тамыры ул особый, ныҡ таралып пешкән бәрәңге шикелле крахмал ул. Ап-аҡ төстә була ул әрщегәщтен. Әкренләп житешә ул жәй уртасына. Аның житешкәнен көтмәйбез, барабыз да, жыйабыз да, ущаҡ жағып ущаҡта пешерәбеҙ. Пешкәщтен әрщеп, эщен ашыйбыҙ инде.

Һәр атаманың үзенең тарихы бар. Бына беҙнең "Щәщкә бәйрәмен" Үәли әрәмәсендә үткәрәләр ийе. Үәли бай булған. Аның жире булған ул.

Кәрим туғайы бар. Кәрим бай, атаҡлы бай, аның үзенең туғайы.

Шунан соң, Ғәбит байы. Мынсы да шул кеше белән бәйле инде. Таулы-щоҡорло жир, аның пещәне әйбәт була. Ғәбит байы ғына диләр аны. Уйсыу жир. Жиреклек урманы бар. Ҡаршы йаҡта – усаҡлыҡ.

Уртатау жаланы бар. Аның пещәне шәп була. Уртатаузың уртасында йуалыҡ, ҡузғалаҡ. Шунан соң, Маржа сабыны. Байар жире. Фин байары булған мында, үзе йәшәгән Петербургта, жире мында булған аның. Ул мирас буйынща килгән. Ул бик ҡызыҡ ул. Байар жиренең иң ҡызығы шунда, коллективизация башланғащтын, щуалыщ ваҡытында талап, алып бөтөргәннәр. Шунан байар хатыны Калининға барған. Калинин тегенән указ жибәргән: "Бу подданный, быны энәсенә лә тийәргә йарамай". Финский подданный бетмәгән булған. Бөтөнөсөн кире биргәннәр. Бер ломын табалмағаннар, шуны таптырған теге.

Щуҡынмыш туғайы, унын ике төрлө аңлатмасы бар. Берсе – урыс жире булған, щуҡынған урыс жире. Шунан икенщесе – без белгәндә ул Ыҡ аша илле-алтмыш метрға керҙе беззең йаҡҡа, теге йаҡта утрау булып ҡалды ул татарларға. Шунда инде, йәнәсе, кергәщтен теге бай щуҡынған икән, Татарстанға китте минең жир, дип әйткән, имеш. Шунан ҡалған.

Фронтон – өйнөң йөзө. Мин инде мансарда белән йасадым. Матща, түшәм, тәрәзә, диләр бездә. Гөбө. Жегерләү щығыры. Орщоҡ. Сөлгө. Әбекәйнең станы бар ийе. Ҡара Зиректә инде. Мин суҡҡанын ҡарап торадыр ийем. Шүре. Жолпо. Таралып киткән кешене жолпо кеүек, диләр. Бәрәңгенән кәкре пешерәләр. Иң исән ҡалдырғаны – ҡатыҡ. Шунан соң бәрәңге, пищтә тәгәрәтеп пешергән бәрәңге. Суда пешергән бәрәңге. Тоз. Шунан талҡан. Дур инәй – тетя, со стороны отца. Дур инәй шуның белән тартып ултырғаны хәтердә. Дур әтәй – дядя, әткәйнең абзыйсы, со стороны отца. Абзыҡай – әнкәйнең абзыйсы, со стороны матери. Әнкәйнең абзыйсы бар ийе – Шәрифйән абзыҡай. Түтәй – әнкәйнең апасы, со стороны матери. Бианай, биатай дип килен кеше әйтә. Ҡәйнеш дип ир-ат жаҡлап әйтәбез, шурин. Ҡатын йағынан йанағай дип әйтсә – жиңгәщәсе әйтсә, ул – ирҙең ҡустыһы була. "Йанағай – йарты ир, ир булмаса – бөтөн ир". Боронғодан ҡалған сүз. Аның мәғәнәсе бар.

Урам исемдәре бар: Төбәк, Түбән ощ, Жуғары ощ, Арйаҡ, Бу йаҡ.

Иске зират әле дә бар. Дур әтәй әйтәдер ийе, щирмещләр зираты, дип.

Ат йеккәндә иң башта тәртә. Тәртәдә була түшлек. Түшлекнең арт жағында арҡалыҡ. Тоже ҡайыш шушындый. Ыңғырщаҡ аша ҡуйыла торған ҡайыш. Иң беренще жөгән инде, билгеле. Жөгәнгә ҡарап кешенең престижы. Тәңкәле жөгән. Мунщаладан үрелсә, ул ноҡта була. Ул иң булдыҡсыз кешенең була ул. Ноҡта белән генә аның аты, ноҡта белән генә, диләр, ул пүштәк кеше. Ә теге тәңкәле, төрлөщә тәңкәле, ыңғырщаҡ та тәңкәле, ҡамыт, дуға, ауызлыҡ, түшлек, аны бауырлыҡ та диләр. Кашауайлар булды. Ул байларский. Колхоз председателе тарантаста инде. Первый секретарь Хабибуллина килде. Без жыйылдыҡ ресорлы арба күрергә, тимер ресорлы, мына шундай крылосы да бар. Шундый ат белән килеп туҡтаҙы. Атын бәйләҙе. Без сырып алдыҡ та ҡарайбыз. Ҡарале, селкетеп тә ҡарайбыз тегене. Первый секретарь. Без брищка белән бәрәңге ташыйдыр ийек. Ике ат жигелә анда.

Щана, утын щанасы бар, үрәщәле щана бар ийе. Аның арты йуҡ үрәщәле щананың, ул базарға-мазарға йөрөй торған, әйбер төйәп. Утын щанасы бит инде бынаулай жәйенке. Ә үрәщәленең артҡа табан килә, алғы йаҡ ҡаплаулы. Ҡунаҡҡа байлар инде, бай дип инде, важныйыраҡ кешеләр инде кашовка белән. Безнең Шәрифйән абзыҡайлар киләдер ийе Татарийадан Ҡара Зиректән, тун, толопта. Ул толоп белән өшөрлөк булмай, аның жаҡасы бына шундай бейеклектә. Төп без белгәндә оло йәштәгеләр, щикмән тулаҙан, аның өстөнән

киндер ыштан. Щикмән, аҡ ыштан, аның өстөнән киндер ыштан, тула ойоҡ, щабата – хәзер дә хәтердә. Щәкән жиле диләр ине северный жилне. Эх, Әхмәтжән, Щәкән жилләре дип барған икән, дип. Татар Щәкәне мында, Рус Щәкәне былайыраҡ. Ҡулға – бәйләнгән бейәләй. Башҡа кийәләр дәрәжәсенә ҡарап, байлығына ҡарап. Мескен бүрек кейгән дигән сүз дә бар ийе.

Безнең әбекәй тапҡыр сүзле ийе, тапҡыр сүзләрне әйтәҙер ийе гел, "Айағың тәпелдәмәсә, ауызың щәпелдәмәй", – дип. Элек шулайыраҡ ийе шул. Әзерәк щинай башласаң, нитә башласаң инде, "Элгәре бу сирле ийе, быҙау тибеп үтерҙе", – дип үртәп әйтәҙер ийе.

*– Үтерҙе тип ҙ менән әйттегеҙ. Ҙ өнө һаҡланған тип әйтергә буламы?*

– Ике төрлө әйтелә. Андый сүләшеү ҙә бар, быңдай сүләшеү ҙә бар. Ҙ өнө лә, з өнө лә бар. Бездә башҡортлоҡ, башҡорт теле нык саҡланған. Без Татарстан белән ҡырыйҙа булғащтын, Кәкребаш ауылы татар ауылы булып хисаплана. Әммә ләкин мына сүләшеүҙә нык башҡорт йолалары, башҡорт сүзләре күберәк. Сүләшеүҙә. Бармайым, ҡайтмайым, эшләмәйем, күрмәйем, белмәйем.

(Сәғитова Айгөл Ғәни ҡыҙы яҙып алды).

**Төхвәтуллина Зөләлә Рәис ҡыҙы, 1967 йылғы**

Ҡаз өмәсенән тыш без йаңа "Кар суы йоласын" күрсәттек. Буразна бәйрәме, Сөмбелә бәйрәмнәрен бик гөрләтеп үткәреп жибәрдек безнең мәдәнийәт йортонда. Былай эшләр гөрләп бара. Үткән йыл Шәжәрә бәйрәме үткәрҙем. Республика күләмендә булды инде ул. Әлеге уаҡытта инде мин башҡорт милли кейеме буйынса Ҡусҡар бәйрәме мастер-класс әзерләп йөрүем. Күп уйлаҙым. Матур бәйрәм булащаҡ инде. Мин инде бу бәйрәмне төнйаҡ-көнбатыш башҡортлары белән тәмамларға жыйынам. Мин үземә лә костюмдар тектерәм, үзебеззең йаҡ башҡортларының. Һәр берсенең костюмын күрсәтеп, сөйләп үтергә ийе. Шуға нык әзерлек бара бүгенге көндә. Эшләгән эшләр ҙә күп инде ул.

Мәҙәнийәт йортонда эшләү дәүерендә бик күп йолалар үткәрелде. Алар ғөрөф-ғәҙәтне йәш буынға өйрәтергә һәм боронғо йолаларны саҡлап ҡалырға тырышыу сәбәпле үткәрәбез инде.

(Сәғитова Айгөл Ғәни ҡыҙы яҙып алды).

## ҠАНДРА АУЫЛЫ

**Абрарова Миңнезадә Шәмсетдин ҡыҙы, 1938 йылғы**

Уфа районы Нөрлө ауылында тыуҙым. Ҡәдерле әтийем – суғыш ветераны Шәмсетдин Сәфиуллин бер мең туғыз йөз ҡырҡынчы йылда вафат булу сәбәпле, дүрт баланы әнийем үзе генә үстерде. Бала чағым ауыр суғыш йылларына тура килде. Туғыз йыллыҡ мәктәпте тамамланым. Туймазы районына бер мең туғыз йөз сиксән өчөнчө йылда килдем. Ҡандра ауылында мал симертеү комплексы асылған иде, шунда ғаиләм белән эшкә килдек. Туған ауылымда аллергия белән интектем, аллергиянан ҡасып килдем. Комплекста мал симертеү операторы булып эшләдем. Бер мең туғыз йөз туҡчан өчөнчө йылда хаҡлы йалға чыҡтым. Хәзерге көндә төрлө түңәрәкләргә йөрөйем, "Хазина", "Умырзая" ансамблдәрендә жырлайбыз. "Туймазы хәбәрләре" дигән гәзиттә шиғырларым басылып тора.

Алдан Ҡандра-Ҡотойда йәшәнем, хәзер Ҡандрала торам. Күрсәтерлек йерләребез күп. Йәрмөхәмәт басыуында Ташмич дигән шишмә бар. Өч урындан су аға. Үзе мичкә оҡшап тора. Ҡандра-Ҡотой ауылына Татлыбай шишмәсе килә. Бик матур йерләрдә торабыз. Ҡотой ауылын икенче туған ауылым дип йөрөтәм.

**"Башҡортостан"**дигән шиғырым бар.

Башҡортостан дигән илем бар,
Анда татыу барлыҡ халыҡтар.
Башҡорт, марий, рустар, татарҙар,
Берсен-берсе дуҫ дип таныйҙар.
Ҡатнаш ғаиләләр бихисап,
Уй, хыйалдар бергә, эш уртаҡ.
Аларҙан туған сабыйҙар ҙа
Бәхетлеләр булыр, табыр үз йулдарын.
Тик именлек булсын илемдә,
Имен илдә бәйрәм, эше лә.
Күңелендә жырлар булғанда,
Жырлай-жырлай эшләй кеше дә.

(Саникина Сулпан Рауил ҡыҙы яҙып алды).

**Байбурина Гөлнур Мөдәссир ҡыҙы, 1967 йылғы**

Бүздәк районының Зур Өштөбә ауылында тыуҙым. Был ауылға килен булып төштөм.

Утыз өч йыл тәрбийәще булып эшләгәннән соң, мине Татьяна Анатольевна мәдәнийәт йортына чаҡырып алды. Өч йыл шушы клубта эшлим, шушы ваҡытта спектаклдәр ҡуйдыҡ, Мостай Кәримнең йөз йыллығына "Ай тотолған төндә" спектаклен әдерләдек. Мин бында Тәңкәбикә ролен башҡардым. Миңә хатта Байбисә дип

ҡушамат та ҡуштылар әле был спектаклдә чығыш йасағаннан соң. Халыҡ ныҡ йылы итеп ҡабул итте. Ауыллар буйлап та йөрибез. Эштә ҡызлар ныҡ йардам итте. Шушы спектаклне башҡарып чығардыҡ һәм конкурста лауреат булдыҡ.

Шушылай спектаклдәр ҡуйасы килеп китте, аннан инде фольклорны да ташлайсы килми.

Без бердәм, бик тату. Бер конкурстардан дә читтә ҡалмыйбыз, һәр ваҡыт урындар һәм дипломдар белән ҡайтабыз.

(Саникина Сулпан Рауил ҡыҙы яҙып алды).

## ҠАНДРАКҮЛ АУЫЛЫ

### Баһауетдинов Раян Талбетдин улы, 1952 йылғы

Үз ихатамда ике музей бар. Беренче музейҙы ачып жибәреүдә Гашимов Фәсим белән Фәтхисламов Иректең йардамы бик зур булды. Без өч класташ, өч таған, өч айаҡ. Без бер-беребезгә һәр саҡ йардам ҡулы сузабыз. Фәсимдән мин йүнәлеш алдым, күп әйбер алдым. Читтән ҡайтҡас, туған йаҡты нығыраҡ сағыныуым сиҙелде.

Музейҙың беренче мөйөшөндә балыҡчы ҡоралдары. Иң беренче ат ҡылынан эшләнгән ҡармаҡтар бар. Шунан суң, ҡурғаштан ҡойолоп эшләнгән йатҡырма дигән алабуға, шүкә ҡармағы бар. Барысы ла ҡулдан эшләнгән. Балыҡтан тыш, ҡуйанға, бурсыҡҡа, бүрегә ҡапҡандар бар. Киләһе мөйөчтә эш ҡоралдары китә. Утыз биш төрлө балыҡ сөнәренә кирәкле ҡомартҡылар бар. Унан тыш, ағач эшкәртеү буйынча инструменттар, революцияға хәтлемге дюймовый ачҡыслар бар. Ул ачҡыстар хәзер ҡулланылмай, безгә Американан килгәндәр. Американа үлчәү берәмеге дюйм булған. Шушы ачҡыстарҙа йылы, ҡаласы йазылған. Шунан, уң йаҡҡа табан жите метрлы балчыҡ көршәге бар. Сауыт-сабалардан май, эремчек, ҡаймаҡ саҡлағыс сауыт бар. Без уны май чаҡлағыс, чиләк, дип йөрөтәбез. Элек шул ағачтарға сөт азыҡлары салып, баҡа төшөрөп базда саҡлағандар. Биш литрлыҡ чәйнүк бар. Бер кинофильм ҡараныҡ, унда Бөтөн Донйа суғышында салдат атакаға бара, сул йағында шул чәйнүк эленеп тора.

Бездә балаларды йоҡлай торған урынын бәллү диләр, ә арбаға салып йоҡлата торғанын чәңгелдек диләр. Элек чәңгелдәктәргә пружиналар бик ҡиммәтле булған, шуға минең әтийем пружинаһын ағачтан эшләне. Ул сына дип тә ҡурҡмайһың, бик ыңғай тирбәлә.

Музейҙың киләһе мөйөчөндә тимер йоҡлағыч, анда парчалы әйберҙәр, меңдәр тышлығы, ковер бар. Иң суңғы мөйөштә Ленин бабайдың бюсты тора, пионер галстуктары, мизалдар һәм ҡанлылардың йылы бүреке, күшәге, сырған чалбар, кәжән, ойоҡ, чабата эленеп тора.

Икенче музейҙа мич, мич алдында ҡомған тора. Мичтең ауызы, эчендә ипи пешерәбез. Инвентарҙан күмер тарта торған, соҫҡо, ут торонбаш, кисәү ағачы, табағач, чәй ҡуйарға таш бар. Мичтән йылы чыҡмас өчөн йүшкәсен тартып ҡуйалар. Мичтең йүшкесен йапҡач, өстөнә менеп сөйәк жылытҡандар. Мич өстө жылы була. Стенала сауыт-сабалардан йулпыч, иләк, ҡалайҙар бар. Йулпычҡа он салып индергәндәр. Түрҙә чәңгелдек эленеп тора. Пружинаһы ағачтан эшләнгән. Башта иң сифатлы, ҡыйбат әйбер – чүрлек йата. Сундуҡта иң затлы әйберҙәр саҡлана. Иртән уйанғач, кешеләр меңдәрен балалар тапамаһын өчөн киштәләргә алып ҡуйғандар. Ипи пешерсәләр ҙә, песи менмәсен дип, шул кәштәләргә ҡуйғандар. Музейҙың йартысын шаршау бүлә. Унда әүернә – минең тамғам төшөрөлгән. Өстәлдә чәй эчә торған чынайаҡ, чынайаҡ асты ултыра. Музейҙан чығып барғанда йүкәнән үрелгән бау эленеп тора. Элекке пальто, шуба, эшләпә.

Ихатамда ҡулдан эшләнгән чана бар. Шушы чана белән ҡыш көнө бәләкәй чаҡта утын, салам, печән ташый торған идек. Бездә ат булманы, үзебез ташыныҡ.

(Саникина Сулпан Рауил ҡыҙы яҙып алды).

### Гашимов Фәсим Шәмсимөхәмәт улы, 1953 йылғы

Ҡандры ауылында тыуҙым. БДУ-ның тарих факультетын беттем. Күп йыллар мәктәпләрдә тарих, география фәннәренән уҡыттым. Азағынан инженер да булып эшләдем. Уникаль хәл – Ҡандрыкүлнең дирекциясы төзөлдө, мин шунда директор булдым. Тәбиғи парк итеп эшләтүгә мин ирештем. Машиналар алынды, үзенең базасы булған, андый ис китмәле шәп парктар йуҡ әле безнең республикада.

Ҡандракүл ул боронғо Ҡанлы волосе территориясында урынлашҡан. Ҡанлы волосе элек-электән булған. Ҡанлылар алар урта ғасырның иң көчлө дәүләтләренең берсе булған. Оғузлар һәм уғырлар, ҡыпчаҡлар. Башҡортостанда бит инде бик күп милләт халҡы йаший. Алтай, Урта Азиянан бик күп халыҡлар күщкән. Суңынан алар барсы бергә дуслашып, берләшеп, бер милләт булып ойоша. Бер генә милләтнең дә чиста бер халыҡтан килеп щыға алмаған. Әле лә шулай. Движение була ул.

Рус милләте – ул иң йәш милләтләрнең берсе булып санала. Төрки халыҡларының влияниесенда. Культурала һәр бересе конкурировать итә. Һәр бер халыҡ үзенең ғөрөф-ғәдәтләрен дауам итергә тырыша. Хәзер глобализация бара. Инглиз, ҡытай телләре ныҡ тарала. Жәмғыйәт ныҡ алға китә. Ҡайсы ил экономик, культура йаҡтан алға китә – шуныҡын ҡабул итергә тырыша. Бөтөн донйада алға китеш бара.

Ҡанлы волосе төзөлә. Ул ун туғызынщы ғасырға щаҡлы килә, анан соң Рус дәүләте бу волостларны бөтөреп, йаңа административный территориялар йасый. Без иң беренще Ҡандра районы булғанбыз, хәзер инде

без Туймазы районы булып йөрийбез. Һәр ваҡытта ла шулай үзгәрешләр барған. Тимур Алтын Урҙаны тарҡатҡан. Ул кинәт һөжүм итә.

Алтын Урҙа йулы Шишмә районына тиклем үтә. Туҡтамыш Ҡандрыкүл һәм Аслыкүл тирәләрендә үзенең ғәскәрләрен Тимурға ҡаршы жыйа. Тимур үзе ике йөз илле меңләп кеше белән килә, ә мында йаҡынца шул уҡ хәтле кешене Туҡтамыш хан мобилизовать итә. Алар Ҡандракүл йанында барсы да жыйыла инде. Урта ғасырның иң зур суғышы була. Тимур жиңә. Тулысынча жиңеп бетерә алмый, Ҡандракүлнең исеме Хан тора дигән сүзгә тура килә. Ҡартлар әйтеүенщә, элек бында хан торған. Без әле Ҡанлының ҡыр территориясында утырабыз.

Иң зур суғышларның сүзлеге бар, Тимурның суғышы анда "ҡыргел суғышы" дип кертелгән. Бу Шарафутдин абзый язып барғанлыҡтан, иң беренсе стычка безнең Ҡандракүлдә башлана.

Инглиз сүзлегендә "ҡыр күле суғышы" дип кергән, ә безнең илдә исә "ғыргел" дип атала. Ҡанлы волосы элек-электән булған. Ҡаған дигәнде аңлата. Ҡан хан дигән сүзгә ныҡ йаҡын. Европада "ураҡан" сүзе бөтенләй булмаған, Американы асҡаннан соң ғына, был сүз индеецлардан килеп, артабан да тарала башлаған. Ураҡан – жил Алласы дигәнне аңлата. Уғырларда Хан, Ҡаған сүзе бик боронғо булып йөрий. Без, хәйерле иртә, дип әйтсәк, индеецлар, хәйерле таң, дип әйтә. Безнең лингвистик бәйләнеш бар. Ҡыпщаҡ теленең роле ныҡ зур. Башҡорт, татар телдәре барсы да ошо төркөмгә керә. Был ике тел бер-берсенә бик ныҡ йаҡын. Дөйөм төркилек була.

Баймаҡ районында ҡазаҡлар белән бәйләнеш күренә. Тәбиғи лә, тел йағыннан да. Башҡорт менән татар теленең тамырлары элекке быуыннарға барып тоташа.

Менә бездең ауылда Эт имгән нәселе бар. Зәки Вәлиди үзенең китапларында сак халҡы турында йаза. Бына әле соңғы йылларда ғына Ҡазахстанда алтын кеше таптылар. Алтын кийемдә, суыҡтан табып, реконструкция йасалды. Зәки Вәлиди, сак халҡы ул – Эт имгән нәселе халҡы, дип аңлатма бирә. Эт культы булған, аларны йәберләргә тырышҡаннар. Сак халҡы зәңгәр күзле, сары сәсле, аҡ тәнле булғаннар. Әйткәндәй, Белорет районында ла шундай кешеләр бар. Шушы исем буыннардан буыннарға щаҡлы килеп, Белорет районының Әбсәләм ауылы – Эт имгән ауылы дип башҡорт фольклорына да ингән. Бу ҡыпщаҡлар аша килеп кергән. Сак халҡы шулай таралып, башҡортлар һәм ҡырғызлар арасына да кереп киткән. Әйткәндәй, ул Европада ла ныҡ таралған. Шуға ла инглиз теле сүзләре белән ҡайсы бер татар сүзләре ныҡ оҡшаш.

Ул йаҡта культура күпкә көщлөрәк булған. Татар белән башҡорт телен берләштерергә лә теләмәгәннәр, шулай да аларның айырмасы бик ныҡ зур ул.

Башҡорт халҡы элек-электән булған, үсешкән, төрлөләшкән.

Безнең элек Ҡандрыкүл тирәсендә ҡуллар булған. Һәр бер ҡул үзебезнең ауыл кешеләренең биләмәләре булған. Бурай, Буранғол, Мин ҡулы бар.

Ҡул дип атала, щөнки ҡул кебек биләмә. Гәрәй бүләге бар.

Язы дигән сүзгә иғтибар бирер кәрәк. Мәсәлән, Туймазы, Уязы, Ауырғазы, Көйөрғазы. Был боронғо төркилектән килә.

Тоймаҡ – башҡорт сүзе, татарларда йуғ ул.

Сөн йылғасы. Ҡомнар дигәнне аңлата.

(Саникина Сулпан Рауил ҡыҙы яҙып алды).

**Зиннуров Тәбрик Хәбип улы, 1950 йылғы**

Иң беренче үзем бенән таныштырып үтәйем. Таныштырыуҙы ошо әйберҙән башлайыҡ. Бына бында йаҙылған бөтәһе лә. Тәбрик хәҙрәт Зиннуровтың шәжәрәһе. "Башкиры рода Канлы". Был әсәйем йағынан шәжәрә.

Икенсеһе атайым йағынан. Ошонан киләбеҙ инде. Усман дигән кешенән. Быйыл беҙҙең ауылға өс йөҙ йегерме йыл була. Ошо байрамды матур итеп үткәреп йебәрергә кәрәк. Беспартийный. Ҡарт та, йәш тә түгелмен әле мин. Сығышым менән Ҡандрынан булам, Ҡанлы башҡорто мин. Атайым дә, әсәйем дә башҡорттар. Беҙ үзебеҙҙең башҡорт икәнебеҙҙе бала саҡтан белеп, тойоп үҫтек. Нәҫелем – Ҡанлы. Мин был ауылдың хәҙрәте булам.

Ауылыбыҙ Ҡандракүл тип атала бит инде. Бында өс төрлө вариант йөрөй. Беренсеһе, имеш, бында Хан торған. "Хан тора" тигән һүҙҙән алынған. Туҡтамыш хан. Икенсеһе, беҙҙең элекке өйҙәрҙең бүрәнә араларына ҡандраҡ ҡуйалар (мүк). Ана шул исемдән алынған. Миңә Ҡотой ауылынан Флүр ағай, "ҡыуандыра" һүҙенән алынған, тип әйтте. Балығын да, мүген дә биреп ҡыуандыра. Мин дә был вариант менән килешәм, сөнки беҙҙең олатайҙарыбыҙ бер ваҡытта ла ла, күлгә керәбеҙ, тип әйтмәнеләр. Улар һәр ваҡыт, Ҡандрыға инәбеҙ, тип һөйләне. Иң беренсе ауыл беҙҙең "Пятачок" тип йөрөтөлә. Ауыл икегә бүленеп йәшәй. Мәсет төҙөнөк. Уны элекке иҫке урынына һалдыҡ. Бер мең туғыҙ йөҙ утыҙ һигеҙенсе йылда мәсетте йемерәләр, шунда минең өләсәйем нигеҙҙең ташын булһа ла ҡалдырыуҙарын һорай. Мин унда ултырырмын, ти ул. Ул таш беҙҙең ҡапҡа алдында торҙо. Йаңы мәсетте һалғанда, шул ташты мәсет аҫтына керетеп һалдыҡ инде. Әйткәндәй, беҙҙең ауылыбыҙҙа йылғалар йуҡ. Серекҡүлдән генә төшә. Күпере бар, шунан һыу ағып төшә. Исеме йуҡ инде ул. Ҡотой ауылы йағынан ваҡ-төйәк шишмәләр ағып төшә. Улар күлгә килеп ҡушыла. Элек Кендек күлдән ағып йатҡан. Кендек тип аҡҡан йерен йөрөтә торған инеләр, һуңынан быуып күмелде инде ул. Тәрәнлеге лә һайыҡты, һуңынан төшөрҙөләр. Беҙҙә Пистолет баҫыуы бар, ул ысынлап та пистолетҡа оҡшаған. Шунан беҙҙә

Ҡырҡ бер бағана баҫыуы бар. Кем һанағандыр инде, уныһын белмәйем. Тағы ла Оло баҫыу, Арба ҡулы, Сана ҡулы баҫыуҙары бар беҙҙә.

Беҙҙә иң оҙон урам Озерная тип атала. Башҡортса Күл урамы була. Шунан Яңы урам бар, мин уны Яй килде урамы тип әйтәм, сөнки ферманан ҡайтырға йай килде, уңайлы.

Ауылыбыҙҙа һәр береһенең ҡушаматтары бар. Мәҫәлән, Бычок, Хутор, Утка. Был исемдәр йуҡтан ғына алына ла ҡуйа. Мәктәптә уҡығанда, физкультура дәресенә сыҡҡас, тау буйына алып сыҡҡас, бер бала быҙауға атланған. Бына хәҙер һиңә быҙау тип әйтәбеҙ инде, тигәндәр, шунан Бычок ҡушаматы киткән. Хәҙер ул йегет тә күптән үҫте инде, ҡайһы саҡта Тана тип тә көләп ҡуйалар.

Балаға исем ҡушҡанда Сәнә доғасы уҡыла, шунан Салауат әйтелә. Уң ҡолағына исем-шәриф әйтелә. Мин инде өс мәртәбә әйтәм дә, өрәм. Һуңынан сул йағына әйтәсең, аҙаҡ изге теләктәр йеткерелә. Был Ибраһимдан килә (Авраам). Ҡорбанға йараҡлы хайуандар – кәзә, сарыҡ, дөйә, сыйыр. Бер һүҙ менән, ике тойаҡлы хайуандар. Сарыҡ мотлаҡ бер кеше исеменән генә салына. Сыйырға, дөйәгә йете кеше ҡушыла. Һуңынан ҡорбан таратып бирелә. Ҡорбан да ике төрлө була. Нәзир ҡорбаны була, ул ашалмай, күрше тирәләргә һәм мохтаждарға таратып ҡына бирелә. Беҙ һәр ваҡыт Ҡорбан ғәйеттәре үткәрәбеҙ, халыҡ күп йыйыла.

(Саникина Сулпан Рауил ҡыҙы яҙып алды).

### Нәфиҡова Әминә Сабир ҡыҙы, 1941 йылғы

Сығышым менән ошо Ҡандранан сыҡҡан, Әйтәктамаҡ ауылы. Килен булып төштөм. Уҡыманым, белемем йуҡ.

Тарихы буйынса, бында ике йөздән артыҡ өй булған. Мин бер мең туғыз йөз алтмыш беренче йылның туғызынчы майында күщеп килдем. Бөтен өйдә дә йәшләр дә, ололар да бар иде. Ауыл гөрләй иде. Элек ауыл йанғащ, бында күскәннәр. Иң беренще бер генә йорт булған инде ул. Безнең йорт бик зур булды, ул кулаклардан алып салынған. Бер йағында ғына дүрт тәзрә иде. Иң оло өй безнеке булды. Кистәрен бөтөн ауыл безгә килә иде. Әбиләр шунда таҡмаҡларын да, мөнәжәтләрен дә әйтә иделәр. Шунан бейеп тә алалар иде. Мин шуңа да мөнәжәтләрне белеп үстем. Мөнәжәт көйгә салынмый, былай ғына әйтелә ул.

Без табында иң беренсе туҡмаслы аш бирәбез, аннары ит белән бәрәңге, шуннан бәлеш. Азаҡ чәй, компот. Бәлешнең дә төрлөсө була. Рис, изюм белән. Элек безнең әнийләр икенчеләй әзерләгән. Иң башта ҡаз итен тураған, ҡазанға салып, жиңелчә издергән, азағынан ала, ул йомшара. Шунан шушы шурпада рисын бүрттерә. Аннары рисы белән итне болғап, ҡамыр эсенә тутыра. Өстөнә өрөк сибәбез инде. Элек гөбә дигән нәрсә булды. Майны шунда туңдыра идек. Ит бәлешен дә шулай әзерләп була. Бәрәңгесен ҡайнар суға саласың да, күбекләнә башлағач, ит менән аралаштырып, щығарып ҡуйасың. Бер нәрсә дә булмый. Сәйгә без гөбәдийә әзерлийбез. Ул рис менән була. Иң башта рисны бүрттерәсең, жимещен йыуасың, икесен бергә бутыйсың. Азағыннан ҡамыр өстөнә жәйеп салып, өстөнә шикәр, сары май салып, бешереп ҡуйасың.

Сөт аҙыҡтарынан: ҡатыҡ, эремщек, ҡорот, май иретәбез. Ҡызыл эремщекне әзерләр өчен эремщекне ҡайнатып алыр кирәк. Эремщеге төшә бит инде. Икенче кәстрүл алып, шушы сыуын алып, эремщекне суы бөткәнще ҡайнатабыз. Сөтнө башта ҡабартып чығарам, азаҡ күкәй белән ҡатыҡ салып, ныҡ ҡына болғатсаң, эремщек була. Ҡайнатсаң – ҡызыл эремщек була. Эремщектән пирожкилар пешерәбез, бик тәмле була.

Скалка – аҡлау, табаҡ – табаҡ, кәстрүл – мискә, щәркә – ағачтан ҡорып йасалған сауыт, чашка – йомро, ҡалаҡ – аш ҡашығы, чәй ҡашығы, сәйнүк – щәйнүк, сүмес – аш, су щүмесе, мейес – мөржә, пич. Кисәү ағасы – мейес болғатыу тайағы.

Нindий төш күрәбез, шуңа йурыйбыз. Ышансаң – тап килә ул.

Үтеп барған ҡара песигә хәйерле йул теләр кирәк, ҡаршыға эт осраса – уңышлы була. Песи – безнең өсөн дошман.

Корова – сыйыр, быҙау – бызау, үгеҙ – үгез, һарыҡ – сарыҡ, тауыҡ – тауыш, себеш – чебеш.

Мәүлит бәйрәме үткәрәбез, бик күңелле үтә ул. Ул Мөхәммәт пәйғәмбәрҙең тыуған көнөнә бағышлап үткәрелә. Рәбиғәл-әүүәл айының ун икенще кищәсендә үткәрелә. Шуңа арнап йыл сайын Мәүлит үткәрелә. Мөнәжәтләре дә бик күп аның.

Рәғәип кисәһе лә үткәрәбеҙ. Кисен башлана, икенсе көнөнә көнө буйы дауам итә. Айат уҡып, бында шундай мөнәжәтләр әйтәбез:

(Саникина Сулпан Рауил ҡыҙы яҙып алды).

## ТУҠМАҠ-ҠАРАН АУЫЛЫ

### Вәлиуллин Әмир Шайсолтан улы, 1938 йылғы

Туҡмаҡ-Каран ауылында туғанмын. Анда башланғыщ мәктәпне бөткәщ, Аблайның жиде йыллыҡ мәктәбен бөтөп, аннары Октябрьскиҙа ун класын бөттөм илле алтынщы йылны. Уфада электромеханический техникумды бөтөрдөм. Төрлө урында, төрлө должностә эшләргә туры килде. Туҡсан сигезенще йылдан бирле пенсиядә, ауылға күщтем, ҡайттым.

Халыҡның эщкән суы Ҡаран шишмәсенән булған, аның щыҡҡан жире тау башы туҡмаҡ кебек булған, шуңа күрә Туҡмаҡ-Ҡаран дип атағаннар ауылны. Анда башҡортлар, татарлар йәшәгәннәр инде. Башҡортлар нигез салған. Татарлар бер мең жиде йөз утыз туғызынщы йылны договор белән кергәннәр, сентябрь айында

эшлекле татарлар, тегүщеләр, сауҙагәрләр һәм башҡа һөнәрле татарлар килгәннәр. Ауыл зур түгел ийе, безнең ауыл илле дүрт йорттан килә. Ауыл бәләкәй безнең. Безнең ауыл бик матур урында урынлашҡан, болонлар, урманлар, жиләк-жимеш күп, ҡымыз йасағаннар. Безнең ауыл бик күренекле булған. Шуның өщөн Уфадан йазущылар утызынщы йылларда семьялары белән килгәннәр йал итәргә, ҡымыз эщәргә. Сәйфи Ҡудаш, Ғайнан Әмири, Шәрифйән Ченбарисов. Ауылда йәшәп, ауыл халҡына йәрдам итеп йәшәгәннәр. Ауыл халҡының кереп ҡалған историясенә: Ҡымыҙ өйө арты дип йөрөйләр болонларны. Анда атларны асрап, шунда ҡымыз йасағаннар утызынщы йылларда, әле алтмыщынщы йылларда йасыйлар ийе, мин беләм, барып ҡымыз эщеп йөрөйдер ийек. Халыҡ без үскән ощорда йортларда йәшиләр иде, салам түбә белән йабылған барсы да, ихаталар щитән белән уратылып алынған ийе, урам йаҡлар таҡта ҡойма, ә ихаталар, башҡа йерләр щитән белән.

Ауылның мәщете лә бар ийе заманында. Ул мәщетнең манарасын утыз жиденче йылны кискәннәр. Халыҡ ҡаршы килеп жыласа да, бер нәрсә дә эшләй алмаған ауыл халҡы. Аннары анда клуп йасадылар. Мына клуп булған щорно мин йаҡшы беләм. Анда спиктәкләр ҡуйып, кинолар ҡуйып йөриләр ийе. Без үскәндә, бәләкәй щаҡта.

Печка – мищ, ул кирпищтән. Ипи пешерергә, ущағы бар, ҡазан. Ул ҡазанда аш пешерәләр ийе. Шул уҡ ҡазанда йаңадан щәй дә ҡайнатып алалар ийе. Самауыр бар ийе. Күмер булды, ағащ күмере. Ҡалайдан йасалған сауыт бар ийе ҡапҡащлы. Шунда күмер жыйалар ийе. Көл жыйалар ийе. Ансы йорт сайын задание.

Щабата кейдек. Күтәрмәле щабата, пима булды. Әткәй безнең бик хәстәрле ийе. Бик тырыш кеше ийе. Барыбызға ла итек бастырып, йыл сайын ике кешегә тун тектерәдер ийе. Өс-баш былай бар ийе. Безнең әткәй суғыш уаҡытында Польшада булған. Ул шунда бик ғәжәйеп бер техника күргән. Шуны исендә ҡалдырып, төзөлөшөн өйрәнеп, суғыштан ҡайтҡащ тегермән йасый. Бу тегермән гел ағащтан ғына булса да, бик әйбәт килеп щыға, ике ат, вертикаль тәгәрмәщтә зур, алмаш-тилмәш тупсаға басып торалар, шулай иттереп теге механизмны хәрәкәткә килтерәләр, тегермән эшли башлый. Бу тегермәнгә йөрүще кеше күп булған йаҡын-тирә ауыллардан. Колхозға кергәщ, бу тегермән йуҡҡа щыға. Суғыш ощоронда ҡартлар, хатын-ҡыз көщө белән Өсән йылғасын буып тегермән салғаннар. Бу тегермән салуҙа күп жиһаз Исламов Сәләхетдин ҡул астында эшләнгән. Ул бик йахшы һөнәрще булған. Шуның белән ауыл халҡы интегеп тегермәнгә башҡа йергә йөрөмәгән. Үзебезнең ауылда тегермән булған. Суғыштан соң өщ ауыл Туҡмаҡ-Ҡаран, Аблай, Бәтке колхозщылары көщө белән Ыҡ суындағы буаны бикләтеп, нығытып электр станция төзөдөләр. Аларын мин йахшы беләм. Өщ ауылда да электр лампочкалары йана башлады. Бу Аблай электр станциясы турында бер мең туғыз йөз ҡырҡ сигезенче йылның алтынщы ноябрендә журналист Бикбай бик зур статья йаза. Ул йаҡтыртып китә ауыл тормошон, шулай уҡ колхоздағы йаңалыҡнарны йазып китә. Бу гәзит әле бездә саҡлана. Бар ул, бик зур статья. Бына шундай хәлләр.

Безнең бабайлар, аҡ бабайлар башта Сыған буйына утырғаннар, Сыған дип аталына Кәкребаш белән Туҡмаҡ-Ҡаран арасында, ике шишмә арасына утырғаннар, ул архив буйынща Ғауыл дип аталған. Шунан алар йаңадан күщкәннәр Ҡаран шишмәсе ҡырына. Ҡаран шишмәсе ҡырында бер аз йәшәгәщ, аны ауыл халҡы хәзер ул урынны Иске йорт дип йөрөтә, аның без үскәндә баз урыннары, йорт урыннары билгеле ийе, күщеп ултырғаннар Өсән буйына. Өсәннең Ыҡҡа ҡушылған тирәсенә утырып, шунда Туҡмаҡ-Ҡаран ауылы барлыҡҡа килгән инде.

Минең белгәнщә, мин – Рәхимҡол нәселе, Миңлеғол бабай – аҡ бабайларыбыз, аннары Рәхимҡол, аннары Вәлиулла, бу минең бабам була инде. Без башҡортлар, Ҡырғыз ырыуынан. Рәхимҡол бабайның жиде улы була. Алар бары да Туҡмаҡ-Ҡаранда урнашҡан булалар. Ул жиде улының да минең щерновикта шәжәрәсе бар. Ә шәжәрә төзөдөм шуның Шәрифулла улына, Вәлиулла улына. Ә Вәлиулла минең бабам була, әткәйнең атасы.

(Сәғитова Айгөл Ғәни ҡыҙы яҙып алды).

**Насыров Әҙип Ғабдулла улы, 1951 йылғы**

Бу Туҡмаҡ-Ҡаран ауылы үзе бер колхоз булып, элек шулай булған бит инде, бик күп маллары булған, тормошлары әйбәт булған. Шуға бик шатланған, ауылда балаларның тамаҡлары туйыр, дип килгән, щөнки аларның шишмәләре бар, бик матур, тәмле сулы шишмәләре булған, ике йылға ауыл ҡырыйында аға. Ҡиблаға ҡарап аҡҡан Ҡаран шишмәсе. Тирә-йаҡта ауыллар ҙа күп булған, урманнар, имән урманнары, ҡайын урманнары. Элек бит инде әрәмәләр Ыҡ буйында, тал-щыбыҡ, утынға интекмәгәннәр, суға интекмәгәннәр. Мына минең әтийемнең абзыйы председатель булып торған суғыш ваҡытларында. Халыҡны ащ тотмаған. Атлары күп булған, тауыҡ фермалары булған. Үзләренең тимерщелеге, ындырлары ашлыҡ суға торған. Шул хәтлем бай йәшәгәннәр, бай тип, мул йәшәгәннәр. Халыҡ ащтан интекмәгән ул ваҡытта, суғыш ваҡытында. Әтийем сөйләүе буйынща, йегерме беренче йылларны бик алый уҡ булмаған. Бик тарҡау ваҡыт булған йегерме беренче йыл. Күп семьялар ащлыктан үлгән. Әтийемнең бер энесе, бер абзыйсы ащлыктан үлгән. Әбекәй шулай ризыҡ эзләп щығып киткән ваҡытта алар көтөп өлгөрмәгәннәр шулай. Бабҡам ауыр щирләп шул уҡ йылны китеп барған. Бабҡам – әтийемнең әтисе Ғәбделнасир. Бабаҡай дисәң дә була.

Шишмәләр күп булған. Ул уаҡытта, алтмышынщы йылларны бездә сарыҡ бик күп ийе. Шуңа шишмәләр ҡырыйындағы ағащларны ҡороткащ, шишмәләр ҡородо. Күп шишмәләр ҡороған, бәләки шишмәләр. Сығын тауы бар, безнеңщә Сығын тауы, диләр. Сығын урманы, дибез инде, Саҡлау урманы. Анда ҡайын урманы, әрәмәлек инде. Саҡлау, щөнки ул ваҡытта Саҡлауға щаҡлы, басулыҡ булған, посадкалар утыртҡанщы басулыҡ булған. Элек бит инде басуларға керергә йарамый. Щоҡор буйлап ҡына кереп көтөүлекләрне шунда топлаған булғаннар. Ул ҡайынлыҡ әле ҙә бар бик матур. Гөмбәләр жыйабыз анда. Гөмбәләр бик күп. Ҡара грузь, аҡ

грузь, ҡоро грузь. Элек жыйадыр ийек волнушки, сыроежкиның йегерме дүрт төрлөсө бар. Аны жыйадыр ийем. Щоҡорлар зерә күп. Безнең элек тауыҡ фермасы бар ийе, ныҡ щоҡор ҡырыйында ҡалды. Сығын щоҡоро өщ километрға сузыла. Шаран районына щаҡлы барып теркәлә аның башы. Ҡоро щоҡорлар ике йаҡҡа йарылып киткән ине. Хәзер ошо посадкалар саҡлый. Нарат тибез, шыршы бар, ансы елка. Шоморт бар. Ҡарама бар. Ҡарама Ыҡ буйы, Өсән буйында зерә күп. Өсән буйында усаҡ, ҡарама, эт шоморто күп. Өсән йылғаһының тарихын әйтәлмайым.

Боярышник – ҡамыр жимеше тибез инде, шиповник – гөлжимеш, земляника – жир жиләге. Ҡайын жиләге бар. Уның аромат икенще. Ҡайын тирәсендә генә үсә. Мин һәр ваҡыт жыйып апҡайтам. Клубника – баҡса жиләге тибез. Ул безнең үзебез ултыртҡан жиләк бит инде. Черемуха – шоморт, лягушка – баҡа тибез, жир баҡасы бар безнең, бәрәңге щоҡоғанда килеп чыға, су баҡасы бар, ул йәшкелт, теге кисләрен жырлай торған баҡа анысы, змея – жылан, тузбаш жылан бар ишек алды тулы. Ҡойашларға щығып, жылынып йата таш өстөндә. Ҡара жыланны күргән йуҡ. Әйтәләр, бар дип. Отец – беззә этийем диләр. Минең баллар этийем диләр. Ә мин эткәй дип өйрәндем. Мать – әнийем, әнкәм, дедушка – бабҡай, бабыҡай, бабҡам – минең бабайым, этейҙән өлкән кешегә абзыҡай, дибез, тетя – түткәй диләр, түтәй тибез, апа ла дип әйтәбез, бабушка – әбекәм, әбекәй, әбекәйем,килен кеше ирнең этисенә этей, эткәй, әнисенә әнкәй, ди, братишка – эне, быстрина – ағым су, дип әйтәбез.

Безнең бер абзыҡайыбыз бар ийе. Ул шәжәрә төзөгән. Әнкәйемнең әнисе йаҡлап бу. Шул Ләбиб абзыҡайның үрнәк булып торзо безгә. Минең инде күптән үземнең бар ийе, этийем әйтәдер ийе, улым, син жиде быуынны белергә тийешсең. Аны балларыңа ла әйтеп ҡуй. Мин аны истән щығарманым. Мин өщ быуыннан алып төзәй башладым. Былтыр бик күп йөрөргә туры килде. Мин таптым өщ йөз зә алтмыш кеше. Безгә килеп йөрөгән кеше эткәйнең иң оло апасын, Латифа исемле, мин аны табалманым. Бу шәжәрә ағащының тамыры башлана Ғәбделвәлинән. Ә бабҡам Ғәбделнасир, аның туған йылы ла бар. Аның ике хатыны булған. Алар ун ике бала булған. Шуларны эзләп йөрөдөм архивларда.

(Сәғитова Айгөл Ғәни ҡыҙы яҙып алды).

## ТУҠТАҒОЛ АУЫЛЫ

### Фазуллин Әдүнис Мөсәғит улы, 1946 йылғы

Туҡтағол ауылының тарихына килсәк, Әнүәр Әсфәндийәровның йазмалары буйынща да, Башҡортостан Республика архивының белешмәләре буйынща, ул бер мең жиде йөз илле икенще йыл булып күренә. Ике мең йегерме икенще йылны ике йөз житмеш йыл була ауылға. Ауылның тарихын мин ул ҡәҙәре бер нещкәлекләренә барып житә алманым. Мына ул булған башҡа урында Иске ауыл дигән. Бабайларның сөйләүләре буйынща, бер урын булған анда йаланнан щығып, мында күщеп ултырғаннар. Ауыл ике өлөштән торған. Тау урам дигән урам – ул Типтәр урамы дип йөрөйдрийек. Анда инде типтәрләр килеп ултырған булған, жир алып мында Иван Грозный заманындағы ҡуылғаннар килеп ултырып. Бу йаҡлары башҡорт булып йөрөгәннәр, мына без үзебез башҡорт булып йөрөйдрийек. Минең жиденще буын, ул бит перепись населения бик ҡызыҡлы нәрсәкәй: бер переписта ауыл татар дип йазыла, бер переписта башҡорт булып бөтә. Шуның өщөн анысы безгә ҡараңғы, әммә ләкин мин үзем уҡырға кердем мең туғыз йөз илле өщөнче йылны беренче класҡа, без уҡыдыҡ гел татарща иттереп, унны бөткәндә дә татарща бөттөк. Без химияны ғына рущща уҡыдыҡ. Мин үзем аграрный университетҡа кердем, анда химияны бишкә, ә физиканы татарща уҡыдыҡ без, татар китаплары белән. Баш ҡалабыз Ҡазан дип уҡырға туры килде. Без инде нәрсәкәй, ниндәй китап биргәннәр, шуны уҡығанбыз, сайлап алырға мөмкинлек булмаған. Физиканан еврей уҡытыущы ҡабул итә, мин татарща ғына сүлим бит инде, өщлө ҡуйды ла щығарып йебәрде инде.

Тарихи йаҡтан бик бай ауыл бу, аның хажға йөрөүщеләре дә булған, сәүдәгәрләре дә булған. Революциядан соң кеше бик кәмсетелмәгәннәр инде, бер-ике ғаилә генә тарҡалған, күпләре күщеп китәргә мәжбүр булғаннар. Безнең ауылдашлар утыз алтынщы йылларда Приморский крайға бик күпләп күщеп киткәннәр, Баймаҡ районына күщеп киткәннәр.

Әле бүгенгесе көндә Киров шәһәрендә йәшәй безнең мең туғыз йегерме алтынщы йылны тыуған Абудуллин Тимерйән дигән абый. Ул ун жиде йәшендә суғышҡа китә ҡырҡ өщөнщө йылны, суғышны ике миҙал, орден белән тамамлап, Ленинградның Киров исемендәге медицина академиясында уҡып бөтә. Фәнни эшкә кереп, доктор медицинских наук, заслуженный врач Российской Федерации, лауреат государственной премии СССР. Киров шәһәрендә ул секретный Министерство оборонының академиясында начальник була, генерал-майор. Әле исән, сәләмәт тормош алып барған кеше. Дүрт кеше Ленин ордены белән бүләкләнгәннәр безнең ауылда.

Щағыу тауы бар. Шар таулары дип аталған урыннар бар. Кәжә тауы текә генә урын инде. Шифалы шишмә тауы. Ул ултырған булған Нөгөш буйында Туҡтағол-Нөгөш дип аталған ул ауыл. Йанғаннар, аннан мында килеп күщеп утырғаннар. Щоҡор-щаҡырлар бар инде, Кәдеш щоҡоро, Арҡылы ҡул. Исемләрен ни өщөн икәнен кем белә инде, ата-бабадан күщеп килгән инде.

Революция ваҡытларында мында аҡлар да килеп кергәннәр, талап киткәннәр. Ҡызылдар да килеп кергәннәр, талап киткәннәр, щөнки мында бер ун ике километрдан Казнаковка дигән ауыл бар, йул Ҡазанға табан киткән булған. Ауылдан күп кенә кешеләр суғышта ҡатнаша өщ йөз иллеләп, әлеге көндә өщ йөз илледән бер абый ғына исән инде. Ҡалғаннары йартысы йатып ҡалғаннар, йартысы ҡайта инде. Ә Башҡорт кавалерия

дивизиясында старший политрук була Ғәрифуллин Ғелми. Ул Шайморатов белән бер вак̣ытта, бер көннө һәләк булалар.

Икенщесе Ғайсаров Юныс Харис улы, беренще колхоз председателе, комсомолның йуғары мәктәбе директоры, аннары Ленин музейы директоры булып эшләй. Суғышта старший политрук булып, өщ орден алып, Смоленскийда к̣ырк̣ алтынщы йылны бер бандит формированиясы белән алышк̣анда һәләк була, суғыштан исән щыға.

Өйәнке, нарат, щыршы, к̣айын, усак̣, ситләүк ағаслары, миләш, щаған, йүкә үсә.

Бездә Бәләкий Нөгөш, шунан мында бер бәләкий генә йылғащык̣ бар инде, аның исеме дә йук̣.

Бүре, төлкө, бурсык̣, к̣уйан, енот, су к̣ондозы, йомран, әрлән, сусар (рысь) бар.

Ак̣ эремщек, к̣ызыл эремщек, к̣атык̣, ак̣ май, сары май, кәзә сөтөннән – к̣ымыз, сарык̣ сөтөннән брынза да йасайлар.

Бәлеш, к̣ыстыбый, тәбикмәк, к̣оймак̣, кәкре (бәрәнге белән пирог), щәк-щәк.

Угол – пощмак̣; мешок – к̣апщык̣, ток̣; хлеб – икмәк, ипий; ведро – бидрә; воробей – щыпщык̣; боҙ өҫөндә к̣алк̣кан һыу – шәр; остров – утрау; салауат күпере – салауат күпере;

Һунарсылык̣: к̣апк̣ан, тозак̣ (петля).

Балык̣сылык̣: ау, йәпмә, морза, дөмбөрө, щәнщке.

Балык̣тар: щуртан, алабуға, к̣ара балык̣, йоморк̣ай, щабак̣, к̣орбан балығы, табан, шамбы, шыртлак̣а.

(Йомағужин Айҙар Ғариф улы яҙып алды).

## ТҮБӘН БИШИНДЕ АУЫЛЫ

### Ғиззәтуллин Шамил Ғәзизулла улы, 1942 йылғы

Ауылның аңлатмасын әйтәм. Бөтәсен дә сорай инем. Бер кем дә дөрөс йауап бирмәне. Йетмешенще йылларҙан. Перепись населения булды бит. Туймазы районында булды мына. Мин инспектор по статистике переписи инем ул вак̣ытта. Мин аны үткәреп, автобуск̣а ултырып, Уфаға барып, Цюрупала сдавать иткән кеше.

Сиксән йетенще йылда экспедиция буйынща бөтә китаплар бар. Шушы к̣ырк̣лап руннар бар. Әйле, Дыуандан, Йыланлынан килгәнләр. Без – Әйлеләр. Есаул ауылын обосновать итәләр. Арслан ауылы ла Бишинденән сык̣кан. Был руннарҙы ук̣ыр кәрәк. Аны асып ук̣ыр кәрәк. Бер китап бар. Ну анда тулы түгел. Мин барысын да тулыландырып малайларыма к̣алдырам. Оло малайыма, тултырып, илле йыллығына бирҙем.

Китапта барысы ла бар. Договорлар килтерелгән, архив материаллар. Перепись материаллары бар. Мына К̣орғәле Алтын Урҙа вак̣ытында йәшәгән кеше. Анан китә-китә килеп щыға Бикташ бабай. Аның внуклары Бишиндене обосновали. Бикташ бабай Сармат малайы, малайлары, ул Әй буйларына йак̣шы тормош эзләп щығып китәләр. Төрлө нәмә күргәндәр. К̣азанға барғанлар. Ханлык̣к̣а барғанлар. Кире к̣айтк̣аннар. Бикташ бабай был китаптарҙа мең бищ йөз дә илле бищенще йылда асаба башк̣ортлар менән договор төзөгәннәр. Улар алдан да килгәнләр. Туймазыла ауыллар күп булған. Әйле башк̣ортлары килеп йәшәй башлағанлар. Күптәр күпне белмиләр. Башк̣ортлар обосновали. Спорный вопрос ул. Әйле волосы бит анда обосновали. К̣ол Ғәли әйленеке. Алар инде барып тоташа.

Әйленән килгән бер нәсел. К̣азантамак̣ ауылы йырағырак̣ ул. Без анан килгәнбез. Ук̣ытыущылар булды, китап йаздылар. Ғәйнетдинов йазды инде. Әммә эшләр тик автобиография кеүек. Минең Сәлихә әнейҙең йак̣ынлары әйленән килгән. Советты ойошторған кеше. Сталин вак̣ытына йәшәгән кеше.

Ауылның тарихы тауларға тартылып тора. Без тау арасынан генетически. Дыуанлар ана средний тауларҙан. Беҙ тауларға тартылғанбыз. Мына шул тәбиғәттә белгертәләр инде. Мин малайыма к̣алдырам. Тышк̣а щык̣сам, йә азербайджанса, йә русса сөйләшәләр. Татарса белмиләр. Ата-бабаларын белмиләр. Шуға мин йегерме биш нәселне эшләдем. Минең балалар мыны беләщәктәр. Был ауыл шәжәрәсе. Был четвертый номер шәжәрә. Рәшидә ханым килгән ине, аны иске вариантын күрсәттем.

Суфиян Сафуанов мына йазған, дөрөс түгел. Мин материалдан выкопал. Шамиғол шәжәрәсе зур бит ул. Бына бу папкады сирәк асам. Мына бу – Бишинде ауылы шәжәрәсе. Бөтөн ауыл бер кешенән щык̣кан. Бикташ бабаның балалары таралған. Революция була, кемгә нәрсә бүленеп бирелә шулай. Мына таблица эшләнем.

Был китап – алмаштырғысыз материал. Бикташ, мына Сәрмәт, Сәрмәттең балалары –Мораҙым һәм Әмир. Китаптарҙа Ресмәт тип йазалар. Дөрөс түгел ул. Бикташ – К̣әзермәт – К̣олғәзей – Мандык̣ай – Ниғмәтуллиндар сыға анда. Ауылғазый һ.б. Китә-китә, китә-китә бабайларның тамғалары бар. Мандык̣айҙың мына. Башк̣ортлар бит азак̣ к̣ына килеп к̣ушыла.

Безнең ағащ – к̣арағащ. Тамға – тарак̣. К̣ошо – к̣арағош.

Мосолман диненә күщкәщ, щәщтәрен кищкәнләр. Исемдәр шундый көщлө. Мына указлы муллалар. Мына красная линия, ихаталар ултыра. Указлы муллаларны аталар бит инде.

Түбән Бишиндегә төшеп китә Таймаск̣а. Бүздәктә Нөгөш буйында Йәрмөхәмәт ауылына төшөп китәләр. Договор төзөйләр. Анда к̣арт булған. Малайлары кире киткәнләр. Таймаслылар килеп щыға. Тарих ул к̣ызык̣ нәмә ул.

Мин ашығам, но йарзамщылар йук̣. Тасмас, Тойғон, Муртаза, Бикташ булған. Был ун сигезенще-ун туғызынщы быуаттарҙа йәшәгән. Тойғоннан ике малай килә. Ғизәтулла, Ниғмәтулла. Анда номерлары бар. Ревизская сказкаларҙа вис бар. Анда бар ҙа бар. Мына ауылның тарихы. Мына алар кире әйләнеп к̣айтк̣анлар.

Бикташның Ибрай дигән малайы нәнәй йеренән бер группаны алып ҡайта. Бүздәк районында бер ауылны обосновали. Малайлары безнеке, асаба. Улар бик актив булышалар, йерне эшкәртәләр.

Йер-сыу атамаларына килгәндә. Урам исемдәре – Ишәле щоҡоро, Ишәй бабай указлы мулла. Мораҙым дибез, Мораҙым йере булған. Самсоҡ сыуы булған.

Биш инә дип йөрөтөлә, бишәү инә – биш инә. Инеш – ул источник. Улар ҡушыла. Йылға ҡушыла. Бишинде ауылның исеме килеп сыға. Бишәү ингән – инеш барлыҡҡа килә. Биш источник бар – Самсоҡ һыуы, Моңло ҡамыш, Мораҙым, Ҡаран, Бишинде йағынан килә, Иманғолдан килә. Мына ҡушылып, Бишинде инеше барлыҡҡа килә. Ауылдың исемен шунан ҡушалар. Түбән Бишинде ҡырҡынсы йылдан ҡушыла. Үрге Бишинде йегерменще йылларда барлыҡҡа килгән. Минең фараз дөрөс, дип исәпләйем.

Ул исем ҡайһы ваҡытта ҡушылған. Ул Чингисхан бүлгәндә бирелгән. Административное деление булған ул. Аның өщөн урман, тау, ҡалҡыулыҡтарға исем бирелә. Анда карта йуҡ. Бүлеп бирәләр. Йылға аға бит инде. Йул йуҡ. Йылға буйынща сәүҙә иткәнләр. Билдәләгәнләр.

(Хужахмәтов Айнур Оскар улы яҙып алды).

## ҮРГЕ БИШИНДЕ АУЫЛЫ

### Раупова Нәжибә Мырҙагәрәй ҡыҙы, 1941 йылғы

Бер генә урам бездә. Йул ғына бүлеп тора. Был йаҡ – Бишинде, был йаҡ – Ҡаранды. Йылға бар. Шишмә бар. Бик матур ауыл. Файзалы шишмә бар. Кешеләр килеп су алалар. Фәррәх Йосопов дигән кеше лесник иде. Анда ағас йуҡ ине. Хәзер ағас күп, жиләк күп. Быйыл жигерме бизрә жиләк йыйдым. Урманда гөмбә үсә. Бында тыуып, бында үскәнгә йаҡын. Сабантуй булды.

Бабайлар буйынща, Айыу басты дигән ҡушамат бар. Даутовларның ун ике баласы бар. Даут – соҡор тауыҡ, дип үсекләйләр иде. Минжан, Унжан, дип балалары атта жөрөр өсөн әйтәләр иде. Атайым лесник ине, Урмангәрәй, диләр иде.

Бәрәмәщ тауы бар, бәрәмәщкә оҡшаған. Ҡызлар тауы бар. Тигез генә урын. Уйын була иде. Суыр тауы бар. Суыр тауында сусуырлар сайрый иде.

Элек “Ҡарағош йауы” дигән китап бар иде. Анда вис тарих бар иде. Граждандар суғышы турасында. Элек уҡытыущым уҡыған иде.

Элек бай колхоз булған ул. Умартасы да булған. Тукай колхозы. Суғыш ваҡытында ике шәп айғырны алып киттеләр. Без икенщедә уҡый инек. Ҡашҡар иде. Суғыш ваҡытында суған килтерәләр иде. Биш йәшлек бала бит инде, әнкәй менән бара идек. Машина күрдем тәүгә. Килтерәләр иде. Әткәй суғыш башында киткән, ун йылдан ҡайтты. Разведчик булған. Командирдары тезгән дә атҡан. Пленға төшкән. Йафаланған иде.

Ҡаранды әйтәләр инде, ҡара урман булғас, Ҡаран дип әйткәнләр. Ҡаран Бишинды.

Ширмищләр булған, сувашларны шулай дигәнләр. Мари ҡызын берәү ауылдан урлап алып ҡайтҡан. Дүрт әбей – ширмищләр, шулар арҡасында Ширмищ дип атаған. Биш бабайзан беләм иде. Бишесен дә беләм.

Әнкәйем ураҡ урғанда урманда йаулығы төшөп ҡалған да, кире алам дисә, йылан мөгөзөн ҡалдырған. Ғаиләсе зур булған. Бер кеше йыланды үлтергән, суҡҡан икән, ҡабығы төшкән. Шунан суҡырайа. Йылан ҡабығынан кеше суҡырайа. Әткәй элек суғышҡа киткәндә өйзөң тотҡасы да булманы. Элек бикләнмәде өйләр.

Йылан ағас башында балалар тузыра икән. Атыу балаларын ашай икән.

Әнкәй әйтә иде, ағымға ҡаршы йөзмәгез, дип, ҡанатығыз тала, дип.

Ике апам үлде ауырып. Суғыш башланғанда дүрт ай булған. Керосин лампасы була иде. Йандыра идек. Щабата йасарға өйрәнде әнәкәй жилый-жилый.

Ҡызлар киләләр иде аулаҡ өйгә. Төнгә жыйыла иде.

Калинка, калинка моя,

Синең ыштанын ҡайда, дип жырлыйлар иде.

Ҡышын бәрәнге алалар иде. Жәйен йаланда эшләп ваҡыты булмаған. Бәрәңге тәмләнгән була иде. Тире өстөндә йоҡлай иде. Кейем киндерзән иде. Һәр кем киндер үстерә иде. Мәк үстерәләр иде. Зепе тамыры (ко́рень бересклéта) ала идек, шуны сдавать итсәң, керосин, бензин бирәләр иде. Бесән жыйа идек. Атлар суғышҡа киткән, үгезләр менән эшләгәнләр. Бер үгезнең ҡойроғо йуҡ иде. Йәнләре көйөп сындыралар иде.

Әткәйем лесник булды, ағас кисергә ҡушмайлар иде.

Ышаныулар бар. Йамғыр, ҡар йауғанда теләктәр теләйбез. Йен-пәрейгә ышанабыз. Азбар эйәсе бар.

(Хужахмәтов Айнур Оскар улы яҙып алды).

### Сафина Рәғинә Зөфәр ҡыҙы, 1956 йылғы

Маржа үлгән жалан бар. Ике версия бар. Суғыш ваҡытында бер маржане үлтергәнләр. Берәү версиясы – ул урманда азашҡан.

Мулла ҡыуағы бар. Мулла барып уҡығандыр инде.

Сайыщҡан ҡыуағы бар, сайыщҡанлар күп.

Типтәрләр Жәнәй дип йөрөткән. Әй йылғасы буйынан килеп ултырғанлар. Бишинде йылғасы аҡҡан бит иде. Ҡушаматы – Жәнәй. Биш ғаилә килеп ултырған. Урта һәм Үрге Бишиндегә бүленгән. Күсеп килгәндәр налог түләгән. Биш ғаилә – Бишинде инде. Шуға әйткәнләр. Бөтөн Бишинде туған. Безнең ауылда.

Бишинде, Бишинде,
Биш йеренә тишелде, диләр иде.

Кәкре – ул ризыҡ, шулай диләр. Бәрәңге менән ҡамырға урайсың. Щүмещ. Ипий – икмәк.

Әнекәй. Әтекәй. Әнейем. Дуринәй. Дуритәй. Түткей – апа (ҡатын-ҡыз) уҡытыусы. Абзыҡай (ағай). Апай – бәләкәй кеше. Апа – оло кеше. Үскәнем, диләр.

Сыйыр бызауласа, азбар эйәсе ишек шаҡый, ди иделәр. Барыбер ышанабыз иде. Мунса эйәсе бар иде. Ун икенән суң мунса бармыйбыз. Ҡойаш байығас, быщраҡ суны түкмәгез, диләр. Ҡунаҡка киткәщ, өй жыйыртырмайбыз. Баш кейемен өстәлгә ҡуйырға йарамай, диләр.

Жиләк, щийә жыйабыз. Щәтлеүек бар. Шоморт, миләш жыйабыз. Балан бар. Ҡаҡ ҡойабыз. Ҡорот ҡойабыз иде. Домашний сыр йасай идек.

(Хужахмәтов Айнур Оскар улы яҙып алды).

## ӘТЕК АУЫЛЫ

### Яушев Даим Ғәни улы, 1938 йылғы

Әсфәндийәров китабында әйтелә, беренще урынлашҡан кешеләр, дип әйтелә. Дүрт ғаилә килә. Өйләндерәләр. Күрше ауылдар менән ҡозалаша. Архивтарҙа информация йуҡ.

Ауылда ныҡлы кешеләр йәшәй. Революцияға диклем. Бер-нищә мулла булған. Указный мулла булған. Кеше күп булғас. Коллективизация башланғащ, ҡарар щығаралар, байҙарҙы тәртипкә килтерергә. Шунан башлана инде раскулачивание. Бездә ауылда утызынщы йылларда башлана. Бына миңә ҡағылған нәселде ҡарасаҡ та. Унан алда зурыраҡ информация әйтәйем әле. Яңауылда жите йөзгә йаҡын кеше документально репрессияға эләккән. Күбесе ике тапкыр эләккәнләр. Утызынщы-утыз беренще йылларда сөргөнгә йебәргәндәр ҙә, өс-дүрт йылға ғына быларҙы эшкә йеккәнләр. Утыз дүртенще-бишенще йылларда кире ҡайтҡанлар.

Йаҥынан тормош ҡора башлайлар, утыз житенще йылларда тағы ла ҡатыраҡ закон сығаралар. Иҥ йуғары жаза – үлем. Ун йылдан да йуғары бирмәйләр. Безнеҥ әнкәйләр йағынан була инде. Ауылға нигез салған өщ туған затынан, ул ваҡытта исәнләре пощти йарты ауылны алып тора затлары. Йосоп балалары Әхмәтсафа, Әхмәтхафиз, Әхмәтхарис, Әхмәтнәби. Әхмәтхафиз бай мулла, Әхмәтнәби указлы мулла, Әхмәтхарис мулла икенще урамда була. Утыз житенще йылда дүртесен дә алып китәләр. Ғаиләләре тороп ҡала. Үзләре генә тороп ҡала. Ноябрь айында. Утыз сигезенще йылда январь айында өщ көн ара менән аталар. Минеҥ дуритәй Әхмәтсафаны бына әйтәм инде русса "Согласно материалам архивных делов №13465 республиканского архива, Юсупов Ахматсафа Юсупович 1877 года рождения, 30 ноября 1937 года, решением особого совещания НКВД АССР приговорен без предъявления обвинения к 10 годам исправительно-трудовых лагерей, умер в местах завода 30 января 1939 года в Черниговском, одном из заводов".

НКВД-ға ла йөрөнөм, ФСБ-ға ла йаздым, прокуратураға ла йаздым. Үлгән кешеләрнеҥ хисабын йазып бармағанлар. Анбарный книга ла йуҡ. Ошо йауап килде, документально алып барылмаған. Бына список, Йосопов Әхмәтнәбиҙән конфисковать ителгән список, наименования. Карандаш менән йазылған булған. Аны күзлек кейеп копировать итеп йазырға ғына ҡалған. Көнө буйы ултырҙым ошоно күщереп. Уҡырлыҡ түгел. Реабилитация башланды бит инде. Выплаталар түләнде. Шул ваҡытта ла бардым мин. Минеҥ Әхмәтсафа дуринәйе тере иде. Йазылған иске ғәрәп шрифты менән. Бер пенсионер булған анда. Инвалид кеше ул. Ул среда көнө генә килә, бер көн генә. Бер-ике сәғәткә. Килегез, тинеләр. Килдем, документты алды. Шул ҡәзәр аптыраны. Списокта хатта озон ҡуҥыслы ойоҡбаш, шундай нәрсәләрен дә теркәгәнләр анда. Аны йазырға кәрәк бит инде. Утызынщы йылды дуритәйҙәрҙе раскулачивать иткәс, бөтә йортларын мәктәпкә биргәнләр, ҡалғанын бер кемгә лә бирмәгәнләр. Әткәйем и әнкәйем йәш щаҡта ике өй аша ғына йәшәгәнләр. Әткәй ун дүртенще йылғы, әнкәй ун өщөнщө йылғы. Дус булғанлар. Әткәйҙе йебәргәнләр Ленинград өлкәсенә Истомскийға. Карьерҙан таш щығарырға. Әнкәйгә ул щаҡта ун алты йәш. Дуритәй менән дуринәй никах уҡыталар. Истомск границасына никахлы булып ҡайталар. Әткәйҙе утыз икенще йылда армияға алалар, Ҡызыл армияға. Өщ йыл хезмәт итә, анан ҡайта. Утыз алтынщы йылда абый тыуа. Фин суғышына алалар. Фин суғышында йыл йарым йөрөп ҡайта. Ҡыш көнө сыуыҡта саҥғыла йөрөтәләр. Мин Санкт-Петербургҡа йөрөйөм лечениеға. Действительно, ул сөйләгән йерләрдә сазлыҡ, урман йуҡ. Ваҡ төйәк ағаслар үсә. Ҡырҡ беренще йылда суғышҡа алалар. Нищек белгәнләр микән. Ул япон границасына инә. Япон суғышында ҡатнаша. Ҡырҡ алтынщы йылда ғына ҡайта. Анда сыуыҡ, ди. Нарядҡа барғанщы, Сталинскийҙы бирәләр иде, ди. Өщ рядовой һалдат и бер разводящий – дүрт кешегә бер йарты араҡы бирәләр иде, ди. Әлбиттә, столовыйҙа ашайбыз да, ди, шунан кищкә ҡайтып, кищкә нарядта тора идек, ди.

Бер случай инде ул. Январныҥ йегермеләрендә, ди, столовыйға индем, ди. Повар таныш иде, ди. Ул да безнеҥ йанда ултырды, ди. Бергә эстек, ди. Ҡайттыҡ, йоҡларға йаттыҡ, ди. Шунан столовойҙан повар жылап төштө, ди. Бәй, аптыраным, ди. Йегетләр ҡайҙа, дип сорадым, ди. Барса, һалдаттар мәйет кроватларында йата, ди. Әткәй тоже щирләй. Мин һушыма килгәндә, ди, алмағащлар щәщкә ата иде, ди. Суғыщ барғанда һалдатты өщ ай лечить иткәнләр. Шундай диверсия булғандыр инде.

Абыйымдыҥ китабында бар. Тыуған ауылым Иске-Ҡудаш турасында өзөк килтерәсе килә: Ул Байғужа ғәүжирәтенеҥ төнйаҡ щиге Свердловск-Казан тимер йулыныҥ уртаһы булған Яҥауыл станциясынан йегерме ике километр йыраҡлыҡта көнйағында урынлашҡан. Ауылныҥ көнсығышынан көн менән төн сузылған Мәүлихә тауы. Үзенеҥ бейеклеге менән данлы. Ауыл өстөнә һәр кем менеп ҡарай.

Щийәле тау бар. Аҥа ауылдан бейек булып күтәрелеп тора. Анда жиләк баҡщалары урынлашҡан. Бер генә урында ул. Дикий щийә үсә торған иде.

Уржый йылғасы бар. Ауылны элек республикаға бүлгәнсе, бүлгән ваҡытта ике ауылға бүленгән булған. Иске Уржа һәм Яҥы Уржа Иске Ҡудаш ауыл советына ҡараған булған. Утызынщы йылларда ауылдарҙы төзөй башлағащ, шул йылғанан ике граница ҡуйып, марилар Ҡалтасы районына ҡала. Иске Ҡудаш ауылы Яҥауыл ауылына ҡала.

Әле халыҡ килгәнще алар ау, балыҡ менән көн итәләр. Йылғада улар, ошо Уржыйда жимеш ҡапҡащын күрәләр. Алар бында берәү ҙә йәшәмәй, дип уйлайлар. Йуғарыла ауылдар барлығын күрәләр һәм аралаша башлайлар. Ул ваҡытта күсеп йөрөүщеләрҙе эзәрлекләгәннәр. Анда урыслар, марилар, татарлар күсеп килде, дип әйтмийләр. Улар шулай ҡалалар.

Тағы бер тарихи ваҡиға бар. Бер меҥ жите йөз ҡырҡ житенще йылны бер нищә ғаилә икенще ауылға ике километрға Яҥы Ҡудаш ауылына күсеп китә. Беҙҙеҥ ауылда нефтяниктар эшләй башлағас, беренсе скважина Яҥы Ҡудаш ауылы һәм Ҡудаш ауылы уртаһында, анда беренще промысел НПО "Краснохолмскнефть" була. Шунда илле икенще йылда була ул. Шунда нефтяниктар быуа быуып су алалар. Көнләрҙән бер көннө водокачкаға төшсә, сөйәкләр йата. Был ҡайта иптәшләренә әйтергә, шунан иптәшләре зурыраҡ кешегә әйтә. Улар Уфаға йеткерәләр, Уфанан археологический музейға йеткерәләр. Был була меҥ туғыз йөз алтмыш икенще йылда. Шунан инспекция килеп, раскопкалар эшләп, мамонт скелеты була. Архивта Уржый йылғасынан сыҡҡан Иске Ҡудаш ауылынан. Ленинградҡа ла алып барҙылар. Республикала щыҡты. Ауыл данлыҡлы инде. Шундай ваҡиғалар ҙа булған. Шулай башҡа ваҡыттарҙа ла тапҡанлар. Шундай сөйәкләр күп тапҡанлар. Хатта малайҙар маҡтанған, заготовителгә күпме сөйәк тапшырҙым икән ул, дип.

Ауыл йерендә колхоз төзөлә. Ныҡ эшлийләр. Беренсе Ленин орденын Зыев Зариф абый ала. Ауылда Советтар Союзында ғүмерендә колхозщылар съезында була. Беренседә Әхтийәл ауылынан Хәсбутдиновлар, өщөнщөсөндә Иске Ҡудаш ауылынан механизатор Нәбиев Рәүеф, Сибәденән Рәфис Исмәғилов ҡатнаша. Дүртенщесендә Кашапов һәм Ленин исемле колхозынан ветеринар – мин ҡатнаштым. Китап бар. Ике меҥ өщ

йөз делегат арасында мин бер үзем ветеринарный врач булдым. Агроном, зоотехник, финансист, колхоз председателе. Мин үзем. Нисек эләккәнмендер. Мәскәүҙә Михаил Сергеевичты тыңланым. Бер мең туғыз йөз сиксән сигезенще йылда март айында бына шул съезда уҡ Прибалтиканан, Украинанан килгән делегаттар аңлашмаусанлыҡ, выступлениеларында килешмәүщәнлек бар иде. Безгә телефон менән файзаланырға була, дип әйттеләр. Тафибат ағай семьясы менән тормай ҙа иде. Телефоннан ҡайҙалыр звонить итергә кәрәк, мин туғанларға звонить итә идем. Ул конный дворҙан булһа ла звонить итә иде. Ҡызыҡ кеше иде. Телефонды набирать итсәң, сразу бара иде. Съезд бөттө, телефон йуҡ уже. Ҡайттыҡ. Йуҡ.

Суғыш ваҡытынан суң ауыл хәйерще булған бит инде. Рафи апа инде. Ире суғышта үлеп ҡала. Иске йорт алып ҡайталар. Күпмесе сыймай, ҡалдырып торалар. Рафи апа, урламасындар дип, тышта йоҡлай. Бер заман Хәким бабай көтөү көткән була. Урам буйлап бара икән, урамда койка тора, ди. Рафи апа йоҡлап йата, ди. Рафи сеңлем, тор, атыу үгез сөзөп китәр, тигән. Рафи апа торған да, ди, ох, щуҡынған, Замиржан менән Ғабдулхайҙың ғына эше инде ул, дигән. Күршесендә йәшләр йәшәгән. Элек шулай сүтә торғанлар иде. Туалетты йә бүрәнәне. Шайарып шулай. Иртән торсаң, туалет йуҡ була ла, иртәсенә кире килтерәләр. Ҡызыҡ булған шулай.

Иске Ҡудаш ауылында тыуған бер мең туғыз йөз утыз алтынщы йылда Ҡайын Хәтфетдинов тигән кеше. Ул безнең нәселгә инә ул. Иске Ҡудашты бөтөп, военный училищеға инә. Командир роты була. Бер мең туғыз йөз алтмыш сигезенще йылда Вьетнамға йебәрәләр. Ракетный комплексты Вьетнам салдатларына күрсәтергә. Унда булып, президент менән ощрашып, наградалар алып. Хо Ши Мин менән. Вьетнам турасында да, пельмен бешерергә өйрәтә. Аның да өлөшө бар. Америка ракеталарын ҡолатып төшөрә. Был хезмәтемде бүләк итеп бирәм. Бына былар көндәлеге. Бала щаҡтан йазған хезмәте был.

Бында ун сигез шәжәрә.

Бер ваҡыт Мөғәллим әбей аулаҡ өйҙө ҡарап тороп ҡалған. Ишек шаҡығанда ҡызлар базға төшкәнләр. Бер ҡыз базға ҡолап төшә. Нимә булды, дип сораған, урыным ғына сынды, дигән. Ҡызлар көлгәнләр дә әбей белеп ҡалған, әәә, сез бындамы ней, дип ҡысҡырып йебәргән.

(Хужахмәтов Айнур Оскар улы яҙып алды).

## ЙӨГӘМЕШ АУЫЛЫ

### Дауытова Зилара Фәүзи ҡыҙы, 1958 йылғы

Мин Түбән Щат ауылында үстем. Хәзерге көндә Йөгәмәш ауылында. Без инде Щатта үстек. Минең туған ауылым белән килен булып төшкән жирне йегерме километр ара йыраҡлығы, силсәүитләр айырым инде. Бала щаҡ су ҡойоноп, эш белән, пещән жыйып, бала ҡарап үтте.

Атамалар бик күп. Бында Йөгәмәштә жирле халыҡ, ис китмәле, иң зур бай тарихлы – ул Йөгәмәш. Шушы силсәүитләргә ҡарағанда. Бөгөнгө көндә менә йегерме каналны бушлай ҡарайбыз. Шушында легендар тау, Ҡалатау бар. Ҡалатау өстөндә телевизион вышка бар. Шунан соң, ул шишмәләр! Һәр бер тау итәгендә шишмә йата. Әле соңғы йылда ғына менә Хәйретдин тауында жиләк-жимешкә йөриләр икән – шунан су эщәләр. Анан соң Ҡәүи шишмәсе, Илүс шишмәсе, Ташлытау башында да Аҡ шишмә, Салҡын шишмә. Нинди генә шишмәләр йуҕ ул. Ис китмәле матур ауыл. Матурлайлар инде ауылны. Әзерәк кенә кеше саны кәмей инде. Шулай ҙа йортлар ҙа бөтөрөп йаталар. Шулай ҙа йәшләр дә киләләр, щөнки безнең трасса үтә. Яңауылға йаҡын. Тәтешле йағы ҙа йаҡын. Бик ихтирамлы жирдә йәшәйбез. Ул Хәмидә тауы. Һәр берсе исем-атамалары кеше белән бәйле. Ул Ҡалатау.

Минең ныҡ әйтәсем килә Йөгәмәш тау турында. Тауның күле булған, ул ҡороған, диләр.Шул күл урынында хәзер ҡамышлар, нейләр. Элек вышка булған тимер. Шул вышка йуҡҡа щыҡты менә. Шул вышканан ҡарасаң, бөтөн тирә-йаҡ, хәттә Балтащ, Борай районнары күренгән. Шушы тау турында безнең йаҡташ йазущыбыз Илдар Юзеев йазып щыҡты. Мыны ул Ғашиҡлар тауы дип атаны. Ғашиҡлар тауы дип атап, менә шулай дип йазған Илдар Юзеев, башҡа йаҡларҙа белмим нищектер, дей, безнең йаҡларҙа ғашиҡлар үзләренең мөхәбәтләрен тау башына менеп әйтәләр, дей. Үзләре тау башынан тыуған йаҡларға ҡарап, үзләренең мөхәбәтләрен аңлатып, мәңге ташлашмасҡа сүз ҡуйышалар. Әгәр ҙә кем дә кем шушы антны боза икән, йә ауырый, йә үлә. Менә бу щынлап та тәбиғәт белән кеше арасындағы бәйлелек. Легенда буйынща, шушы тауның күлендәге пар үрҙәкнең берсен бер аущы атып ала да ҡайнатырға сала. Үрҙәк күпме ҡайнаса да пешмәгән. Пар үрҙәкнең икенсеще сарғайып үлгән, ә кешеләр дә шулай мөхәбәтләре тәбиғәткә тиң. Икесе дә йәнәш ҡуйарлыҡ, дип әйтәсе килә инде. Ул тау турында тағы былай дип йаза Илдар Юзеев, былай дип ул хикәйәне бөтөреп ҡуйа. Аущы алып ҡайтып салған үрҙәкне, ҡайнатҡан, ҡайнатҡан, ни ғәжәп, теге үрҙәк ощоп зәңгәр күккә күтәрелгән. Менә без кемләр, без – Йөгәмәш тау үрҙәкләре. Менә без ниндий йаҡтан, дип әйтеләә.

Күңелгә тийгән бер тарих турында сөйләймен. Безнең Йөгәмәш ис китмәле бай. Репрессия ваҡытларында сиксән йәшлектән ашыу ҡортҡалар әйтәләр безнең күз күреме жир генә әле ике йөз йыл шушы ауылға, ә дүрт йөз йыл барҙыр дигән. Исәпкә алсағыз, бөгөнгө көнгә ҡәҙәр балта осталары, кейез итек басущылар, матур итеп бизәкләп тәрәз рамнарын, көйәнтә, сандыҡлар, мищ щығарыущылар белән дан тотҡан ул безнең Йөгәмәш ауыл. Ауылыбыздан әле соңғы йылларда ғына өщ ғалим, биш йуғары категориялы ващ, фән эшлеклеләре, эшҡыуарлар, атҡазанған хезмәткәрләр, данлы эшщеләр ауылыбызның данын күтәргән. Димәк, шундый эшлекле кәсеп, шөғөл иткән буыннан килә. Бик эшлекле, булдыҡлы кешеләр белән дан тотҡан ул Йөгәмәш ауылы. Ауыл тарихында мәңгелек булып ҡалған ҡарабайлар, тараҡаннар, сарманнар, мөҡәйләр, хисаметдин һәм үәлиләр

аларның нәсел-ырыуы мең дә жиде йөз сиксәненче йылларға барып тоташа. Иғтибар итсәгез, тирә-йакта дан тотҡан Шәңгәрәй мулла – Ҡарабайлар нәселенән. Менә мин килгән уаҡытта Шәңгәрәй мулланың улы Кирам менә шулар буыннан-буынға эшлекле булғаннар. Ҡарабайларның бер нищә туғаны Таджикстанға щығып киткән. Бер улы белән миңә осрашырға туры килде. Бынан ун биш-йегерме йыл элек. Ул ҡайтҡан туған жире белән бәхилләшергә, сиксәннән ашҡан. Ул уҡыған, интеллигентный кеше булған. Мәҙәнийәтле булыуы бер дә кәмемәгән, төп-төз матур булып ҡайтҡан, тик бабай булып ҡайтҡан. Тағын бер туғаны бөтөн байлығын ҡойоға ташлап щығып киткән, шул ҡойо урынын да беләм. Ә инде Ҡарабайның тағын бер туғаны бар байлығын ҡалдырып, бөтөн булған китапларын ат арбасына төйәп, таң алдынан щығып киткән. Хәзер мин уртаҡлыҡны әйтәм. Берәүне ауылдан ҡыуалар, аның ашарына йуҡ, кийәренә йуҡ, ул белемгә ынтыла, китап тейәп, щығып китә, берәүне ҡазанға салалар, үрҙәкне, ул зәңгәр күккә күтәрелә. Безнең ауыл – бик бай ауыл. Әйтәсе килә, нәтижә йасап ҡуйасы килә. Бу Йөгәнбаш нищек килеп щыҡҡан. Халыҡ бит белгән. Эшлекле халыҡ урын эзләгән. Эзләгән ваҡытта суын да ҡараған, урманын да ҡараған, бездә бөтөн нәрсә дә бар. Таулар да бар уратып алынған. Ис китмәле. Килегез әле жәй көнө сез. Шунда йөгән башы тапҡаннар. Менә безнең музей да бар. Шунда йөгән башы эленеп тора. Шунан соң халыҡ бында йәшәргә була. Бында электән йәшәгәннәр. Шунан баштараҡ: Ҡайсы ауыл? Йөгәнбаш ауылы. Азаҡ Йөгәмәш ауылы булып киткән ул. Шунан соң, йазып ҡуйдым әле: Күпне күрде йөргән баш,

Шомарҙы бит йөргән таш.
Илсез-көнсөз йөзәмәдек,
Ҡулда булды йөгән баш.
Без бит әле – Йөгәмәш,
Йөгән башын тотҡан кеше
Илсез, көнсөз көнләмәс!

Боярышник – ҡамыр жимеш. Шиповник – гөлжимеш. Черемуха – шоморт. Клубника – жир жиләге. Земляника – ҡайын жиләге.

Дедушка – бабай, ҡартәтәй, зурәтәй. Бабушка – зурнәй, зурнәкәй, нәнәй. Бианай, биатай инде ул былай. Алай дип әйткәнне йаратмайлар. Ә былай әнкәй тибез. Ҡайнаға (ирнең ағасы), балдыз, ҡайынсеңел (ирнең бер туған сеңлесе).

Боҙ өҫтөндәге һыу – туш.

Божья коровка – ҡанға пипи. "Ҡанға пипи, ощ, ощ, кейәүең килә, Ҡанға пипи, ощ, ощ, кейәүең килә", диләр. Оща да китә.

Деңгәзәй – уф, аллам, бигерәк йәмсез сүз белән әйтәбез: усыраҡ әтәщ.

Улитка – әкәм-төкәм. "Әкәм-төкәм, өйөңнө жимерәм, мөгөзөңнө щығар", дисәң, ул мөгөзөн щығара.

Ҡырмыҫҡа – ҡырмысҡа. Йыланнар бездә йуҡ ул. Ежик – керпе.

Щыпщыҡ, песнәк, өкөләр, суҡыр тыщҡан. Суҡыр тыщҡан бигерәк ныҡ таралды. Лягушка – баҡа. Паук – үрмәкүщ. Бурсыҡ бар, тейен, ҡуйан.

Имән, йүкә, ҡарағай, жирек, щаған.

(Сәғитова Айгөл Ғәни ҡыҙы яҙып алды).

## КИҪӘКҠАЙЫН АУЫЛЫ

**Ахкямов Рәмил Муллый улы, 1951 йылғы** (фотола – уртала)

Мин үзем Кисәкҡайын ауылында тыудым, үстем, уҡыдым. Пенсиядамын. Йуғары белемләрне сит обласларда алдым. Техникумды Красноусольскийда Свердловская обласында уҡыдым, институтны Ижевскийда, Удмуртия СПК-сында уҡыдым. Эшләү – Башкирия территориясында. Шулай килеп щыҡты инде. Суңғы ваҡытта, пенсияға сығыр ваҡытта, коммунальное хозяйство белән йетәкще иттем, зур ғына организацияда. Пенсияда уже ун йылмын. Пенсияға щығып, сразу өйгә ҡайтып китмәдем, өщ йыл йарым эшләдем еще. Пенсияға щыҡҡащ инде, өйдә аурыраҡ булды, иркен тормошҡа өйрәнеүе. Бер көннө утырамын нийдейдер эш табырға. Компьютер заманнары бит инде хәзер. Ауыл буйынща бер ниндий группа ащу турында уйлап йөрийдириийм. Компьютерда утыра торғащ, килеп щыҡты әзер группа. "Земляки: Кисак-каинцы" дигән. Бу ваҡиғаға уже жиди йыл ваҡыт үтте. Шунан суң йарты йыл уйланып йөрдөм-йөрдөм дә готовиться итеп, шунан шушы группаға кердем. Аның администраторы бөгөнге көндә – Шәйхутдинова Зинфирә Фәтих ҡызы инде. Ә мин аларның права рукалары. Организацияда главный инженер күберәк эшләй тигән кеүек. Мин дә инде, хәзерге тел менән әйткәндә, супер модератор. Бөтөн нәрсәне контролировать итү минең өстә. Хотя администратор үз иптәше белән бергә өсәүләп ишлийбез инде. Бөгөнге көндә группада өщ мең дә алты йөзләп фотография бар. Ул фотоларны ысыннан бүлгеләнем төрле ваҡиғаларға, төрле историяларына ҡарап, где-то алтмыштан артыҡ группаға. Теге былай ғына әйткәндә киш-миш түгел инде. Бөйөк Ватан суғышында үлгәннәре бер альбомда, исән ҡайтҡаннары бер альбомда, мәктәп тормошы отдельно альбомда, колхоз тормошо отдельный альбомда. Шулай бүлеп щыҡтым. Ауыл историясы отдельный альбомда. Мәщет турында альбом. Ауылда безнең зур ғына мәщет бар. Һәр бер альбомға группалағы кешеләр фотолар өстәп баралар. Мин аларны контролировать итеп барам инде. Йегерме житенще январь көнне безнең группаға жиде йыл булды. Мин шунын алты йыл йарымын хезмәт итәм инде. Өщ меңдән артыҡ фотоларны жыйу жиңел түгел. Алар исторический фотолар. Мин биш-алты йыл инде өйдән-өйгә йөрөп, фотоларны жыйып, аларны урнлаштырып,

үзебезнең ауылдашларны күрше ауыллардан табып, күрше городлардан табып, шушы фотоларны табып урнлаштырып торам инде. "Одноклассники"ның администраторының нәтижәсе буйынща, безнең группа матур, уңышлы, аңлайышлы группа. Үзебезнең эшкә үзебез ҡыуанып барабыз. Тынысланырлыҡ вағыт йуҡ. Эшләргә дә эшләргә. Бер үк ваҡытта видеолар да урнлаштырып барам. Суңғы ваҡытта видеолар төшөрәмен. Йегерме биш видео бар. Ул видеоларның иң искесе туҡсанынщы йыллардан башланған. Ҡырҡ йыл элек төшкән видеолар да урнлаштырылған. Ул ваҡытта видеолар щыға ғына башлаған иде. Әле күптән түгел үзем Бөйөк Жиңүдең житмиш биш йыллығына бағышланған дүрт сәғәтлек видео эшләдем. Ул видеода ун биш кеше ҡатнашты. Видео безнең бер Кисәкҡайын ауылы ғына түгел, ул киң күләмдә алынған. Безнең ауылға, Ҡарман ГРЭС-ы төзөлү сәбәпле, өщ ауыл халҡы күщте. Күрше ауылларға да күщтеләр. Аларны бит обижать итеп булмай. Кемдер исә безнең Кисәкҡайын ауылында шофер булып эшләгән икән, кемдер суғыштан ҡайтҡан, мин аны, Кисәкҡайын кешесе суғыштан ҡайтҡан тип, Кисәкҡайын альбомына ҡуйа алмайым, уларның альбомына ҡуйам инде. Тракторист булып эшләгән икән Ҡызыл Ярдан килгән иптәш, аны мин Кисәкҡайынныҡы тип атап әйтәлмайым, үзләренең альбомына ҡуйам. Дүрт сәғәтлек видеода ун биш кеше ҡатнашты. Өйдән-өйгә йөрөдөк. Аны декабрь айында ғына урнлаштырдым. Анан жәй көне почти бер сәғәтлек видео эшләдем. Шушы Кисәкҡайынның бөтөн урамларын, тыҡрыҡларын төшөреп урнлаштырдым шушында. Күптән түгел мәщеттәге мулла абыйның сөйләүен дә урнлаштырдым. Ул йәшләрне тәрбийәләү темасына сөйләгән иде, мин аны видеоға төшөреп урнлаштырып ҡуйдым. Киләщәктә мәктәпнең, Кисәкҡайын мәктәбенең, историясын искә төшөреп, исән уҡутущылар белән ощращып, видео төшөрергә инде, мәктәп турында.

Мин үзем Яңауылда йәшәсәм дә, азна сайын ҡайтып йөрөйем. Мында минем бер туған энекәш йәшәй бер үзе генә. Аларға өйөн жыйыштырырға, продуктылар алып ҡайтырға. Әзерәк группасы да бар аның, шуға сирләй дә бит инде. Шуға йәрдәм итеп йөрөйем. Ауылда мин постоянно буламын. Эшләгән ваҡытта "Заслуженный строитель" тигән Почетная грамота бирделәр. Минем әтей "Заслуженный механизатор БАССР" булған. Без бер семьядан ике заслуженный работниклар булып саналабыз районда. Тик йатып булмай бит. Халыҡ арасында эшләй торған эштә эшләгәс. Мин өщ төрле организацияда эшләдем. Эштән туҡтағащ, тик торасы килмәй, группалар ащтым мин Одноклассникида. Бөгөнге көндә минем жиде группа ащылған. Шушы жиде группаның биш группасы Российкий масштабтағы интернетта утыра. Былары подготовительный периодта, Российский масштабҡа кереп китмәде.

Мин үзем бывший коммунист. Бөгөнге көндә бер партияға да подчиняться итмәйем. Барсын уважаю. Ғөмергә МТС системасында эшләгәнмен, шуға мин МТС системасын изучать итәм ныҡ ҡына. Музей боевой славы бар безнең районда. Коммунислар партиясына ҡоролған инде ул. Аларға группа ащып бирдем и помогать итәм инде. Тик тормасҡа үземә-үзем эш табып тик торам инде. Булған группаларны ащмайым, өстәп, матурлап алып барырға ғына исәп бар инде. Әле суңғы ваҡытта, ҡыш эш бөткәщ инде, частный домда йәшәгәщ, жәй көне эш бар ул, ҡыш көне тяжело, тәзрәнән генә ҡарап йатып. Скучно. Видеолар эшләй башланым. Мин бик йаратам путешествовать итергә. Бәләкәйдән үк йаратадырыйем. Йылға буйларына төшеп йөрергә, басуларға барып, зурайа башлағащ, заграницаларға щыға башланым. Бөгөнге көндә үзебезнең бывший СССР-ның республикалары белән утыз илдән артыҡ илдә булдым. Фотоға төшерәм. Бу фотоаппарат минем дүртенще. Өщне туздырдым инде. Видеоға төшөрәм, фотоға төшөрәм. Суңғы ваҡытта бер төрле программа изучать иттем дә видео эшләймен. Шунда үзем төшерәм видеолар. Фотоны да движениеға китерәм. Бик матур-матур ғына ниләр щыға. Фотоны әйләндереп, компьютердан ҡарап утырғанщы, былай күренеп тора, асларына йазып ҡуйасың ниндий город, нииндий йердә. Күп йөрөдем. Әле барасы жирләр бар. Әйткәнләр иде Америкада булдыңмы дийеп, мәктәптә уҡущылар белән осращҡанда. Америка территориясында тоже булып ҡайттым. Кубада булдым, девятнадцатый годта. Америка материгы. Ун ике сәғәт оща самолет.

Видеоларда минем политикаға артыҡ кермәймен. Халыҡны матур итеп тәрбийәләү, тарихҡа. Мәщет ащылу тарихы төшөрелгән бит инде. Ауыл советы тарихы бик әз йазылған, уны күбәйтергә кәрәк. Анан суң безнең силсәүит территориясында суғыш ваҡытында детдом булған. Яңауылда алар өщ төркөм булған. Иң зуры бездә булған. Бәдрәштә. Шул детдомның историяларын интернетҡа ҡуйдым. Оригиналь альбомны таптым музейдан. "Одноклассники"да ошы сүзне жыйсағыз, килеп щыға инде. Одноклассники"да йәшләрне мин артыҡ ҡуймайым. Алар үзләрен үзләре ҡуйырлар. Олораҡ поколениены ҡуйам. Одноклассники арҡылы ҡайбер семьяларның биш поколениесын белергә була. Кемдән кем тыуған – барысы да.

Ауыл урамлары. Советлар Союзынан ҡалған Ленин урамы бар. Бар Түбән ощ, Йуғары ощ, дип сөйләшәбез. Бәләкәй урам, Ферма урамы, дип сөйләшә идек. Ауылыбызның озонлоғо ике километр. Туп-туры ул. Быйағынан, Янбарыс йағынан, ҡарайсың, тимер йулынан үткән поезд күренә. Суңғы ваҡытта водокачка, по-моему. Ике километр ауыл буйлап, тағы ике километр барған су йулын күрергә була.

Поезд бездә ун дүртенще йылдан уҡ йөрөй башлады. Шуңарға безнең халыҡ поезға утырып тегендә-мында йөрөй. Тиме йулы белән барырға безгә жайлы. Безнең халыҡҡа Уфаға барырға ауыр. Шуға шағирлар, жырщылар – барсы да йә Ҡазанда, йә Свердловский йағында. Безнең земляклар Уфа йағында бик әз.

Без бәләкәй щаҡта Ҡазан йағынан итек басущылар килә иде. Өйдән-өйгә йөрөйләр иде. Анан суң тегүщеләр йөрөйдерейе. Тун тегәләр иде. Бар да Ҡазаннан киләләр ийе. Башкирия территориясына кереп, итек басырға, тегү тегеү эшләрен алып барырға. Безгә Уфадан килмәгәнләр, потому что Уфадан ул ҡәдәрем килеп булмай иде. Ул Уфаға бару ул – вообще... Ат белән йөргәнләр.

(Акилова Мөнирә Фәтих ҡызы яҙып алды).

**Фәхретдинов Зифил Заһир улы, 1959 йылғы**

Кисәкҡайын ауылында тудым, шушында сигез класны, мәктәпне тамамладым. Шушында эшкә ҡайттым. Ике мең дә алтынщы йылға тикле шушы туған колхозда эшләдем. Аннан биш йыл Дәүләкән районында ОПХ Казангуловскоеда директор булып эшләдем. Шунан йаңыдан был йаҡҡа ҡайтып, Орловка йаҡларында бер дүрт йыл эшләп алдым. Хәзер пенсияға щыҡтым. Но әле эшләтәләр. Мунщада директор булып торам. Тыуған жирем шушында, йәшәгән өйөм шушында, Кисәкҡайындан ҡайда ғына китсәм дә, әле дә шунда йәшәйем. Мында тыуған кешеләрне, мында йәшәгән кешеләрне, мында эшләгән кешеләрне бик әйбәт беләм. Сөнки эткәй ғүмер буйы бригадир булып эшләде, ауыл советы председателе, суңыннан имам хатиб булып уҡыды мәщеттә. Мин аңа эйәреп йөрөйдерейем, утырып йөрөйдерейем. Басуларда, халыҡлар ҡырында. Шуңалыр инде профессияны да ауыл йерен сайладым инде. Агрономлыҡҡа уҡып щыҡтым да шушында ҡайттым.

Эш буйынща да инде мин, агроном булып уҡысам да, шул бер дүрт йыл агроном булып эшләдем дә, шунан зам булдым, партком секретары булдым. Шуннан суң, партия бөткәннән суң, председатель заместителе – урынбасары (бик йәмсез инде), аннан суң сигез йыл председатель булып эшләдем. Шушы дәүердә генә шәжәрә белән, тарих белән дә, эш буйынща да туры килде инде өйрәнергә. Иң беренче тарих буйынща безгә килделәр, бу туҡсанынщы йылларда. Килделәр профессор Әсфәндияров. Шуннан суң бәйетләр өйрәнергә фамилиясы истә ҡалмаған, Юлай Гайнетдинов килде. Халыҡны шушында жыйып, ул алып килгән иде Кисәкҡайынның тарихын. Ревизские сказки буйынща төзөгән иде, группалаштырған иде. Мына сез ҡарағыз, үзегезнең эткәгезне, ҡартәтәгезне – кемне беләсегез, астан менсәгез, үзегезнең быуынларны эзләп табасыз, тине. Беренче ауылға бөтөн халыҡны жыйдыҡ. Фойеға ул алып килгән нейләрне йәбештереп ҡуйдыҡ. Кеше щыҡты, ҡарады, танышты. Минем ныҡлап шәжәрә белән ҡызыҡсына башлауым шошынан барлыҡҡа килде инде. Минем эткәй, шунан суң, ул ваҡытта ауыл мулласы инде, Низамов Хәсинйән бабай, безнең ҡартәтәйләр бер туған булған. Алар сүләп китә инде Фәррәхетдин, Фәхретдин, Низаметдин, Хөснетдин, Нуретдин, аларның әтәсе булған Фәрүәзитдин, Фәрүәзитдиннең әтәсе булған Ғәли. Ғәлидән суң алар белмәйләр иде. Мин шул астан ҡарадым да барып щыҡтым инде шул Исәнғол тамырына. Мин туғызынщы быуын, минем малай унынщы быуын, оноҡлар уже ун беренче быуын. Фәрүәзитдиннең әтәсе – Мөхәммәтғәли. Мөхәммәтғәлинең әтәсе – Бәхтийәр, Бәхтийәрнең әтәсе – Өмөтҡол, Өмөтҡолноң әтәсе – Исәнғол.

Ауылның исеме ҡайан килеп щығыуы. Бабайлар сөйләйләр, безнең йаҡларда ҡара урман булған. Шул уҡ ваҡытта ҡайынлыҡлар да булған. Безнең ауылды, йәнәсе, шул ҡайынлыҡны төпләп, йандырып или пожардан суң йанып киттеме икән, или йандырып төпләделәр микән? Ҡайын кисәк исеменнән килеп щыҡҡан инде. Әсфәндияровның китабында да бар. Унынщы ревизия буйынща интернетта щыҡты. Кискән ҡайын буламы ул, ҡайын кисәге булғанмы? Однако шул ҡайын белән бәйле. Тарихына килгәндә шул инде.

Бабайлар атаған йалан исемләре дә бар инде. Сарысаз. Бещән щаба идек. Сарыҡ көтөүен көтә идек – Аптал йаланы. Кеше исеме белән бирелгәндер инде ул. Ҡарман ауылы белән ике арада – Ишмәкәй басуы. Анда уңдырышлы туфраҡ. Игеннәр ишелеп үскәнгә Ишмәкәй дигәнләрдер инде. Ауылдан йыраҡ түгел – Жидусаҡ басуы. Мин эшләгән щағымда да өс ағащ исән иде. Хәзер инде бөтте инде анда. Анда урнлашҡан булған бер ауыл, шунда ашлыҡ суҡтыра торған булғанлар.

Бәҙрәшбаш йылғасы. Бәҙрәшбаш ауылында шишмә бәреп щығадырыйе. Без аны уҡущылар щағында уҡ экскурсияға да алып барып күрсәттеләр. Безнең биология уҡытыущысы инде. Бәҙрәшбаш йылғасы Бүә йылғасына ҡойа иде. Бүә йылғасы бөгөнге көндә Кармановское водохранилище. Бүә йылғасын буып, электростанция төзөдөләр бит инде. Буй йылғасы. Зур ғына йылға инде. Ауыл бик зур ийе. Аның жирләре зур ийе. Мына эткәй бригадир булып эшләйдерейе. Хәзер анда сад-огородлар. Элек анда Ҡызыл Яр дигән ауыл бар ийе. Мына шул Бүә йылғасы күпердән щығып өскә менеп китәдерейек, шунда безнең басулар бар ийе. Анда бещән щабалар иде, мин ийәреп йөрөй торған идем. Янбарыс ауылының күпмелер өлөше, ауылның бащланғыщ щалущылары микән, былар Ҡазан шәһәрен Иван Грозный алғащ, щуҡындырылудан ҡащып, шушында килеп утырғаннар. Йәнәсе, безнең бабайлар сөйләүе буйынща инде, алар йылғадан ағып төшкән. "Иван Грозный щуҡындырыуыннан ҡащып килдек, зинһар, безгә рөхсәт итегез утырырға". Алар рөхсәт биргәннәр, шул ауылның границасы, элек ауыл ҡапҡасы булған. Безнең Кисәкҡайын жирләре Янбарыс ауылының суңғы өйөнә терәп безнең жирләр инде. Тимәк бу Кисәкҡайын жире булған. Бабайлар урнлашырға рөхсәт биргәннәр.

Ҡарман ауылы бороңғо. Бороңғо ғына түгел инде. Ҡаһарман исемле Кисәкҡайын ауылы кешесе, йәнәсе, ул бик буйныйыраҡ булған. Тәртип бозущыраҡ кеше булған. Аны башҡа щығарған кебек, йыраҡҡараҡ алып барып урнлаштырғанлар. Шунан киткән, Ҡаһарман исемле кешедән Ҡарман ауылы киткән.

Мына без утырған урам – Никкилдем урамы. "Ник килдем". Бында барысы да күщенгән. Ҡызыл Яр ауылы, мына мында Үрдәк ауылы. Ике ауылдан килеп утырғанлар. Ике йаҡтан урам бит инде, бу – басу. Йалан дип әйтеп була. Бер нәрсә дә йуҡ, былар килеп утырғанлар. Ә элек бик ҡарлы буладырыйе. Ҡар өйөп китә бит инде. Быларның ҡапҡаларын да өйөп китә. Щоланларын да өйөп китә. Былар щығалмай бит инде. Шунан әйткәнләр инде – ник килдек без бу жиргә. Үзебезнең йәшәгән жиргә житәме суң инде, дип. Шуннан – Никкилдем урамы. Йылға буйы урамларын – Непроха диләр. Анда үтеп булмайдырыйе. Непроходимый урам. Динараның ҡартасы йәшәгән урам – Шишмә урамы.

Безнең ауыл эщендә генә дүрт шишмә бар. Шишмәләр бик күп ийе инде. Тартар йаҡлап шишмәләр күп ийе. Шишмәләр бөтте, щөнки водозабор төзөлде. Хәзерге көндә, нищәнще йылда, бер ҡырҡ йыл Кисәкҡайын водозаборы төзеп, Яңауыл шәхәренә су качать иттеләр мынан. Шунлыҡтан инде шишмәләр ҡородолар. Түбәнгәрәк киттеләр инде. Безнең аста ул диңгез микән, күл микән. Бөтә торған су түгел инде.

Гриб – гөмбә. Белый гриб – аҡ гөмбә. Картофель – бәрәңге.

Сосна – нарат. Осина – ущаҡ. Пихта – аҡ шыршы. Ива – өйәңке. Рябина – миләш.

Кастрюля – мис. Баня – мунща. Вьюшка – йүшкә. Место для умывания – гөмбәш. Мочалка – мунщала. Банный веник – миллек. Место для хранения вещей – кәлиткә.

(Акилова Мөнирә Фәтих ҡыҙы яҙып алды).

## ҠАРМАН АУЫЛЫ

### Ғафарова Зөһрә Мәғруф ҡыҙы, 1946 йылғы

Радик Гәрәев исемендәге мәктәптең директорымын.Русса уҡыным. Рус мәктәбендә уҡыттым. Үҙ телемдә сөйләргә, аралашырға хыйалландым. Бирск techинституттың инфагын бөтөрҙөм. Йетмеш беренсе йылда өщөнщө мәктәпкә килдем. Анан ике мең алтынщы йылда пенсияға сығып киттем. Алтмыш йәшемде тултырып. Ул мәктәптә Радик Гәрәев уҡыны. Шунан Салават Әминев уҡыны. Беренсе медалист безнең мәктәптә. Санкт-Петербургта, элек Ленинградта ракетный заводтың директоры булды. Шундый зур-зур кешеләр щыҡҡан. Радик Гәрәев инде мәктәп эргәсендә торҙо. Йырлап-бейеп, шулай итеп йәшәгән йегет. Атасы-әнийсе лә йырлайлар иде. Гармун тотоп, әйҙә Хәсрәтбикә менән бергә йырлайыҡ әле, дип әйтәләр иде. Бәләкәй генә йортта торалар иде алар. Легендарная щкола булды. Йыш мәктәпкә килә иде. Арслан ағайҙың китабында бар иде ул. Яңауылның үзәге булған, диләр. Урманнан алып күщеп килгәнләр. Бер бай ике малайы менән күщеп килгән. Исемен белмәйем. Салынған дүрт йорт. Шунан йәшәп киткәндәр. Анан Бухаровтар киткән. Бухаровтар йәшәгән. Безнең мәктәпнең урынында. Архив документларында аларның ике йорто булған. Ат сарайы, мунчасы. Аларны раскулачивать иткәнләр. Сөргөнгә. Өйләрен безгә мәктәп итеп биргәнләр. Без шул мәктәптән башлағанбыз инде уҡытырға. Өщөнщө мәктәптә. Аларның йортонда дүрт-биш класс булған. Анан мәщет тә булған, бер-ике класс. Анан сиркәү бар. Анда уҡыйлар. Мин үзем уйлайым, бик легендар булған. Сыуаштар, марилар, башҡортлар, урыслар уҡыған. Элеваторҙа, консервзаводта эшләгәнләр. Маслосыр заводында эшләгәндәр. Шәп балалар щыҡҡан. Хезмәттә үскәндәр. "Уран" тигән китапта Фәрит Зыевич йазған, анда йазылған, Ҡарман башланған кещкенә ауылдан. Ике йорттан анда. Ҡарман тигән кеше күсеп килгән. Ҡарман тигән кеше башлап йебәргән. Безнең замандарҙа зур ауыл иде. Нефтяниктар эшләне. Кармановский ГРЭС барлыҡҡа килде. Шул Ҡарман халығы ҡулларында ла, телләрендә лә бар, дип әйтәләр. Йең сызғанып эшлий. Колхоз ваҡытында колхоз урынлащтырғанлар. Аҡтар-ҡызылдар үткән. Әнкәйем сөйлий иде, ҡартәтийемнең баҡщасында зур котлован булған, анда Чапаев йәшенеп ултырған, дип сөйлий иде.

Бездә башҡортлар әсәй диләр, оло әсәй диләр, атай диләр, татарлар әйтә, дәүәней диләр, әтей диләр, Ҡарманлар шартлатып әнкәй, әткәй, ҡартый, ҡартәтей диләр. Ошо йердә әйтәләр. Ҡарманлар күп йөрөгәнләр сәүҙә итеп. Бына йаҡында Никольская бар, Инйар булған элек. Революция ваҡытында мариларҙан тәңкәләр йыйып, Саратовҡа алып барып сатҡанлар. Күбещенсә, көмөш тәңкәләр булған. Балаларына биргән тәңкәләре саҡлана. Саратов, Ҡазан бәйле булған. Без бәләкәщ щаҡта ҡартәней сепарат айыртып, йоморҡаларын жыйып, йетмеш бер поезына ултырып, щығып китә. Шул көндөз ҡайтып килә иде. Йоморҡаларын сатҡан, майын сатҡан. Ирләр дә, ҡатынлар да шәп булған.

Әткәйләр әйткәнщә, күрше ауылдар әйтәләр, ти, Ҡарманлардың ҡулларында ла бар, телләрендә лә бар, дип. Элек ныҡ жырлыйлар иде. Анан оло урам менән барғанда, мәщет бар иде. Озаҡ сүтмәнеләр аны. Иске иде. Мулла ла йуҡ иде. Гел барғанда аны урап, эщенә инеп үтә идек. Төшөңә ауыл инсә, ин беренще мәщет инә иде. Религия ла көщлө булған анда. Баш ауырта, тисәң, ҡартыйлар тиз генә уҡый да иде, баш ауыртмай иде. Ҡарман ауылы шундай уңған кешеләр инде. Тик сатҡанлар, колхозда эшлийләр. Поезда йөрөп. Колхоз көщлө иде.

Ҡушаматлар буйынща инде. Безде "Бүреләр" дип йөрөтәләр иде. Безнең ҡырҙа торған "Туҡ бызаулар". Әнкәй әйтә иде. Председатель төн йөрөй, ди: "Туҡ бызау, сыҡ сайлауға". Пожарный команда төндә йөрөй иде, ди: "Туҡ бызау, сыҡ, Бүре бабай менән бар", – дип.

Ҡартатайны өйләндергәндә өйләрендә торбалары ватылған, лампа торбасы тиз шартлай торған иде. Ҡартнәйҙе жибәргәндәр, иренең братишкалары, "Бар ана аларға, анда лампа торбасы була торған", – дип. Киткән шул өйгә. Барып ингән дә: "Исәнмесез, сездә торба була дип әйтәләр иде", – дигән. Тегеләр ашап ултырғандар инде, көлөп жибәргәнләр. "Бездә торба булмай, бездә торва була", – дип әйткәндәр.

Суғыш ваҡыты бик ауыр заман булған. Ҡарманнан күп кеше киткән. Заманына ҡарата өйө, өйөнә ҡарата көйө. Без үскәнщегә тиклем сөйләй торған идек. Гел искә алғащ та илағылар килә.

Аҡҡош ощар жөнөн ҡойар,<br>
Аҡҡош жөнөн кем йыйар?<br>
Щит йерләрдә вафат булсам,<br>
Жыназа уҡып кем жыйар?

Мына шулай ныҡ сағынып, илап йөрөгәнләр. Әткәй мең туғыз йөз утыз туғызынщы йылда киткән, мең туғыз йөз ҡырҡ алтынщы йылда ғына ҡайтып кергән. Барысы да суғышты күргән. Бабруйскиҙа армияға алынған. Под Брестом, шунан башланған. Анан щаҡ ҡайтып килгән. Бухаровларның бересе репрессированный булған, анан жигерме йылға йаҡын йөрөп ҡайтҡан. Репрессиянан суң сразу штрафбатҡа алып киткәнләр. Анда йуғалып йөрөгән, хат килгән йуғалған тигән. Эт күрмәгәнне күргәнләр.

Йен-пәрейләр турасында мына әнкәй сөйлий иде. Бер көн барып керзем Василә апаға, ди. Ул әйтә, ди, ана су, өй эсендә су, ди, анда өйрәкләр йөзөп йөрөй, ди. Мин ҡарайым, ди. Ысын йөзөп йөрөй, ди. Уже йуҡ, дигән

икән, итек муйыннан салынған, ди. Өйрәкләр йуҡ, ди. Элек сихыр менән булашҡанлар инде. Элекке кеше көщлө булған инде. Хәзерге заманда йуҡ инде.

Элек ҡартәтийҙең башы ауырта торған иде. Ҡартый әйтә иде, ҡартәтийҙең башы түңкәрелгән, дип. Тастамалды урай ҙа сөй ҡаҙа иде. Башты ҡыса ла инде тастамал. Шунан суға иде. Баш ауыртыуы туҡтай. Тауыҡ майын килтерә лә башына сала иде. Әллә нимәләр эшләй иде. Чистый хәлем булды хәзер, Камаринға хәзер бейейем, дип китә ҡартәтий. Мин бала щаҡта аңламай идем. Хәзер аңланым. Көнө-төнө йөрөп арыған инде.

Кешеләр киләләр дә ҡартәтийнән сорайлар иде. Май бир, дип, щәй бир, дип. Тоз бир, дип. Ҡәртий әйтә иде: "Эй хәйерщеләр, тағын кергән булғандар, әллә бында Андрей ҡазнасы бар микән?" – дип әйтәләр иде.

Мәктәпкә йаҡын торған Рафиҡова апа бәйет әйтә иде. Мәүлид байрамдарында анда.

Уфанан бер одноклассниғымны күргән идем. Жәмиләгә и Рәмилгә уже сиксән йәш. Әйтә, ди, кем мине элек аулаҡ өйҙә арттан ҡощаҡлап йата иде әле ул, дип. Исләп көлгәндәр.

(Хужахмәтов Айнур Оскар улы яҙып алды).

## ПРОГРЕСС АУЫЛЫ

### Шәкиров Халфин Шәйгәрәй улы, 1957 йылғы

Прогресс ауылына Ҡарман ГРЭС-ы төҙөлү сәбәптә Бәҙрәш ауылыбыздан күщтек. Алтмыш сигезенще йылны дүртенще ноябрь көннө. Шунан башлап Прогресс ауылында йәшәймен. Алай армияҙан ҡайтҡащ Ҡарман ГРЭС-ында столяркада эшләҙем. Анан училищеда физвоспитание буйынща бер йыл, анан йаңаҙан ГРЭС-та. Анан суң ауылға ҡайттым и ауылдан эштән дә щыҡмадым, былай ғына әйткәндә, эшләҙем. Ауыл советында, колхозда. Колхоз ойошторылды. Ҡарман ГРЭС-ы безнең колхозға ферма төҙөп бирде. Ике йөз илле баш сауым сыйыр, йөз баш ат ҡаралды. Мең йарым гектар йер бригадаҙа эшкәртелә иҙе. Уражайлар әйбәт булды, халыҡ ҡәнәғәт булаҙырыйе. Хәзерге көндә, шулай уҡ, безнең ауыл ҡырындағы жирләр эшкәртелә. Хәзерге ваҡытта колхоз түгел инде. Конкретно – СПК. СПК – фермерский хужалыҡ кеүек инде.

Ауылда йәшләр бар, алай теге йәш балалар әзерәк, но бар. Мәктәп бар. Училище шулай уҡ. Участковая болница төҙөлде. Участковая болницада житмеш биш кеше кереп йатырлыҡ. Клуб төҙөлде. Клуб сиксәненще йыл ачылды. Больница житмеш алтыларда, мин армияҙан ҡайтҡащ, житмещ сигезләрдә ачылды. Мин житмещ биштән житмещ житегә тиклем хезмәт иттем. Хезмәттән ҡайтҡащ, больница ачылған ийе. Бөгөнгө көндә халыҡларны лечить итәләр, но элеккещә йатып түгел инде.

Ауылда ҡушаматлар бар. Үземдең әтәйгә бирелгән – Оло ҡош. Оло ҡош тип биргәннәр, ул ваҡытта (ул суғышҡа киткәнще) ул ун алты-ун жиде йәшлек жигет атларны фронтҡа әзерләгәннәр. Шул ваҡытта бер атны жиңә алмағащ, әтәй узып барған да, шул ат өрәткәндә ҡырында торған кешеләр узып барышлай туҡтатҡаннар да, әтәй йаҡшы атҡа атланып китеп, атны күз ачып-йомғанчы буйсындырып биргән. Шуңа күрә, атны оло ҡош басҡан кеүек басты, тийеп исем биргәннәр инде. Әйтергә ҡыйынырaҡ инде, кешеләрдә бар инде ул ҡушаматлар. Йуҡ, кеше ащуланыр. Кем әйткәнне беләләр, ащуланырлар. Мынсы үзебезнең әтәйнеке булғащ, шуңа әйттем инде.

Электән килгән ғөрүф-ғәзәт буйынща ышаныслар бар. Элек аларны буйсондырырға порох йандырғаннар. Шуңа, хәзерге ваҡытта ла, ҡайбер кешеләр шундайны файдаланалардыр инде.

Легендәләр, риүәйәтләрне белмәйем, литература белә шөғөлләнмәдем.

Братишка – эне. Сестренка – сеңле. Брат – абый. Сестра – апа. Жена брата – жиңгәй. Сестренка жены – балдыз. Бабушка – ҡартый. Прабабушка – олы ҡартый.

Шапка – бүрек. Обувь – айаҡ кийеме. Лужа (после дождя) – йамғыр суы.

Земляника – ҡайын жиләк. Смородина – ҡарағат. Малина – ҡурай жиләге.

Жук – ҡоңғыз. Кузнечик – щикерткә. Все насекомые – ҡорт. Улитка – әкәмтөкәм.

(Акилова Мөнирә Фәтих ҡыҙы яҙып алды).

## СИБӘҘЕ АУЫЛЫ

### Фазылова Римма Фани ҡыҙы, 1952 йылғы

Ауылның тарихын уҡып белмәйбез. Әсфәндийәровтың китабының бишенсе томында Йаңауыл турасында йазылған бит инде. Беләм инде мин ҡартатайның, нәнәйләрнең сөйләүе буйынща ғына беләм инде. Мин нәнәйләр ҡулында үстем. Нәнәйем мең сигез йөз туҡсан житенще йылғы иде, ҡартәтей мең туғыз йөз өщөнщө йылғы иде. Шушы кешеләр ҡулында үстем инде. Искә төшкәнләрне әйтеп бирә алам инде.

Сибәдә ауылына күщеп килгәнләр Юғары Щат ауылынан ике ғаилә. Алар артынан йаңылар килә. Урман булған бит инде. Айыу-бүреләр бик күп булған. Бик алжып килгәнләр былар. Уларны атҡанлар. Ҡызыу ғына йылға булған инде. Быға Бәймән дип исем ҡушҡанлар. Йал итеү урынын аңлата икәнен. Ауылның был йағынан аға бит инде. Аның үзенсәлеге шунда – урман эщенән жите шишмә сыға, шунан Бәймән йылғасы барлыҡҡа килгән. Анан тәгәрмәщ салғанлар, икесе быуа астында ҡалған. Су менән питать итеп тора инде шул. Салҡын сыуҙы йүгереп сыға торған идек. Икенщесе Кәрәүәде йылғасы аға. Исеме ҡызыҡ бит инде. Ул тигезлектә аға, таулы-щоҡорло урында ауыл. Ул шулай тигез, боролоп аға, урғыла-урғыла, кәрәүәде барлыҡҡа килә лә, шуға

Кәрәүәде дип исем ҡушҡанлар. Нәнәй сөйләүе буйынща. Хәзер сыулары аз инде. Ике йылға арасында йата ауыл.

Ауылға иң беренще Сибәде тигән кеше килгән. Сибәғәтулла булған, аны Сибәде, Сибәде дип, шулай тороп ҡалған. Ауылыбыз бик матур, ике тип-тигез урам. Заманында ауыл зур булған, колхозлащыу осоронда ауылда үзендә Бәймән колхозы барлыҡҡа килгән. Ике мәщете булған, өс тирмәне булған. Инйарға йөрөгәнләр купецтарға. Базарға Ғундырға йөрөгәнләр. Ғундыр базарына йөрөгәндәр. Шунда йөрөп сатыу иткәндәр. Айыу-бүреләр бик күп булған инде.

Йылғалар ҡаты көщлө булған балыҡҡа. Балыҡщылыҡ менән щөғөлләнгәнләр. Киңлеге лә ней түгел, йарлары текәрәк инде, дөмбөр менән, йә булмаса йәтмә менән, ағас осонан ике бизрә балыҡ йыйып ала идек. Балыҡ ала идек.

Ҡызылғанат. Иң күбе ҡарабалыҡ, сөйәксез балыҡ инде. Аны ҡазанға салсаң да сикерә иде ул. Тәңкәсез. Щука хәзер йуҡ.

Әзәйгән диләр хәзер. Йете шишмәнән килгән йылға ул. Бишесен күргән бар ул ҡартәтей менән. Ысын урманнан щығалар. Тегеләре, тегермән булғащ, быуа астында ҡалған. Тегермән шишмәсе дип йөрөтәләр инде бер шишмәне, аның астынан щыҡҡас инде.

Тағын ҡартәтәй бик ҡызыҡ иде, биографиясы тарихи инде. Бик хәлле ғаиләлә үсә, иртә йетем ҡала. Әткәсе үлгән ваҡытта ун өщ йәш була, шунан инде ат фермасы, сыйыр фермасы, ике ҡатлы йорт, мал-тыуар күп була инде. Жирлектәре күп була аның. Нимә эшләтәсе инде. Сабый балаға инде. Аны ун өщ йәшендә өйләндерәләр. Байғужа ауылына татарлар килеп урынлашҡан була бит инде. Байғужа волосының старостасының ҡызын урлап киткәнләр булған. Анда ат ҡараҡлары күп йәшәгән. Гел Оренбург йағына щығып китә булғанлар. Нәнәй бик щибәр булған. Нәнәйне урлап киткән Нурлыҡай тигән билдәле атаман, ат ҡарағы. Өйләренә кертмәгән бер кемде, щығармаған, өщ айлап торған. Нурлыҡайны щығып торған ваҡытын көтөп торғандар ҙа, өйнө саҡлап торған кешеләре булған, Инйар куртниклары килеп, уларҙы ҡурҡытып, алып ҡащҡаннар ҙа атҡа салып нәнәйҙе. Байғужаға алып ҡайтмағандар, тура Сибәде ауылына алып та киткәндәр. Бына ошо ун өщ йәшлек малайға, мына синең ирең була, дип ултыртып та ҡуйғанлар. Тегесе маңҡасын ҡатырып, бозға туңып ҡайта. Жите йәшкә өлкән булған. Ун алты йәше тулғащ, ҡартәтәй щығып китә. Мин аны Кащей, Кащей дип әйтә идем. Бармаҡлары озон, зур иде. Атын өскә бәйләп щығып китә. Ун туғызынщы йылда Бирский йағына. Ҡызыл армия йыйған булалар. Аның сөйләүе буйынща. Анан ҡайта ул дүрт йыл үткәщ кенә. Йыл йарым тора. Йегерме бишенще йылда военкоматта йазылған була. Азаҡ Гражданлар суғышына алына. Анан йегерме йетенще йылда ғына ҡайта.

Нәнәй инде бай баласы була бит инде. Йегерме сигезенще йылда ҡайта ла туғанларына әйтә. Вис малларығызны таратығыз, дип. Малларны вис таратып бөтөрткән. Донйа туда идет, дип. Шулайтып таратып бөтөрткән, үзенекен дә таратып бөтөрткән. Аның абзыйы була инде. Ул жәлләгән инде, бирмәгән. Малларын фәләнләрен алып киткәнләр, ун көн эщендә атҡандар инде. Бөтөн семьясын раскулачивать иткәнләр. Бәләкәй балаларын нәнәйләр алып үстергәндәр инде. Бик ҡызғанышщ итеп сөйлий торғанлар иде.

Анан ҡайтҡащ, фин суғышына баралар иде. Шунан ҡырҡ беренще йылда йегерме житенще июндә суғышҡа алына ла, сигезенсе августа ғына ҡырҡ бишенще йылда ғына ҡайта. Өщ көн суғышта өщ тапкыр контузия ала. Суғыш башланғандан алып кавалерист була. 33-й гвардейский кавалерийский полк Граждандар суғышында, 79-й гвардейский кавалерийский полк Бөйөк Ватан суғышында. Шушындый суғышларда ҡатнаша.

Алардан истә ҡалған ауыл атамалары. Ауыл ҡырынан тауҙы Бурсыҡ тауы, диләр иде. Ваҡ ҡына ташлы. Аның түбәсенән малайлар сана шыуалар иде. Ташлы бит инде. Анда бер малай айағын да сындырҙы. Текә тауы. Был тауҙа бурсыҡ күп йәшәгән. Бик күп аулағандар. Аны ҡыйбат хаҡҡа Ғундырға барып сатҡанлар. Байларға – аның майын. Бәләкәй щаҡта саҡ ҡына сирләсәң, бурсыҡ майы сөртәләр иде.

Артлытау бар. Урман иде. Бурсыҡ тауын артынан узып китә. Арҡылы йатҡан була инде. Шулай атайлар.

Күп үстергәнләр житен. Колхозлащыу ваҡытында. Анан зәңгәр щәщкәле. Ис китмәле матур инде. Гел нәнәйне ҡушалар иде, көлтәләр нейтә иде. Бещән эщенә житен салып тастамалдар суғалар иде. Мин нәнәйнең эргәсендә йөрөй идем.

Бер зыйарат бар. Берәү. Ыршылар үсә иде. Ҡартәтийҙең әткәсе була инде Зариф. Ҡәберендә йата тегермән ташы. Аның менән булышҡащ. Элек ҡорт ҡарыйлар иде. Зыйаратҡа умарта илтә иде. Ҡартәтий нишләптер анда ҡуйа иде. Кешеләр – урманға. Зыйарат астында урын бар, тегермәне булған анда. Сазлыҡ анда хәзер.

Шишмәләр бар. Кәрәүәде шишмәсе бар.

Ауыл данлы ауыл инде. Заманында күп гармунсылар була. Ҡартәтий Карамов Зариф гармун эшләгән. Бала ваҡытта ун ике-ун биш кеше гармун тарта иде. Эшкә йегәрле халыҡ инде. Сатыу итергә йараҡтандар. Тимерлектә эшлий иде. Тимерще булған иде. Келәт тигән йере бар иде. Ҡазан, сөйөн, самауыр бар иде. Өс суғышта булған, йаралары булмаған, теш ала иде. Плоскогупцы менән тартып ала иде. Тимердә ҡыззырып. Өщ контузия алған. Ағас эше менән дә булашҡан. Госпиталдә йатҡанда санитарка булып та йөрөгән. Ике ай. Декабрдән февралдән. Айағы кемдең тартылған, кем сызлана, ҡартәтийгә килә, кем баласының эсе ауырта, анда нәнәйгә киләләр иде өшкөртөргә. Алты айҙан аның ҡулында үскәнмен. Суғыштан суң ғәрип кешеләр күп була. Өйҙә тимер мейещ йанында ултыра торғандар иде. Ҡартәтий авторитетлы кеше булған инде. Истә ҡалған. Кемдең айағы протез менән, жиңе кесәсенә тығылған, Ғәлинур абыйның күзе Кутузов кеүек повязка ҡуйылған. Бер абзый килә иде, исеме истә ҡалмаған, ике айаҡсыз иде ул. "Вечный зов"ны ҡарағащ, мин илай торған идем. Андағы Димьян кеүек. Нәҡ шулай каталка, срезда эшләнгән тәгәрмәйләр, ағащ менән этеп йөрөтә ийе.

Ҡартәтий тимерҙән ҡырщау эшлий иде. Бөтмәсен өсөн. Ҡалай тығып бирә иде. Ул ағайлар суғыш турасында сөйлийләр иде. Ғәрипләр иде. Тыңларға бирмәйләр иде. Мин шаршау артынан, ҡыҙыҡмы, ҡыҙыҡ түгелме, тыңлай идем. Аңлайыммы-аңламайыммы, тыңлайым. Жыйын үткәргәннәр иде. Нәнәй "Жирән ҡашҡа"ны жырлай иде. Башҡорт жыры, ди иде. "Рамай", элекке "Шахта" жырларын жырлайдар иде. Бик матур жырлый иде. Башҡорт жырларын жырлауы ауыр, ди иде.

Хәҙер балалар музыкальный школаларны бөтәләр, уҡыйлар. Элек гармунда уйныйлар иде. Талйанда, саратский гармунда уйнай иде ҡартәтий. Балалар килә иде өйрәнергә. Безнең ауыл бик данлы ауыл иде. Бар инде. Йөз генә. Колхоз алдынғы иде. Дәртле халыҡ бездә.

Айыу алып ҡайтҡанын күрмәнем. Тимер әйберләре, балыҡҡа йөрөй торған әйберләре, эш әйберләре айырым тора иде. Йәтмә тотоп балыҡ тота иде. Комбайн тәгәрмәйләрен ыщҡындырып, йомшартып, ҡаты йепте смалаға буйап тота иде. Йәтмәгә. Бурсыҡ алып ҡайтҡанын күргән булды.

Без ауылда биш ҡыз сығабыз бит инде. Иң башта китаптар бирәләр. Клуб эргәлә бит.

"Сәскә уйыны". Кругҡа нисәлер кеше йыйыла һәм щәщкә йыйа. Кругта шулай бейеп сыға инде.

"Сигез уйыны" бар иде. Бында бер пар, тегендә бер пар. Шулай сигез басалар да, ниндәй движение менән ҡаршы барасың, анда ҡапма-ҡаршы кем ҡабатламай, йеңеүсе була инде.

Йалғыз бейеү. Йалғыз бейей инде. Бездә Фәтхиә әбей бейей инде. Туҡтамай.

Ҡызлар, йегеттәр айырым ултыра иде. Кем кем менән генә ултырасы килсә, "Ҡолаҡ әйтеш" уйнайлар иде. Оҡшаған йегетте йанға ултыртыу өщөн.

Бала-щағалар мейщ башына менеп йатып йоҡлайлар иде. Әпәй алам да тиз генә менеп ултыра идем.

(Хужахмәтов Айнур Оскар улы яҙып алды).

## СӘЛИХ АУЫЛЫ

### Сафин Нәркис Тәнғим улы, 1977 йылғы

Мин Сәлих ауылынан. Ауыл тарихы турына килгәндә инде. Сәлих исемле кеше килгән. Башта инде бер нищә генә семья булса, азаҡ Сәлих ауылы үсеп киткән, дип әйтергә кирәк. Шундай мәғлүмәтләр бар. Әлбәттә, йазылған инде ул Гәрәй башҡортлары, дип. Сәлих ауылы элек-электән бай ауыл, дип әйтергә кирәк. Ни өщөн тигәндә:

Сәлих ауыл – бай ауыл,
Ҡапҡа сайын ҡарауыл.
Аш артынан щәй эщмәгәщ,
Ниңә кирәк самауыр. Ул бит инде бер дә йуҡтан ғына андый әйтеү ҡалмаған бит инде ул. Ололар сөйләүе буйынща нитсәк, күрше-тирә ауыллардан безнең ауылға шулай ипи ашарға киләләр, дип сөйләгәннәрен ишеткәнем бар. Ауыл инде бай булған дигәннән. Әпәйне былай ғына ашап булмай. Безнең ауылда инде бик күп тегермән булған, диләр. Йаңлышмасам, дүрт тегермән, диләр. Мәщет тә булған, дин тотҡаннар. Әнинең сүләүе буйынща инде, зурәтәйнең Сафа ҡартның бал ҡортлары бар ийе, ди. Нищә баш икәнен ул әйтмәде. Бал айырҡан ваҡытта бөтөн күрше балларын щаҡырып сыйлай торған ийе, ди. Элек-электән Сәлих ауылда бөгөнгө көндә ҡорт ҡараущылар бик күп. Зурәти ҡарағащ бит инде, минең дә ҡарайсы килә.

Ҡортщолоҡ буйынща сүзләр: дымарь – төтәткещ, төткөщ. Күщ тота торған – тубал. Йүкә балы, щәщкә балы, ҡарабойдай балы.

Бында колхоз бар иде, инвестор сатып алды. "Восток" колхозы бар инде.

Йылҡы малына ҡағылышлы сүзләр – тай, көлөкәй, айғыр, алаша, бейә. Жирән ат, щал ат, ҡара ат. Тәгәрмәс, дуға, тәртәсе бар инде, ноҡтасы, дилбегә, ҡамыт, арҡалыҡ, ауызлыҡ, жөгән, тибез.

Мәрхәб шишмәсе бар. Нурлығайан, Залиф, Салҡын шишмә, дүрт шишмә бар инде бездә.

Бездә Ҡазаҡ әрәмәсе бар. Бу Йөгәмәштән щығып, Тау йулы белән барғанда безнең йаҡҡа Сәлихкә таба төшөп китә инде. Ҡазаҡларның дөйәләре дә булған, атлары да булған, дип сүләделәр. Шушында Ҡазаҡ әрәмәсендә күпмелер йәшәп йатҡаннар. Алар киткәннән соң, шушы урынны Ҡазаҡ әрәмәсе, дип атағаннар. Анан соң, тауларға килгәндә, Сөзәктау бар инде, Йөгәмәштау. Йөгәмәштау безгә йаҡынраҡ та әле. Сәлих ауылында Шаршады аға. Ҡыдращ, Тирәнкүл дигән буалар бар. "Сағыш" дигән шиғырым бар:

Йөрәк тулған сағыш белән,
Дуслар, инде нишләргә?
Йазмышым бит ташлады
Мине йыраҡ Шишмәгә.
Белсәгез сез сағышларның
